Безнең МИРАС

03

март 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Л.Гобәйдуллин фотолары

13 февральдә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Республикакүләм татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр (краеведлар) җыенын үткәрде. Әлеге чарада Татарстан районнарыннан 150 делегат, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Россия ислам университеты галимнәре – «Безнең мирас» журналының авторлары да катнашты.

Олуг мирас – авыл тарихы!

Әлеге җыенда яңгыраган чыгышларның кайберләрен журналыбызның бу һәм алдагы саннарында укый аласыз.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
3(50)
март 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

48

11 **«МӘН ЧУРАМЫН, ЧУРАМЫН...»** *Мурат Кәримов*

112 **ТАТАР АВЫЛЫ ХАТЫН-КЫЗЫ КИЕМЕ.** *Руфия Мөхетдинова*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Газизә Сәмитова*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Ак пулат.** *Н.Шәйдуллина*
6 **Чыңгызхан хәйләсе.** *Ә.Мөхәммәдиев*
11 **«Мән чурамын, чурамын...»** *М.Кәримов*
17 **Тукай турында исемдә калганнар.** *Г.Кәрам*
20 **Гайнә иленең мәгариф каһарманнары.** *Ф.Газизова*
26 **Русиядә гарәби хәреф илә басмачылык.** *Ш.Әхмәр*
30 **Авыл тарихын языйм, дисәң...** *Н.Гариф*

ТАТАР ГАМЕ

34 **Иске демократиядән яңасына атлаганда.** *Ф.Садриев*
40 **Болгар һәм Спас районы энциклопедиясе.** *Ф.Хуҗин*
45 **«Шулвакытта мин кулыма китап алам...»** *Ә.Әскәров белән Р.Сәгъди әңгәмәсе*
48 **Җәгъфәр тарихы.** *Ф.Ислаев*

ПЕДАГОГИК МИРАС

56 **Гаилә дәресләре.** *Ф.Сөләймания*
59 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

60 **Сүз һәм сурәт.** *Р.Гаташ*
64 **Гариф бабай дәресләре.** *Ф.Галимуллин*

ӘДӘБИ МИРАС

68 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
72 **Шагыйрә Газизә Баһаветдин кызы Сәмидова.** *Җ.Алмаз*
76 **Мәңгедәшләр.** *С.Зыялы*
80 **«Ак чәчәкләр» әсәре: алтмыш ел элек.**
88 **Мөнир абый Нигъмәт турында истәлек.** *Ф.Кутлу*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

94 **Фатих Әмирхан**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борханов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Холык.** *Ә.Зарипов*
104 **«Арча гимны» – йөрәк җырым».** *Г.Сафиуллина*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
110 **Сүзләр тарихыннан: «Карандаш».** *Ә.Кәримуллин*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Татар авылы хатын-кызы киеме.** *Р.Мөхетдинова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның март ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Март*

Заказ №М-464. Тираж – 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.02.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Алпамша һәм кыю Сандугач». Кәгазь, акварель. *З.Мөхәммәтҗанова рәсеме*

Газизә Сәмитова
(1862-1928)

Син йылама, йәш туташ

Идел буйы йәшел таш:
— Ник йылыйсың, йәш туташ?
— Бәхетләрем булмаганга,
Эчем сагыш, күзем йәш.

Идел буйы йәшел таш:
— Син йылама, йәш туташ.
Йылаб хәсрәт басылмас,
Йәш күңелең ачылмас.

Идел буйы йәшел таш:
— Ник йылыйсың, йәш туташ?
— Мин йыламый, кем йыласын, —
Үзем йәтим, үзем йәш.

Идел буйы йәшел таш:
— Син йылама, йәш туташ.
Йыласаң күзләрең бетәр,
Жырлаб күңелең күтәр. ■

БОЛГАР. АК ПУЛАТ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Ак пулат. Әлеге монументаль бинаның тышкы кыяфәте академик П.С.Палласның 1768 елгы тасвирламасы буенча мәгълүм. Бу һәйкәл XIX гасырның 60 нчы елларында җимерелеп төшкән, шулай да аның XVIII гасырның икенче яртысында-XIX гасырның беренче яртысында ясалган күп санлы рәсемнәре сакланып калган. Ф.Эрдманның XIX гасырның 20 нче елларындагы, П.П.Свиньинның 1823 елдагы рәсемнәре, А.Шмидтның 1827 елгы планы, сызымнары, Н.Н. һәм Н.Г.Чернецовларның 1838 елгы рәсемнәре, ә соңрак А.К.Саврасов, И.И.Шишкин сәнгати әсәрләре иң яхшылардан санала.

Әвернә формасындагы бай бизәлешле бу бина мунча ролен үтәгән, гөмбәзле үзәк залдан, киенүчишенү бүлмәсеннән, юыну бүлмәләреннән һәм җылыту, мич ягу бүлмәсеннән гыйбарәт. Көнчыгышта мунчалар, шул исәптән Болгарда да санитар ролен генә үтәмәгәннәр. Алар эшлекле әңгәмәләр алып барыла, сәүдә килешүләре төзелә торган ял итү урыны да булган.

Ак пулатта яңа археологик тикшеренүләр XX йөзнең 80 нче елларында үткәрелгән. Галимнәр цивилизацияле Көнчыгыш стандартларына туры килә торган җылыту мичләрен, кайнар пар йөрү каналларын, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү һәм файдаланылган суның агызу системаларын тапкан.

Янәшәдә казылган 10-12 м тирәнлектәге өч кое мунчаны су белән тәэмин иткән. Тикшеренүче белгечләр 1877 елгы казу һәм төзекләндерү эше эзләре тапканнар. Шул вакытта Ак пулатта таш фонтаннар, сулыклар казып чыгарылган, алар хәзерге көндә музейга куелган. 1990 нчы елларда әлеге ядкярга консервация ясалган. 2012 елда диварлары сүтелеп, элек консервацияләнгән өлешкә тәңгәл китереп торгызылды, гөмбәз астындагы помакларга блоклар куелды, бөтен комплекс чыланудан саклый торган гидрофобия составы белән капланды, нигезләргә гидроизоляция ясалды. ■

ЧЫҢГЫЗХАН ХӘЙЛӘСЕ

Әзһәр Мөхәммәдиев

...Бибарс әлеге нокталарның чынлап та яр буйлап югарыга таба агынтылар аша бер югалып, бер күренеп хәрәкәт итүләрен күргәч һәм аларның, ниһаять, артык ишле булмаган атлы кешеләр төркеме икәнлегенә ышангач, үзенең ишарә салырга тиешле коралларын барлап, карап алды: менә кисмәккә тиз кабынып китсен өчен коры үлән белән буталып салынган кара яг — нафта.[1] Ә таш арасына утыртылган баганада исә чаң тимере һәм сугар өчен тимер кендек эленеп тора.

Бөрҗанбашы Бураш морзага хәбәр салыр өчен, бер сугу белән икенчесе арасында утызар тапкыр әчтән генә санап, ачык итеп, өч тапкыр чаң какты. Мондый чаң авазы эштәге халыкны артык борчымас өчен, кирмәнгә таба артык зур булмаган ят кешеләр төркеме килеп ятуы турында гына ишарә иде.

Килүчеләр төркеме кирмәннең таш диварына терәп салынган манарасы — керем әленә[2] якынлашканда, Бурнаш морза үз яраннары белән аларны капка өстендә, икенче каттагы мәйданчыкта көтеп тора иде инде...

Төркем пар ат җигелгән ике тәгәрмәчле арба артыннан атлаган, куллары да бәйләнмәгән егермеләп кол һәм алар качу турында уйлап та карамасыннар өчен, кол сатучы «сәүдәгәрләр» — унга якын аршын озынлыгы кылыч таккан килбәтсез мангул нүкәрләреннән тора иде.

Төркем килеп җитәрәк, арбада дилбегә тотып килгән берәүнең карлыккан тавыш белән кыпчак телендә җырлап килгәне ишетелә башлады:

Кызыл кыя — кышлавым,
Яшел кыя — җәйләвем,
Чыңгыз малын караең,
Рәхәт гомер итәең!

Җырлаган кешенең тавышы да, ике тәгәрмәчле арбасы да Бибарска таныш булып тоелды. Һәм, чынлап та, ул бу тавышны теге вакытта төнлә белән Хәрәзм тирәсендә ишетүен исенә төшерде.

Кирмәнне әйләндереп алган өч рәт тирән итеп казылган канаулы урны һәм һәр чокыр өстенә җайлап салынган күперләр аша чыгып, кирмәннең керем әленә — манаралы керү капкасына — якынлашкач, дилбегә тотып җырлап килгән кеше, атларын туктатып, арбадан төште һәм алгарак чыгып, әмир Бурнаш морзага сәлам юллады:

— Уйсыннар патшасы Таргытай хөрмәтле Бурнаш морзага сәлам тапшыра! — диде тавышын күтәреп.

*Дәвамы. Башы журналның 2 нче санында

[1] Болгарча: «кара яг» (кара май), гарәпчә: «нафта». Нефть.

[2] Керем әле — кирмәнгә (крепостька) керә торган биек манаралы капка.

Р.Заһидуллин рәсеме

Уйсыннар Иделнең түбән агымында аръякта — болгар биләмәләрендә күченеп йөргән зур гына бер кабилә булып, шул ук вакытта ул зурмы — кечеме, мондый кабилә башлыклары үзләрен бик олылап, болгар патшаларына тиңләп, болгар саклыгы астында яшәсәләр дә, «падишаһ» дип атарга ярата иде.

— Бигрәк тә мәшһүр патша икән! — диде Бурнаш морза, артында басып торган йөзбашы Җиһангирга кинаяле елмаеп. — Муенына боксык[3] кидертелгән кол артыннан сәлам җибәргән.

Чынлап та, арбадан төшкән кешенең куллары бәйләүле булмаса да, муенында богау иде.

Бурнаш морза йөзенә ясалма елмаю чыгарып:

— Сәламеңне алдык, абайлы дустым, Калаун. Рәхим ит! — диде ул.

Аннары йөзбашына борылып, үз-үзенә:

— Тик капкадан гына ераграк торсыннар! — дип өстәде. — Болары сукбайга

[3] Боксык — кол богавы.

охшаган... Барыбер шул башкисәр мангул нүкәрләредер. Сак булырга кирәк. Алар, безнең оланнар кебек үк, һәркаюсы өйрәтелгән булыр.

Калаунга карап, ул сүзен дәвам итте:

— Нишләп бик озак күренмәдең, Калаун? Мал-тауарың да бик аз күренә. Мин сине һич югында бер кырык-илле кеше белән килерсең, дип уйлаган идем... Күрәм, сайравыңа караганда, үзеңнән кол ясап, сатарга алып китергәннәр булса кирәк. — диде ул үзенең шаяртуына үзе көлеп.

— Яныйлар бит! — диде Калаун, кыйналган борчулы йөзен күтәреп. — Эшләр бик шәптән түгел, Бурнаш морза. — диде ул бераз тынып торганнан соң. — Үргәнечне ташын-ташка харап иткәннән соң, бу дошманнар безнең Җаек буенда урнашкан җәйләүләргә дә һөҗүм итә башладылар...

Иярле атларда дорфа гына читтәрәк утырган көбә күлмәкле җайдакларга ымлап күрсәтте ул. Күрер күзгә куркыныч булып күренмәсәләр дә, бөклеләргә[4] охшаган бу көчет атларга атланган җайдаклар бөтен дөньяны якалап яткан шул мангул нүкәрләре иде, күрәсең.

— Нишләп үзләре сату итми соң алар, Калаун? — дип сорады Бурнаш. — Колны үзе белән сатулашып алмыйлар бит инде аны!

— Тел белмиләр. Сүбәдәйнең ярты гаскәре кыргыз нүкәрләреннән торса да, төркичә сөйләшмиләр. Ә акчаны яраталар, ләкин үзләре бик һавалы алар. Ал безне сатып, әмир Бурнаш! Болар бар да һәйбәт коллар, үзем сайлап сатып алган идем мин аларны. Әгәр алмасаң, сезнең күз алдыгызда барыбызны да турап ташлаячаклар бу каһәрләр. Кирмәнегез ике катлы, ә астагы таш базларда күп санлы коллар яши, дип ишеттерделәр...

— Кырагайлар, күчмәләр сүзе, юк сүз бу! — диде Бурнаш морза катгый итеп. — Каян килеп күп булсын? Туранлылар түгел ич без — ихата саен арык казытып, су кертмибез. Бездә табигать башка, үзебез эшлибез. Үзең дә беләсең, безнең кирмән артык зур түгел, сәүдә юлында утырган бер кәрвансарай кебек кенә. Безнең аркылы колларны Сүриягә, йә булмаса Румга алып китәләр. Ә калганы, кул эшенә ярардае инде 20-30 яшьтән картаеп эштән чыга, үлә. Базда саклап тотмыйбыз. Хәер, әгәр бездә калсаң, үзең дә күрерсең...

— Картаймый ни, ачлы-туклы килеш көне-төне эшләтсәләр, картаерсың да! — дип мыгырданды Калаун.

Бурнаш ишеккә якынрак торган йөзбашы Җиһангирга акрын гына тавыш белән:

— Бар, тиз генә тикшер аңдуны[5]. Уланнар урыннарына басканмы, бассалар, сак торсыннар! Бу мангул дигәннәре үткер егетләр булса кирәк, юл югалтып, болай ялгыш кына килеп чыга торган җайдакларга охшамаганнар, — диде.

Бурнаш морза, юлчыларга борылып, вакытны сузу теләге белән, коллар бәһасен сораштырган арада, йөзбашы Җиһангир артыннан Бибарс та баскычның ике яркасын бер итеп йөгереп төште. Йөзбашы әйткәнче үк, үз эшләрен белгән бер төркем улан зур керем-әле кырындагы янкапкадан үтеп, дивар эчендәге куышка кереп урнашкан иде, ә икенче бер төркем исә тар урамнан кирмәннең икенче башына таба йөгерде.

Икенче катта басып торган Бурнаш морза кул ишарәсе белән тимер күгәннәрдәге авыр керем-әле (капкалары) шыгырдамыйча, тыныч кына ике якка ачылып киттеләр — алар яхшы майланган иде. Юл газапларыннан талчыккан тоткыннар зур һәм биек капкадан бер-бер артлы эчкә үтте. Ләкин мангул нүкәрләре

[4] Бөкле (борынгы төркичә) — Корея.
[5] Аңду — засада.

аңа карап ашыгып, каударланып капкадан узмадылар. Аларның сагаеп торганын күргән Бибарс: «Бәлигъ булган[6] сугышчылар болар», — дип уйлап алды.

Ачылган капка янында эшнең кайнарлана баруын һәм уланнар кергән янкапка янында басып торган йөзбашының аңа карап әмер көтеп торуын күреп, Бурнаш хәлне бик тиз аңлап алды һәм аталыкны үз кулына алып, көр тавыш белән:

— Ук ат! — дип кычкырды.

Шуны гына көтеп торган бер төркем улан янкапкадан йөгереп чыгып, укларын керешкә күзләп атып өлгергәнче, хәлнең хәтәргә әйләнүен аңлап алган мангул нүкәрләре аларның якынрак торган берничәсен кылычлап та ташладылар. Калаун исә югалып калмады — арбасыннан елкы тота торган элмәкле бау алып, аны яшен тизлеге белән кылычыннан кан тамып торган бер нәүкәрнең муенына ыргытты һәм элмәкне тарта-тарта терсәгенә җыйный да башлады. Элмәккә эләккән нүкәр, чабулап биегән атында утыра алмыйча, мәтәлеп егылып төште. Ә эшнең болай артык яманга әйләнгәнен күргән башка нүкәрләр атларын кире бордылар. Мондый очракларда сугыш кырыннан качып китү алар өчен оят саналмый иде, күрәсең.

Ләкин кирмәнне салганда ук болгар төзүчеләренең кайбер нәрсәләрне алдан уйлап хәстәрләгән булуын нүкәрләр белмәде. Алар чабып киткән такыр юлның сул ягында — тирән Болга елгасының текә яры, ә уң ягында — өстендә сакчылар торган биек кирмән, ә каршыда — кирмән почмагында — ат үтә алмаслык итеп юл аркылы тирән ур казыган иде. Нүкәрләр килгән күпер исә, аңдуга йөгергән ирәннәр тарафыннан күтәртеп куелган булып чыкты. Авызлыкларын тартып, атларын биетеп, күперсез тирән ур янында кая барырга белми торган нүкәрләрне төрле яктан йөгереп чыккан уланнар урап алдылар да сөңгеләп аттылар.

Элмәктән ычкына алмыйча, тузанлы юлда аунап яткан нүкәр янына арканын тарта-тарта беренче булып Калаун барып җитте. Ул бер аягы белән элмәккә басып, кунычыннан пычагын алды һәм ашыкмыйча гына чабуын билбавына кыстырды да, исенә килеп, читтәрәк яткан кылычына үрелергә маташкан нүкәргә китереп чәнечте. Аннары яшел үлән өзеп алып, ашыкмыйча гына пычагын сөртә-сөртә, морза янына килде.

— Үтермәскә иде, — диде Бурнаш морза, — Һәйбәт кол булган булыр иде.

— Син боларны белеп бетермисең әле, Бурнаш бәй. — диде Калаун җирдә аунап яткан нүкәргә ымлап. — Берсе генә исән калса да, алар яңадан өере белән килеп, кирмәнегезнең астын-өскә китерәчәкләр.

«Безнең кирмәннең алай гына астын-өскә китерә алмассың!» — дип әйтмәкче булган иде дә Бурнаш морза, мангулларның Үргәнеч тиклем Үргәнечне дә җимерүләрен исенә төшереп, дәшмәде.

Аның тынып калуын күреп, Калаун үзенең дә коллар белән алыш-биреш итүче сәүдәгәр икәнлеген исенә төшерде булса кирәк:

— Ярар, — диде ул, ярты юлда калган сүзен дәвам итеп. — Кол башыннан күпме түләрсез икән?

Калаунның әрсезлегенә елмаймыйча булдыра алмады Бурнаш морза:

— Соң, әле яңа гына син «Чыңгыз малын карап, рәхәтләнеп яшәгез», дип җыру җырлап, үзеңне сатарга маташкан идең, ә хәзер кемне сатарга җыенасың? — дип көлде. Аннары Калаунның җавабын да көтмичә, йөзбашын култыклап читкәрәк алып китте. Алар янына тагын бер-ике алпавыт та килде. — Йә, бу кол дигәннәре белән нишлибез? — дип киңәште Бурнаш морза.

— Калаунны азат итәргә кирәк, — диде йөзбашы. — Бәрелештә дә ул үзен кыю тотты. Ә калганнарын сатып җибәрү мәслихәт.

[6] Бәлигъ булу — сугышта яралану, ягъни тәҗрибәле булу.

— Минем фикеремчә, — диде морза, — бу болгавыр заманда кырагайларны үчекләргә ярамас, киресенчә, аларны үзебезнең якка аударырга кирәк. Шуңа күрә, тоткыннарны азат итәргә киңәш итәр идем.

— Без дә моңа каршы түгел, — дип, башкалар да аның фикере белән килеште.

Бибарс кояшка күз салды. Аңа инде бик күп вакыт үткән кебек тоелган иде, баксаң, кояш әле урыныннан да кузгалмаган — күтәрелеп кенә килә икән. Ул өенә ашыкты. Әнисе аны яртылаш җир катына кереп торган таш алачыкның ишеген ачып, якты йөз белән каршы алды. Көтеп үк торган икән. Бибарс тапчан[7] уртасындагы ташна[8] өстендә комганнан су салып кулларын юды да, иртәнге ашка утырды.

— Мин, әнием, балыкка барып киләм. Кичтән саплауга кармаклар да салып калдырган идем. — диде ул урыныннан кузгала башлап.

— Сак йөр, улым, тагын шул тартар нүкәрләренә тап була күрмә, — диде.

— Тартар түгел, әнием, татар! Алар үзләрен мангул, диләр икән. Татар, дип мыскыллап, безгә генә акыралар алар!

— Нинди тартар булыйк без, улым, Аллага шөкер, мөэмин-мөселман без, ә асылыбыз — кыпчак! — диде Бибарсны озата чыккан Бибисара.

Бибарс, яр буйлап түбәнгә төшеп, кичтән салган саплауларын барлады. Салмак кына агып яткан Болга суыннан саплаудагы бер-ике кушбашны һәм җәен баласын, саңакларын ертмаска тырышып, кармактан салдырды. Аннары аларны чыбыкка тезеп суга батырып куйганнан соң, бераз кармак та салып алырга булды. Бөтерелеп аккан чоңгыл өстендә әйләнеп йөзгән калкавычка күзләрен текәп озак кына утырды. Кояш шактый ук күтәрелеп, көн соңара төшкәнгә, күрәсең, маймыч кармакны чистартып торса да, балык башка эләкмәде.

Кармагын алып, суалчанын рәтләгән арада малайның күзләре өскә — сөзәк яр башына төште. Анда... Ярдан бер-ике йөз адым чамасы гына ераклыкта күренеп торган Әтәй кыясы өстендә... Нечкә озын муенлы ак аргамакка атланган кемдер берәү ул кармак салган якка таба карап тора иде. Күрәсең, ул яр астындагы кармак салып утырган малайны шәйләмәде. Ара шактый ерак булса да, күтәрелгән кояш нурларында малай җайдакның өстендә буйлы ефәк тукымадан тегелгән затлы хитан[9] икәнлеген чамалады.

Җайдак ашыкмый гына иңсәсеннән җәясен салдырды да, садагыннан ук алды һәм аны күзләп, төзәми генә елгага таба атып җибәрде. Кояш нурлары астында озак кына күренеп очканнан соң, ук елга ярына җитәр-җитмәстән камышлы бер чокырга барып төште. Малай, кармагын ташлап, кабаланып яр башына менде дә, камышлы чокырга таба йөгерде. Ук башагы кадерле нәрсә — югалтырга ярамый, хәтта олы-олы ирләрнең дә яудан соң аны эзләп, җыеп йөргәннәрен ул яхшы белә иде. Әмма укның кая төшкәнен күрсә дә, аны рәт-рәт үсеп утырган камыш арасыннан табуы җиңел булмады. Ул камыш ерып йөргән кабандай тавыш чыгарып, азмы-күпме укка охшаган бер генә камыш сабагын да калдырмады, ә табып алгач, кыяга таба йөгерде.

Дәвамы бар ■

---

[7] Тапчан — кызыл балчык төеп катырылган җир идән.
[8] Ташна — комган куяр өчен идәндә көйләнгән һәм уртасында су агар өчен тишеге булган бизәкле ак таш. Юынтык су аска таба киңәя барган таштан салынган 1-2 метр тирәнлегендәге чокырга ага.
[9] Хитан — плащ.

«МӘН ЧУРАМЫН, ЧУРАМЫН...»

Мурат Кәримов

(«Чура батыр» дастаны — татар һәм казакъ милләтенең кардәшлеге ноктаи назарыннан)

В.Булатов рәсеме

«Чура батыр» дастаны – төрки халыкларның уртак мирасы. Татарларда дастан «Чура батыр» исеме белән мәгълүм. Казакъ кардәшләребездә исә **«Шора батыр»** дип атала. Шулай ук нугай һәм кыргызлар да әлеге тарихи ядкярне «Шора батыр» диләр. Дастанның төрекмән шивәсендәге нөсхәсе дә бар. Аның сюжеты барлык төркиләрдә дә охшаш булуга карамастан, тел, фактик мәгълүмат һәм кайбер детальләрдә үзгәлекләр дә күзәтелә.

Казакъ дастанында Шораның атасы **Нарык** — бай кеше, эреле-ваклы, бихисап терлек-малга һәм тибен (ягъни көтүлек) җирләргә, күп хезмәтчеләргә хуҗа. Ул Алтын Урда дәүләтендә, хәзерге Казакъстан, Татарстан арасындагы киң далада күчмә тормыш алып барган. Әмма **Гөлханыс** белән аларның баласы булмый. Казакълар, борынгы мәҗүси йола нигезендә, Баба Туклас каберен зиярәт кылып, аңа бәхетсезлек вакытында ярдәм сорап ялвара торган булганнар. Шулай итеп, дөньяга **Шора** аваз салган. Ир углан «ай үсәсен көн үскән», зирәк, куәтле, гадел булган. Көннәрдән беркөнне, бил алышкан вакытта, Шора айратканнарның ыру башы Али бәйнең угылын бергә-бер көрәштә үтергән. Дөрес, бу егет элек тә Шораны гына түгел, аның гаиләсен, ырудагы башка кешеләрне дә гел кыерсытып, рәнҗетеп яшәгән. Шора бу башкисәрдән күпләрне яклый һәм данмәртәбәгә ия була.

Али бәй, угылының үлеме турындагы хәбәрне ишеткәннән соң, таминлылардан һәм Шорадан үч алырга уйлый. Кара хан аңа әүвәле Шора янына күзәтчеләр җибәрергә, таминлылардагы хәлне белергә киңәш итә. Икейөзле хан шултикле мәкер белән эш итә ки, күзәтчедән Шорага Али бәйнең яу белән киләчәген һәм башын чабачагын хәбәр иттерә. Бу хәбәре өчен Шорадан Али бәйнең башын чабып китерүен сорый. Әлеге вакыйга кабилә арасындагы ызгыш-талашның бер күренеше генә: хан, тәхетенең иминлеген тәэмин итәр өчен, мәкерле һәм үҗәт, көчле кабилә башлыгы Али бәйне үз юлыннан юк итәргә теләгән.

Казакъларда шундый гадәт бар: әгәр дә кеше кемне дә булса үтерсә, ул аның ата-анасына яки туган-тумачасына кон түләгән һәм үтерүчене гафу иткәннәр. Кон, гадәттә, тугызар баш дүрт төрле ayклы мал — дөя, җылкы, мөгезле эре терлек, сарыктан гыйбарәт булган. Җинаятьче үзе түли алмаса, аның ыруы түләргә тиеш булган. Кабилә өчен әлеге авыр йөкләмәне башкармый калу гаять зур хурлык саналып, бөтен ыру-кабиләнең вәкиле кеше үтерү кебек олы җинаятьне кылудан сакланган. Ягъни казакъларда кеше үтерү кебек җинаятькә каршы профилактика булган.

Шора батыр тарафыннан тәкъдим ителгән конны Али бәй алмый. Кискен көрәш вакытында Али бәй беренче ата, ләкин аның угы Шорага тими. Шораның угы Али бәйнең йөрәгенә кадала. Шора, аның башын чабып, **Кара ханга** җибәрә. Нугай, татар вариантларыннан аермалы буларак, казакъ дастанында Шорага ата-анасы, ырудашлары, гомумән аңа иминлек теләүчеләр торган җирен ташлап китәргә киңәш итә. **Казан** — Шораның әтисе туган төбәк, аның күп кенә туган-тумачасы, ырудашлары шунда яшәгән. Казанда

Казакъ бишеге.
Фото «Казакъның киез өе» китабыннан алынды

Чөбәк. Бишеккә яткырган вакытта малайның җенес әгъзасына беркетелә торган әсбап. Күчмәннәрдә бала табигый кече хаҗәтен бишектә булган тишек аша шушы әсбап ярдәмендә башкарган.

«Ачык һава астында» С.Романов рәсеме. 1970 ел

ул тулысы белән үзен имин-тыныч хис итә алган. Анасы Гөлханыс, китмәсәң, имезгән сөтем хәрәм булсын, дип кичермәячәген дә белдерә.

Дастанның казакъларда булган башка версиясендә Чура батыр, үзенең Казан ханлыгында яшәүче ырудашлары белән кушылып, казакъларның кан дошманы калмыклар белән сугыша. Калмыклар (калмаклар, ягъни калучылар) Кытайның төньяк-көнчыгышындагы Җунгәр иленнән Көнбатыш Себер, көнбатыш казакъ җирләрен кичеп, Идел буена кадәр барып җитәләр. Күчмә җунгәрләр, кытайлар тарафыннан кысрыкланып,

Сиртмәле татар бишеге.
«Казан арты» тарих-этнография музееннан

XVI гасырда казакъ җирләренә һөҗүм итә. Алар, казакъ кабиләләрен куып җибәреп, көтүлекләргә хуҗа булып кына калмый, хәтта халыкны, шул исәптән картларны, хатын-кызны һәм бала-чаганы да юк итә. Кече җөзнең казакъ кабиләләре һәм аларның Казан ханлыгында яшәүче тама ыруы калмаклар белән даими ызгыш-көрәштә була.

Казан ханлыгындагы тама ыруының гаскәр башында Исым белән Шора торган. Исым — Казан ханының карачыбәге. Казакъ галиме **Мөхәммәтҗан Тынышбаев** язуынча, Исым, ягъни **Ислам Нарыков** — **Чура Нарыковның** бертуган энесе. Татар галиме **Дамир Исхаков** та Казан ханлыгының өч дәүләт эшлеклесе — **Чура**, **Аликәй** һәм **Ислам** Нарыковлар арасында туганлык мөнәсәбәте булганлыгын таный. Алар барысы да Кече җөздәге тама ыруы вәкиле, Нарыкның бертуган балалары.

Дастанның казакъча бер вариантында Нарык Кырымга түгел (татарча варианттагы кебек), **Үргәнеч** каласына күченә. Ошбу каланың хакименә хезмәт итә. Көннәрдән беркөнне ханның яраткан эте куяннар артыннан ауга китеп югала. Нарык, аны эзләгән вакытта, мәгарәләрнең берсендә алтын хәзинәсе

таба һәм бу турыда ханга хәбәр итә. Рәхмәт йөзеннән, хан аңа би титулын бирә. Көнләшүче адәмнәр ханны Нарыкка каршы котырта башлый. Шунлыктан Нарык Казанга китәргә тели һәм бу хакта ханның рөхсәтен сорый. Хан, намуслы хезмәтчесен сарайда калдырырга теләп, айтыс (әйтеш) оештыра.

Айтыста катнашучылар Нарыкка Үргәнечтә калырга киңәш итәләр, ә ярышта җиңүче **Миңсылу** исемле туташны хан Нарыкка кияүгә бирә. Бу никахтан аларның улы Шора һәм кызы **Ширин** туа (татар вариантында **Кәнибәк**). Малайлар Шораны «килмешәк углы» дип үртиләр. Үргәнечкә Казанга руслар һөҗүм итүе турында хәбәр килеп җиткәннән соң, Шора, үз халкын якларга дип, тарихи ватанына ашкына. Ул Казанны талаучылар белән көрәшә, башкаланы азат итеп, яңадан Үргәнечкә китә.

Дастанның нугай вариантында Чура батырның атасы Нарыкның **Дагыстаннан** куылып җибәрелүенә аның **Казы бәк**нең энесе **Канмирзаны** үтерүе сәбәп, диелә. Канмирза Нарыкның хатыны Миңсылуны «кулга төшерергә» хыялланган була. Нарык, Дагыстаннан куылганнан соң, **Хаҗитарханга** килә һәм **Акча солтанга** хезмәт итә башлый. Акча солтан да Миңсылуга гашыйк була. Нарык, Акча солтанны да үтереп, чабаннар арасында яшеренә. Юлда барганда Миңсылу ир бала таба һәм аңа Шора дип исем кушалар.

Флүс Латыйфи, дастанның добруҗа татарлары хикәяләвенә нигезләнеп, Нарык батырның куылуына Казан ханының углын үтерүе сәбәп булды, ди. Бу ханзадә дә Нарыкның хатыны чибәркәй Миңсылуны көчләп «кулга төшерергә» талпынып караган. Казаннан Кырымга кайтканда аларның балалары туа. Бу балага Чура дип исем кушалар.

Добруҗа татарлары сөйләвенә караганда, Али бәй, Чура батыр булмаганда, хан белән килешеп, Нарык йортына һөҗүм итә. Нарыкны кыйный, хатыны Миңсылуны һәм сеңлесе Канибәкне җәберли, аларны мәсхәрә кыла һәм яраткан чабышкысы **Тасмагерне** урлап кача. Әтисе, булган хәләхвәлне хәбәр итеп, улын чакырта һәм үч алуны таләп итә. Чура батыр, Али бәй янына килеп, атны кире бирүен үтенә, моның өчен алмашка башка мәшһүр чабышкы атларны тәкъдим итә. Али бәк катгый рәвештә баш тарта. Чура батыр, Али бәйне йорт талауда, әтисен кыйнауда, әнисе һәм сеңлесен мәсхәрәләүдә гаепли һәм көрәшергә яки ук атышырга тәкъдим итә. Али бәй уктан атуны сайлап ала. Беренче булып атып җибәрә һәм ук чак кына Чура батырга кадалмый кала. Икенче чиратта Чура батыр атып җибәрә, ук Алинең йөрәгенә кадала. Шулай итеп, Чура яраткан чабышкысы Тасмагерне ала, атасы янына әйләнеп кайта. Ата һәм угыл **Чыңгыз ханнан** калган канунны яхшы хәтерли: «Караны үтергән — каралмас, түрәне үтергән котылмас!» Гади кешене үтерүчене аклау мөмкин, ә түра-чыңгызыйны үтерүче гафу ителми, качып котыла алмый. Алар шуны аңлый: Кырым ханлыгында калу шактый хәвефле һәм тизрәк китәргә кирәк. Әтисе Нарык улына шундый киңәш бирә: *«Бар, анаңның рөхсәтен ал, ул бит сине сиртмәле бишектә үстергән!»* Чура батыр, анасының фатихасын ала, туган-тумачасы һәм сөекле яры **Алтын** белән саубуллашып, Казан ханлыгына китә. Казак (ягъни урыс) гаскәриләре Казан ханлыгына һөҗүм итә калса, шәһәр халкы азатлыгы өчен сугышачагын белдерә.

Миңсылу йөкле вакытында ук бер төш күргән икән: аның улы мәшһүр баһадир булачак һәм суга батып үләчәк... Дастанның бер варианты буенча, Чура батыр бар көч-куәте белән Казан халкы азатлыгы өчен көрәшә. Берүзе калгач, әсирлеккә төшәргә теләмичә, **Иделгә** ташлана һәм аты белән батып үлә.

Чура батыр дастанының нугай,

казакъ, татар вариантларын һәм тарихи фактларны чагыштырып тикшерү әсәрнең булган вакыйгаларга нигезләнеп язылганын күрсәтә. Шулай да татар варианты тарихи чынбарлыкка күпкә якынрак. Нугай, казакъ телендәге дастаннарда юлбарыслар, аждаһалар белән көрәш, тау, елга һәм чүлләрне кичүне тасвирлаган күренешләр бар. Ә бит таулар казакъ даласында юк, ә арысланнар, аждаһалар Дагыстанда да, Казакъстанда да булмаган. Чура батырның тарихи шәхес булуын һәм аның **Кече җөздәге** тама ыруыннан чыкканлыгын казакъ тарихчысы Мөхәммәтҗан Тынышбаев 1925 елда ук **«Материалы к истории киргиз-казакского народа»** дип исемләнгән китабында **Карамзин** һәм **Левшиннарга** сылтама биреп яза. Казан татарлары арасында **Урта җөзнең** аргын, кыпчак, ширин, барын, Кече җөзнең алчын, тама, адай һ.б. кабиләләренең вәкилләре булган. Барыннан да бигрәк аргын, кыпчак, барын һәм шириннәр Әстерхан, Кырым ханлыкларындагы кебек үк Казан ханлыгында да идарә итүче ыру булган. Ә легендар Чура батыр Нарыков — Казан ханлыгы хакимияте әгъзасы булган һәм **Сафагәрәйне** тәхеттән куып җибәрүдә катнашкан шәхес. Сафагәрәй, яңадан Казан тәхетенә утырганнан соң, Чура Нарыковны үтертә. Чура батырның кардәше хан диванының әгъзасы, карачебәк **Аликәй**, һәм Казан ханлыгы карачебәге, хакимият әгъзасы **Ислам** 1552 елда Казанны Явыз Иван гаскәриләреннән аяусыз саклыйлар һәм кирмән янында батырларча һәлак булалар.

Татар һәм казакъ халкының уртак тамырлары турында Татарстан җирлегендәге казакъ кабиләләре топонимнары да дәлилли. Татарстан Республикасының **Буа** районындагы **Әлки**, **Азнакайдагы Әлкәй** авыллары, **Актаныш** районындагы **Чурай** һәм **Чуракай** авыллары, мөгаен, татар халкының батыр угыллары исеме белән бәйледер. Хәзерге Актаныш районында 1747 елдан ук мәгълүм булган **Адай** авылына да, мөгаен, казакъларның Кече җөзендә яшәүче Адай ыруы вәкилләре күченеп, нигез салгандыр. Кукмара районында 1678 елдан ук мәгълүм булган **Адай** авылының да әлеге ыруга мөнәсәбәтле булуы мөмкин. Хәзерге Казакъстан Республикасының **Мангистау** өлкәсендә **(Мангышлак)** хәзер дә Кече җөзнең **Адай** токымы казакълары яши.

Дастан буенча Чура батырның нәсел-шәҗәрәсе болай: **Арыслан**, **Байхуҗа**, **Ир-Түләк**, **Нарык**. Нарык белән **Миңсылудан Чура**, **Аликәй**, **Ислам**, **Канибәк** исемле балалар туа. Аларның социаль чыгышы турында дастанда турыдан-туры дәлил бар. Чура батыр:

«Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын»,

— ди, ягъни үзенең чыңгызый түгеллеген, гади халыктан күтәрелгәнлеген белдерә.

Әсәрдә игътибарга лаеклы тагын бер әйбер бар: Миңсылу Чура батырны сиртмә бишектә тирбәтеп тәрбияли. Казакълар үз балаларын җирдәге бишектә йоклата һәм аны бер яктан икенче якка тирбәтә. Үзбәк һәм кыргызларда да шул рәвешле. Бары тик татар хатын-кызы гына баласын ак биләүгә биләп, *сиртмәле (пружиналы) бишеккә сала*. Аңлашыла ки, Чура батырның (Шора батырның) атасы Кече җөзнең җиде ыру кабиләсендәге тама ыруыннан, ягъни хәзерге казакъ милләтеннән, ә әнисе Миңсылу Урта Идел буеннан, ягъни аның нәсел-нәсәбе хәзерге татарларга нисбәтле. Шунлыктан әсәрнең һәр вариантында да вакыйгалар урыны Казан ханлыгы белән бәйләнешле булу очраклы күренеш түгел.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: «Чура батыр» дастаныннан кала, **«Идегәй»**, **«Кузы Көрпе белән Баянсылу»**, **«Алпамша»**, **«Камбар»** кебек халык авыз иҗаты ядкярләре дә татар һәм казакъ халкының уртак иҗат җимеше. ■

ТУКАЙ — ЯДКЯРЛӘРДӘ

Текстны һәм искәрмәләрне басмага *Рәмил Исламов* һәм *Җәүдәт Миңнуллин* әзерләде

Истәлекнең авторы Габдерахман Хәбибулла улы Кәрам (Рәхмәтуллин) (1878-1947) – театр тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче, Г.Тукайның замандашы һәм якын дусларыннан берсе. Химик карандаш белән гарәп хәрефләрендә язылган (1944 елның 14 апрель) аның бу истәлеге хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр Академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас фондында саклана: 9 ф., 4 тасв., 70 сак. берәмлеге. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә басыла.

ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСЕМДӘ КАЛГАННАР

Габдерахман Кәрам

Мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукай белән без бик якыннан таныш идек. Аның белән якын танышлыкка «Гасыр» көтепханәсе тарафыннан чыгарылган «Аң»[1] журналы зур сәбәпләрнең берсе булды. Мин «Аң» журналының гыйльми секретаре булып эшли идем. Шуңар күрә аның белән бик еш күрешергә туры килә иде. Мәрхүм бик оялчан, бик җуаш кеше иде. Хәтта анда кеше күп була дип, «Гасыр»га да сирәк төшә иде. Мәрхүм гомеренең актык көненә кадәр «Аң»да язышты, ул аның иң кадерле сатрудникгы иде. Иртәгә үләсе дигән көнне «Аң»да иң соңгы шигырен язды. Тукай Казанга килгәндә

[1] «Аң» — нашире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәни (1883-1934) булып, 1912-1918 елларда Казанда ике атнага бер чыккан әдәби, фәнни, сәяси һәм иҗтимагый рәсемле татарча журнал. Барлыгы 123 саны дөнья күргән. Редакция хәзерге Татарстан һәм Каюм Насыйри урамнары чатында урнашкан булган. Ул урында хәзерге вакытта тугыз катлы торак йорт тора, аның адресы: Татарстан ур., 7.

үк авырый иде. Каты авырып Кләчкин балнитсасына кергәч, татар зыялылары, укучылар чиратлашып дежур тордык. Бәхетсезлеккә каршы, ул үләсе көнне мин аның янына бара алмый калдым. Ул мине бик сораган. «Кәрам әфәнде кайда соң?» — дип күзләре белән эзләгән. «Ул нигә кирәк соң, сүзең булса, әйтербез», — дип әйтүчеләргә: «Юк инде, үзенә генә йомышым бар иде», — дип әйткән. Аның шул сүзе минем йөрәгемдә зур төен булып калды. Аны күрми калуыма үкенеп бетә алмадым. Мин ул вакытта: «Китапларыңны миннән барып ал, мин үләм», — дип әйтмәкче булгандыр, дип уйладым. Чыннан да анда минем шактый күп төрек әдәбияты калды. Үзеннән соң ул китаплар югалды. Белмим, иптәшләренә биреп торгандырмы, мәгълүм булмады. Шагыйрь мәрхүм авыруын яшерергә тырыша, ул турыда сөйләргә ярамый иде. «Болгар» нумирында торганда янына менгәндә күп вакытта ятып торган була. «Нихәл?» — дип сорасаң: «Әле менә бу арада салкын тиердем бугай, йөткереп торам», — дип әйтә иде.

Соңгы вакытларда аның янына фәлсәфә сатарга яратучы күп кенә аттистатчылар килеп йөри башлаганнар иде. Алар Тукайга комачаулыйлар, аның күп вакытын алалар иде. Аның янына кайчан гына барсаң да ике-өч егет була иде. Хәтта ул миңа: «Шул дус-ишләр аркасында күпме вакытым әрәм була», — дип зарланган иде. Мин: «Алай булгач, ник аларны кертәсең соң, куалап чыгар, авырыйм, вакытым юк, дип әйт», — дигәч, ул: «Мин алай булдыра алмыйм шул, алар барыбер миннән сорап тормыйлар», — дип әйткән иде. Бервакытны мин барып кергәндә, нумирда өч егет карта уйнап утыралар, үзе бизгәк тотып ята иде. Мин аларның өчесен дә куып чыгардым.

Шагыйрь мәрхүм ривалүтсиун рухлы, яхшы йөрәкле, аптимист бер кеше иде. Шулай да сәгатьләр буенча сөйләшми утыру яки бертуктаусыз көлеп-шаярып тору кебек табигате бар иде.

Без аның белән хатын-кыз мәсьәләсе турында күп сөйләшә торган идек. Ләкин ул хосусый тормышында бу мәсьәләгә артык әһәмият бирми иде. Мин аның яратып йөри торган кызы барлыгын ишетеп, ул турыда сүз ачкач, ул: «Әй, ул минем белән юри генә йөри торгандыр ла. Хатлар язгаласа да, бер дә аермачык бер сүз әйткәне юк», — диде. Шуннан соң, авыр сулап: «И Кәрам иптәш! Мине кайсы кыз яратсын соң, үзем кечкенә, үзем ябык, үзем... (авыру дип әйтмәкче булгандыр инде)», — дип куйды.

Шагыйрь мәрхүм бик беркатлы кеше иде. Кайвакытта бик кызык сүзләр әйтеп куя иде. Мәсәлән, бервакытны: «Кәрам иптәш, кара инде син бу «Мәгариф»тәге («Мәгариф» көтепханәсе) җүләрләрне! Минем бер тапкыр басылган шигырьләремне икенче кат бастырмакчы булалар. Бер басылган әйберне яңадан бастыру нигә кирәк инде! Шуның өстенә тагын акча да бирмәкче булалар. Әле элек басылганы да сатылып бетмәгән, мин аны буш бастырырга риза булган булыр идем», — дигән иде. Мин, аның бу сүзләренә каршы көлеп: «Юк, алар бик акыллылар, менә син үзең җүләр. Син тагын буш бастырырга риза булып куйма», — дип, үзен яхшы гына орыштым. Шуннан аның бу җүләрлеге турында бик озак көлештек.

Бу югарыда язылганнар, билгеле, шагыйрьнең тормышындагы вактөяк фактлар гына. Безнең ике арада күтәрелгән бәхәсләр, фикерләр башлыча шигырь, матур әдәбият турында була торган иде. Баштарак күбрәк төрек әдәбияты турында фикер йөртүләр була иде. Истанбулдан Уральскига качып килгән бер төрек ривалүтсиунирының Тукайга бик зур тәэсире булган. Ул һәрвакыт аның турында сөйли, аның шигырьләрен китерә иде. «Төрек әдибе ул минем остазым, — дип атый, — ул минем дөньяга карашымны киңәйтте, фикеремне ачты», — дип сөйли торган иде. Шуның тәэсире астында булса кирәк,

ул баштарак әсәрләрен дә төрекчәрәк яза иде. Билгеле, бара торгач, ул моны ташлады һәм саф татар телендә яза башлады. Төрек шагыйрьләре турындагы мәсьәләгә килгәндә, ул аларның телләре Анатулы төрекләре аңлый алмаслык дәрәҗәдә тәкәллефле, авыр, эчпошыргыч, дип сөйли. Алар бик артык писсимизмгә бирелгәннәр, бөтен шигырьләре җылау, аһ-фәган белән тулган яки мәхбүбәләренең зифа буйларын, кара күзләрен мактаудан гыйбарәт булып кала.

Шигырь дигәч, әйтерсең лә гыйшыктан гына бәхес ителергә тиеш дип беләләр, һичбер төрле актуаль мәсьәләләрдән бәхес итмиләр, тормыштагы көндәлек әһәмиятле вакыйгалардан ерак торалар, дип сөйли иде. Төрек шагыйрьләре арасында бары тик Мөгаллим Наҗи гына башка шагыйрьләрдән аерыла. Теле садә, күптөрле мәсьәләләргә кагыла. Ләкин ул андый шигырьләренең күбесен француз шагыйрьләреннән икътибас итеп яза, дип сөйли иде. Шушы фикерләрдән соң ул төрек әдәбиятына аз әһәмият бирә, аннан ераклаша башлаган иде.

Рус әдәбиятына килгәндә, Тукай аңар бик зур кыйммәт бирә, Пушкин белән Толстойны артык ярата иде. Ул бервакытны Грибоедовның[2] «Горе от ума» камидийәсен укыганда аның теленең, өслүбенең гүзәллегенә хәйраннар булган. Шуның тәэсире белән ул бу әсәрне тәрҗемә итәргә хәзерләнгән иде. Ул шул турыда минем фикеремне сорагач, мин аның бу турыдагы фикерен куәтләмәдем. Чөнки бу әсәр русның иң югары катлау аристакратиясе турында язылган, шуның өчен бу әсәрнең безнең татар массасы өчен артык әһәмияте булмас, дидем. Шуннан соң русча зур паемалардан кемнең әсәрен тәрҗемә итү муафикъ булыр икән, дигәч, мин аңар Пушкинның «Руслан һәм Людмила» исемле фантастик әсәрен тәрҗемә итүне тәкъдим иттем. Ул моны үзе дә укыган һәм бик яраткан икән. Шуны тәрҗемә итәргә хәзерләнгән иде. Һәм аны, тәрҗемә итеп, «Аң» журналына бүләк итәсе иде. Ләкин әсәр зур булганга, «Аң» да айлык журнал булганга моңа бик артык озакка сузылачагын игътибарга алып, аны аерым китап итеп бастырырга карар бирелгән иде. Ләкин мәрхүмнең гомере вафа итмәде, ул әсәр дөньяга чыкмый калды.

Мәрхүм Тукай церизмга, буржуазийәгә дошман иде. Аның «Яңа Кисекбаш» китабы басылып чыккач, татар байлары, Печән базары сәүдәгәрләре арасында дошманнары шактый күбәйде. Шәмче Вәли, Карәтмән Шакир, Кадыйр Сәйдәшев кебек карагруһлар аны Казаннан кудырырга тырыштылар, аның өстеннән губернаторга данослар ясадылар, имгәткәнче кыйнарга дип шымчылар ялладылар, Казаннан китмәсәң, үтерәбез, дип бүлмәсенә хатлар ташладылар. Шуннан соң Тукай кичләрне урамга чыгып йөрмәс булды, үзенең тормышы өчен чыннан да курка башлады. Карәтмән Шакир дигән Печән базары сәүдәгәре «Гасыр» көтепханәсенә кереп безне сүкте: «Ул Тукай дигәнегез малай башы белән олыларга, голәмага тел тиерә, сез шуны яклыйсыз, аның шәйтан такмазаларын акча түләп бастырасыз, сез акча бирмәсәгез, ул такмазаларын бастыра алмас иде. Сезнең үзегезнең өстегездән губернаторга жалоба бирергә кирәк. Мөселманнар арасында дошманлык тараталар, патшага тел-теш тиерәләр, дип, менеп әйтергә кирәк», — дип дулап чыкты.

Тукай мәрхүм халык яклы, изелгәннәрне яклаучы татар шагыйре иде. Шуңар күрә дә ул һаман чын халык шагыйре булып калачак, үзе үлсә дә, аның шигырьләре мәңгегә безнең арабыздан югалмаячак! ■

[2] Грибоедов Александр Сергеевич (1795-1829) — рус язучысы һәм дипломаты.

ГАЙНӘ ИЛЕНЕҢ МӘГАРИФ КАҺАРМАННАРЫ

Фәһимә Газизова

1919 елның 27 сентябрендә төшерелгән фоторәсемдә башларына татар кәләпүше, өсләренә пөхтә комзол кигән җиде яшь ир-егетне күрәбез. Алар гражданнар сугышы чорында Оса педагогия курсында укыган яшь укытучыларның бер төркеме. Дөрес, курсларда укыганчы ук, алар теге яки бу мәдрәсәдә укып, мулла таныклыгы алган һәм хәлфәлек итәргә яки земство мәктәпләрендә сабак бирергә, күпмедер дәрәҗәдә педагогик тәҗрибә дә тупларга өлгергән булган. Гайнә иле төбәгенә мәгърифәт нуры чәчкән ошбу гаярь егетләргә җентекләп тукталыйк.

* Байавылның мәгарифенә XVIII гасырда ук Батырша нигез салган. Татар-башкорт халкының милли герое, яклаучысы 1744-1745 елларда биредә шәкертләр тәрбияләгән һәм «Ел ярым Гәйнә илендә, Илеш мулла Әтнәшев авылы Байавылда тордым, укыттым», — дип язып калдырган.

Аптуков Мортаза Мостафа улы — Байавылда* укыткан; **Булатов Нәҗип Кашшаф улы** — Түбән авылдан, Искир мәктәбе укытучысы; **Әтигулла Рахмангулов** — Кодаш авылыннан, Байавылда укыткан; **Аптуков Зәки Мостафа улы** — Байавылдан, Кувья мәктәбендә мөгаллим; **Барсаев Мөхәмәтгата Гәрәй улы** — Кодаш мәктәбендә укыткан; **Фаяз Барсаев** — Кодаш мәктәбендә

укыткан; **Әхмәткәшиф Суяргулов** — әнисе Кодаштан, Барда мәктәбе укытучысы.

1918 елның җәендә **Солтанморат Абдусәләмов** тырышлыгы белән Осада ачылган беренче татар укытучылар курсында алтмыштан артык укытучы гыйлем эсти. Шул елда ук Солтанморат ага Барда төбәгенең 31 авылында башлангыч мәктәп ачтыруга ирешә, сентябрь аенда дәресләр дә башлана[1].

Илдә Совет хакимияте урнашканнан соң, Гайнә иленең асыл уллары — белемгә омтылган яшь муллалар, хәрәкәтсез торудан яхшы нәтиҗә чыкмаячагын яхшы аңлаган. Дин сабагын укыту тыела башлагач та, авыр хәлдә калган мулла-хәлфәләргә педагогик курсларны үтеп, революцион рухлы укытучыларга әверелергә мөмкинлек тудырылу, совет мәктәбендә эш урыннары булдырылу, мөгаен, зур сөенеч булгандыр. Әнием **Рангулова (Тугумова) Фатыйма**га да абыйлары Мөхәммәтгата һәм Фаяз Барсаевлар белән бергә бу курсларда укырга тәкъдим булган. Кызганыч, аңа бабам рөхсәт итмәгән.

1930 елның 16 февралендә Барда районы башкарма комитеты президиумы 167 гаиләне (шуларның 44е дин әһелләре) сөргенгә җибәрергә карар чыгара. 1933 елның 7 апрелендә имзаланган карар белән 220 гаилә туган-туфрактан аерылырга хөкем ителә. 1937 елда Эчке эшләр наркомы Н.И.Ежовның 00447 номерлы приказы нигезендә сөргенгә җибәрүнең тәртибе, сроклары һәм масштабы тәгаенләнә. Әлеге фотодагы егетләр — совет чорында районыбызның беренче укытучылары — 1930 елларның корбаны. Аларның нәсел-нәсәбенә, гаилә язмышына җентекләбрәк тукталыйк.

***

Аптуковлар нәселеннән татар-башкорт халкын тәрбияләгән, аң-гыйлем биргән мөгаллимнәр күп чыккан. **Аптуков Вәлимөхәммәт Нәҗметдин улы** (1834-1894) Танып авылында **Хәерзаман хәзрәт** мәдрәсәсен тәмамлый. Аның улы **Аптуков Мостафа Вәлимөхәммәт улы** (1864-1922) Байавылның **Зиннәтулла хәзрәт** мәдрәсәсендә укый. Аннан соң Казан өязе (хәзер Арча районында) Курса авылының **Гатаулла хәзрәт** мәдрәсәсендә белем эсти. Мостафа, атасыннан бер тиен дә матди ярдәм алмыйча фәкыйрьлектә укыган, тормышы

Оса шәһәрендәге укытучылар курсында белем алучылар. Сулдан уңга: Мәмәтхуҗин Шакир – география укытучысы, ..., Казанбаев Габдулла, Аптуков Мортаза, Усманова Рабига

[1] Солтанморат Абдусәләмов 1924-1927 елларда Барда партия райкомының беренче секретаре булып эшли. Кызганыч, 1930 нчы елларда халыкны аң-гыйлемле итү өчен тырышкан кешене «халык дошманы» дип юк итәләр.

Сулдан уңга: Аптуков Зәки, Аптуков Мостафа Вәлимөхәммәт улы, Барсаев Мөхәмәтгата Гәрәй улы

да җиңелдән булмаган. Истәлекләргә караганда, шәкерт, Байавылда укыганда, **Шәңгәрәй Кутлубаев**ка көненә 20 тиенгә урман кисеп, җир әзерләгән (арчыган). Соңрак бу җирне авыл халкы «Шәңгәрәй арчымасы» дип йөрткән. Икенче җәен хатыны **Хәфәсә** белән Елово кырына чыгып урак ура һәм 48 сум акча эшләп кайта. Бу акчаның 25 сумына йорт, калганына башка кирәк-ярак сатып ала. Мостафа мулла, укуын тәмамлагач, Уфага, Диния Нәзарәтенә барып имтихан тапшыра, имам-хатыйп шәһадәтнамәсен ала. Шулай итеп, яшь хәзрәт кышын балалар укыта, мал-туар асрый, җәй көнендә исә тал кабыгы әзерләү, аны сату белән шөгыльләнә.

Мостафаның улы **Мортаза Аптуков** (1894-1975) 1902 елда авыл мәдрәсәсенә укырга керә. 1912-1913 елларда Каенавылга килеп «Мустафин учитель»дә урыс телен өйрәнә. Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, 1914 елда Мортаза хәрби хезмәттән котылып кала. 1915 елны Кодаш авылының имамы **Гәрәй Барсаевның Җәмилә** исемле кызына өйләнә. Аларның шактый мажаралы кавышу тарихы авыл халкы хәтерендә әле дә саклана.

Көннәрдән бер көнне 18 яшьлек бик матур, укымышлы Җәмилә туташны Яматай (Чувашай) авылының бае **Азматов Нигамәтнең Мулланур** исемле улына ярәшәләр. Җәмилә яраткан кешесе Мортазага хат җибәрә. Кияү егет үзе кебек гаярь егетләрне әзерли, Җәмиләдән хәбәр килгәч, ике ат белән Кодашка юнәлә. Күңеленә егет дәрте кергән кыз, комган тотып, берничә мәртәбә тышка чыга. Энекәйләре Гата һәм Газиз сизенә, әмма өйдәгеләргә сатмый. Соңгы чыгуыннан соң Җәмилә өйгә керми — сөеклесеннән «урлата». Аның өйдә юклыгын 3-4 яшьлек сеңлесе Мөнибәнең: «Апа юк!» — дип, елый башлавыннан беләләр. Гәрәй бабай, ат җигеп, Байавылга чыгып чаба, килеп җитеп Мостафа мулланың капкасын дөбердәтә: «Җәмилә мондамы?» — дип сорый. Аны йортка керергә чакыралар. Ул керми, кызын чакыра. Җәмилә: «Мин кайтырга килмәдем!» — дип әйтеп карый, ләкин ата сүзе нык була. Җәмилә чыгып ат арбасына утырырга мәҗбүр ителә. Ата, Кодашка кайтып җиткәнче аның белән сөйләшми, кучерена кызны карт әнисе Сабрыйга илтеп куярга куша. Җәмилә, биредә бер айдан артык торганнан соң, үз сүзен әйтә: «Әгәр минем теләгемә каршы килсәләр, мин бу якты дөньяда яшәмим, монда елга якын, бәкесе уелган!» — ди. Ата-ана кызны туй ясап сөйгәненә бирергә мәҗбүр була. Җәмилә абыстай өендә кыз балаларны укырга-язарга өйрәтә башлый.

1916 елның язында, Азматов Нигамәтнең дәгъвасы буенча, Мортазаны солдатка алалар. Ул, 1917 елның февраль революциясеннән соң гына, 14 ай хезмәт итеп туган авылына кайта.

Мортаза белән Җәмилә, 1917 елгы революциядән соң, укытучылар курсларында белем алып, балалар укыта. 1922 елда, атасы Мостафа үлгәч, мулла эше Мортазага күчә. Тормышы

фәкыйрь... Шуның өстенә 1929 елда муллалыгын ташларга мәҗбүр була һәм бу турыда газетада игълан итә, 1929-1932 елларда Пермьнең бер заводында эшли. Мортазага ияреп башкалар да муллалыкны ташлый.

Аптуковлар, бар мал-мөлкәтләрен тартып алганнан соң, сыену урыны эзләп авылдан чыгып кача. Гаилә башлыгы Татарстанның Чаллы районында эшли башлый. Соңрак Башкортстанның Дүртөйле районы МТСында кассир, «Агыйдел» колхозында бухгалтер вазифаларын башкара, авыр елларда да югалып калмый. Мортаза белән Җәмиләнең 5 баласы туа. Балалары да ата-ана назыннан мәхрүм булмый, ачлыктан интекми. 1942 елда исә хатыны Җәмилә бакый дөньяга күчә.

Мортаза бабай 1946 елда гына туган-үскән, мәгърифәтле Байавылын, ямьле Әмҗе буйларын сагынып кайта. Туган ягында колхоз бухгалтеры булып эшли, аннан промартельдә эшләп пенсиягә чыга. Каенавылның зыялы, укымышлы аксакал карты 1975 елда, 81 яшендә бакый дөньяга күчә. Кабере Каенавыл зиратында.

Мәсгут Мортаза улы Аптуковны (1916-1993) әти-әнисе укытучы итеп тәрбияләп һич кенә дә ялгышмаган. Ул аларның ышанычын аклый. Заманында Мәсгут ага да Каенавылның мәртәбәле мөгаллиме булды. 1942-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан соң «Урал» колхозында партоешма җитәкчесе булып эшли. Мәсгут ага гаять укымышлы, ягымлы, горур кеше иде.

Мәсгут аганың хатыны **Мәрьям апа** аз сүзле, җитди укытучы булып истә калды. Без аның белән 1966 елда Каенавыл мәктәбендә башлангыч классларны бергә укыттык. Укыту-тәрбия эшен аларның кызы **Венера Аптукова** да (1939) дәвам итте.

Мостафаның икенче улы **Зәки Аптуков** та сөргенлектән котыла алмый. Аның яшеренгән урынын тиз ачыклыйлар һәм кулга алып, Уралның бер заводына озаталар. Зәки ага заводта алты ел эшләп, авылына кайта. Туганы Мортаза шикелле үк, ул да исәп-хисап һөнәрен үзләштерә. Озак еллар Байавыл промартелендә бухгалтер булып эшли.

***

Булатов Нәҗип Кашшаф улы — җиде якташы арасыннан иң яше. 1898 елда Түбән авылның указлы мулласы **Кашшаф Булатов** гаиләсендә дөньяга килә. 12 ел укып, революция алдыннан Солтанай мәдрәсәсен тәмамлый. Оса укытучылар курсына җибәргәндә Нәҗипкә нибары егерме яшь була. Яшь мөгаллим 1920-1921 елгы ачлыктан соң Искилде, Искир, Түбән авыл башлангыч мәктәпләрендә балаларга гыйлем һәм тәрбия бирә.

1933 елны әтисе Кашшаф мулланы Карабашка сөргенгә җибәрәләр, 1938 елны гына аксакалга, көч-куәте бетү сәбәпле, Бардага кайтырга рөхсәт ителә.

Улы Нәҗип Чиләбе өлкәсендә шахтага эшкә урнаша. Сугыш алдыннан забойда эшли. Зур бәхетсезлек кинәт килә: күмер ватканда, күзенә таш тиеп, Нәҗип ага дөм сукыр кала. Шуннан соң гаиләсе белән Куеда поселогына килеп урнаша. Ачык йөзле, киң күңелле хуҗаның өе авылдашлары өчен кунак йорты, мәгърифәт үзәге була. Нәҗип бабай чирек гасырдан артык якты дөньяны күрүдән мәхрүм булып яши. 1960 нчы елларда гына врачлар аның күзенә катлаулы операция ясый һәм бер күзе күрә башлый. Бу олы шатлык онытылмас бәйрәмгә әверелә. Шул елларда Нәҗип Булатовның хатыны, олы йөрәкле **Фасиха апа** «Сукырлык бәете»н иҗат итә.

Әтисенең мөгаллимлек эшен **кызы Кадрия** дәвам иткән. Кадрия апа 1962 елда Пермь пединститутын тәмамлый. Җиде ел Куеда районының Кон-Завод авылында укыта, кырык ел Куеда поселогы мәктәпләрендә карт әтисе һәм әтисе эшен дәвам итеп, 47 ел балаларга белем бирә.

***

1933 елда мөгаллим **Атигулла Рахмангулов**ны да гаиләсе белән Карабашка сөрәләр. Бу игелекле шәхеснең исемен ишетүгә чишмә каршындагы ике катлы, биек, матур йорты, утырткан агачлары күз алдына килә. Без шул йорт тирәсендә, тауда уйнап үстек. Атигулла йортында озак еллар колхоз идарәсе эшләде.

***

Әхмәдгали Суяргулов Кодашның указлы мулласы **Җиһанша хәзрәт кызы Фәхрикамал** (бабамның бертуган апасы) абыстай белән гаилә кора. Әхмәдгали хәзрәт Бардада мәдрәсәләр комплексы төзи, Сәпәй елгасы буенда умарталык тота. 1894 елда туган улы **Әхмәткашиф** та әтисе төзегән мәдрәсәне тәмамлый. Шуның өстенә Әхмәтгали улына дөньяви фәннәрдән дә дәрес бирә, аны зур тормышка әзерли. Әхмәтгали һәм **Әхмәтгазый Суяргулов**лар Бардада икенче һәм өченче мәхәллә мәчетләре имамы булганнар. Әхмәткашиф берникадәр вакыт Әхмәтгазый Суяргулов имамлык иткән өченче мәхәллә мәчетендә мәзин вазифасын башкара. 1918 елда Осада педагогик курсны тәмамлагач, көндез мәктәптә, кичен ликбезда укыта. 1920 еллар ахырында Әхмәдгали хәзрәтне 3 баласы белән урамга куып чыгаралар. Имеш, советка каршы эш алып бара, хөкүмәт салымнарын түләми. Ә бу вакытта үзенең йорты төзелеп тә җитмәгән була.

«Хәзрәтнең улы совет мәктәбендә укытырга тиеш түгел», — дип Әхмәткашифны да укыту эшеннән чыгаралар. 1932 елда ярты гектар җирен тартып алалар. Мәзин булган, алыпсатарлык иткән, дип гаеплиләр. Орлыгын сорый башлагач, алып бетерделәр, 1 кг гына орлык бирә алам, дип җавап кайтарган Әхмәткашифны Карабашка сөргенгә җибәрәләр. Бу вакытта **хатыны Мәрьям** дүртенче баласына йөкле була. Дүрт баланы җылытырга, ашатырга утын да, ризык та юк. Ишегалдыннан сыерны алып чыгып киткәндә балалар да, ана да үксеп елап кала. Карабашка китәр алдыннан, Мәрьям апага күршеләре сохари әзерләп бирә, ләкин юлда анысын да урлата. Алар мең газаплар белән әтиләре янына килеп җитәләр. Кечкенә баласы озак яшәми, үлә. Әхмәткашиф Суяргулов исә шахтада 12шәр сәгать руда төялгән вагонетка этә. Аяклары нык авырта башлагач, балта остасы булып эшли башлый.

«Әни белән без күрше рус авылларына хәер җыярга да баргаладык. Әни,

Кодаш мәктәбе (Гәрәй мулланың йорты)

кар-яңгыр, салкын җил булуга карамастан, тау кебек өелгән руданы сортларга аера иде. Тиздән салкын тиеп әни авырды. Әти, Карабаш мөселманнарын туплап, һич яшеренми намаз укый иде. Бер әләкче, әтине намаз уку оештыруда гаепләп, донос яза. 1938 елның җәендә әтиебезне кулга алдылар. Әнинең озак кына елый-елый арба артыннан йөгереп барганы күз алдымда тора. Әтине соңгы күрүебез шул булды... 1939 елның 18 декабрендә 41 яшендә әни дә үлде. Мөнирә апаны ФЗОга билгеләделәр, Галимне — детдомга. Галим, техникум тәмамлап, Воркута шахтасында эшли башлады. Шахтада метан шартлый, Галим шунда үлә». Бу истәлекне **Шәфика Кашиф кызы** язып калдырган. Рәхмәт яусын туганыма.

Әхмәткашиф Суяргулов Чиләбе төрмәсенең хастаханәсендә 1939 елның 27 февралендә үпкә туберкулезыннан вафат була. Кайда җирләнгәне билгесез. 1973 елда гына суд аны гаепсез дип таный. Кызы Шәфика Бардада телефонист булып эшләде. Оныгы **Хәмдия Нургали кызы** (Ланикина) Мәскәү университетын тәмамлый, гаиләсе белән Украинада яши.

***

Карабаштан кулга алганнарның кайберләрен Свердловскига китерәләр. Көннәрдән беркөнне Свердловски төрмәсенә ябылганнарны шәһәр читенә алып чыгып аталар. Атылганнар арасында Кодаштан **Барсаев Габдулла** абый да була. Габдулла абый Кодашта кешеләр язмышын хәл иткән «тройка» әгъзасы булса да, үлем җәзасыннан котылып кала алмый. Свердловски (Екатеринбург) шәһәре янындагы зур каберлектә якташымның да исем фамилиясе язылган. Тарихыбызда мондый ялгышлыклар, җәзалаулар кабатланмасын!

Кодаш авылының указлы мулласы **Гәрәй Барсаев**ның өлкән улы **Мөхәммәтгата**, аның туганы **Фаяз Барсаев** кебек гомерләрен гыйлем эстәүгә генә багышлаган игелекле шәхесләр — укытучылар да кара исемлеккә эләгә.

Кодашның имам-хатыйбы Мөхәммәтгәрәй Ибниҗәмин улы Барсаевның Пермь архивында үз кулы белән 1895-1917 елларда язып барган метрикә кенәгәләре саклана. Аларда эре, матур гарәп хәрефләре белән туу, үлү, өйләнешү актлары теркәлгән. Мин кенәгәләрнең матурлыгына, чисталыгына таң калдым, күзләремә яшьләр килде. Олы туганым үзеннән соң нинди матур ядкяр калдырган бит! Истәлекләргә караганда, Гәрәй мулла ачлы-туклы йөргән балаларны җыеп ашата торган булган, аларга **Ягафар мулла** мәдрәсәсендә белем һәм тәрбия биргән. Мөхәммәтгәрәй мулланың өлкән улы Мөхәммәтгата абыйның кызы **Җәмилә апа** да (башта Кодашта, соңрак Байавылда) гомере буе балалар укытты.

Кешеләргә тугры һәм намус белән хезмәт иткән Гәрәй Барсаевның 8 балалы гаиләсен тулысынча талыйлар. Өлкән улы Мөхәммәтгата һәм әтисе Гәрәйнең гаиләләре 1929 елда туган җирдән кубарылалар. Фаяз Барсаев та, авылдан кууларын көтеп тормый, туганнары юлын сайлый.

Мөхәммәтгәрәй мулла белән Таныптан Мансуров Гата хәзрәтнең Оса шәһәрендә кирпечтән беркатлы зур кибете дә булган. Бабамның Кодаштагы бер йортын Барданың Куйбышев урамына китереп салалар. Бу ике катлы зур йорт 2014 елга кадәр тулай торак булып хезмәт итте. Ә Кодаштагы төп йортында башлангыч мәктәп оештырылды. Без шул мәктәптә укып, уйнап үстек. Йорт хуҗалары кайдадыр тилмереп йөргәндер, ачлык-мохтаҗлыкта интегеп яшәгәндер, урыннан-урынга күченергә мәҗбүр булгандыр.

Кызганыч, без укыган мәктәпне, Кодашның иң матур тарихи йортын 2010 елда сүтәләр. Авылыбызда берничә ел инде мәктәп юк. Бу теләсә кайсы авыл өчен зур фаҗига, йөрәкне сызлата торган күренеш. Туган авылым яшәрсен, мәктәп тә ачылсын иде, дигән теләктә калам. ■

РУСИЯДӘ ГАРӘБИ ХӘРЕФ ИЛӘ БАСМАЧЫЛЫК*

Шиһаб Әхмәр
(1882-1966)

Азиатский матбагасы

Казан шәһәре руслар тарафыннан алынганның соңында Казан халкы бик авыр хәлләргә төшеп, бик кысынкылыкта калмышлардыр. Бу агырлыклар вә бу кысынкылар боларга тәэсир итеп, болар гаять дәрәҗәдә каралмышлар, мәктәп-мәдрәсә, уку вә укыту дигән нәрсәләрнең исемнәрен онытырга якынлашмышлардыр. Бар укыган нәрсәләре дә күңел сабакларыннан, догалыклардан, әлифбадан гыйбарәт булып, китап юклыгы сәбәпле боларны такталарга язып укырга яисә күңел сабагы итеп агыздан укырга мәҗбүр булмышлардыр. Шуннан соң ул заманның аңлырак татарлары, бу хәлләргә ачынып, Русиянең императорларыннан беренче Александр[1] җәнабларга гариза биреп, үзләренең әлифбаларын вә дин китапларын басар өчен Казанда бер матбага булындыруны рәҗа итмешләрдер[2].

Шуннан соң Казанда, гимназия йортында бер матбага ачылып, шул матбагага Петербургтагы Сенат матбагасыннан ике станок вә берникадәр гарәпчә хәрефләр күндерелмештер. Вә матбага Азиатский типография («Шәрык» матбагасы) исемендә ачылмыштыр. Шуннан соң мөселманнар бу матбагада үзләренә кирәк булган дини китаплар бастыра башламышлардыр. Бу матбага 1800 нче сәнәләрдә ачылып, 1802 нче сәнәләрдә Габделгазиз Бурнашев дигән кешенең идарәсенә тапшырылмыштыр. Соңра, Бурнашев шул ук сәнә 26 нчы ноябрьдә мөдирлектән газел ителеп[3], бу матбага, мәгълүм мөддәттә[4] бәһасен түләп бетерү шарты илә, Казан байларыннан Апанаев җәнабларына тапшырылып, 1807 нче сәнәгә кадәр аның тасрифында калмыштыр.

Шуннан соң бу матбага 1829 нчы сәнәгә кадәр Азиатский матбага исемендә үз башына идарә кылынып килсә дә, Казанда 1802 нче сәнәдә ачылган университет матбагасының мөдире 1819 нчы сәнәдә министрга язган отчетында: «Азиатский матбага машиналары вә мәсариф[5] җәһәтеннән һәрникадәр университет матбагасыннан ким булмаса да, идарәсендә булган косурлыклардан[6] университет матбагасы китергән файданы китерә алмый», — дип шикаять иттегеннән, 1829 нчы сәнәдә хөкүмәтнең фәрманы илә Азиатский матбагасының мөдире газел кылынып, бу ике матбага

[1] Биредә Павел беренче булса кирәк, чөнки типография ачылган елда һәм аңа кадәр ул идарә итә.
[2] Рәҗа итү — үтенү.
[3] Газел ителү — эшеннән алыну.
[4] Мөддәт — срок.
[5] Мәсариф — чыгым.
[6] Косур — кимчелек.

*1909 елда Ш.Әхмәров Иван Харитоновның кырык еллык юбилее уңаеннан «Матбагачылык тарихы» дигән китап бастыра. И.Н.Харитоновның эшчәнлеген, Европада, Русиядә китап басу һәм гарәби хәреф илә басмачылык тарихын бәян кылган әлеге китаптан кайбер бүлекчәләрне сезнең хозурга да тәкъдим итәбез.

берләштерелмешләр вә Азиатский матбага исеме тәмам бетерелеп, университет матбагасы дип йөртелә башламыштыр. Бу матбага безнең сүнеп беткән әдәбиятыбызны аз булса да яңадан торгызырга сәбәпче булып, милли матбугатыбызның нигезен салучы бер матбага булганлыгыннан, без татарлар өчен моның хидмәте[7] бик кыйммәтле вә шаян[8] тәкъдир ителергә тиеш бер хидмәттер.



Харитонов матбагасы

Безнең милли матбугатыбызга иң күп хезмәт иткән вә аны нәзакәт вә матурлык җәһәтеннән башка милләтләрнең матбугатына якынлаштырган бер матбага бар исә, ул да Казандагы Харитонов матбагасыдыр. Бу матбага 1896 нчы сәнәдә мөхтәрәм И.Н.Харитонов тарафыннан тәэсис ителмештер. Бу матбага, әүвәл ачылганда гаять дәрәҗәдә кечкенә булып, барлык тормышы бер машина вә алты наборщиктан гына гыйбарәт булса да, хуҗасы Харитоновның иҗтиһады вә гайрәте сәясендә бик аз заман эчендә тәрәккый итмеш, 1898 нче сәнәдүк бу матбага хозурында литография (ташбасма), 1899 нчы сәнәдә словолитня ачылмыштыр.

Шуннан соң бу матбаганың хуҗасы Харитонов, татар матбугатына аерым сурәттә әһәмият биреп, аны ислях итәргә керешмеш вә хаттатларның күрсәтүләре буенча төрле шәкелдә гарәп

Ш.Әхмәровның И.Н.Харитонов лито-типографиясендә басылган (нашире – «Сабах» көтебханәсе) «Матбагачылык тарихы» китабы. 1909 ел

Харитонов матбагасының идарәсе

[7] Хидмәт — эш, хезмәт.
[8] Шаян — тиешле дәрәҗәдә.

Газета һәм мөселманча хәреф җыю бүлмәсе

хәрефләре кисеп, әүвәлдә булмаган бик күптөрле хәрефләр ясап чыгармыштыр. Ачылган көннән бирле бу көнгә кадәр Харитонов матбагасында елның елында хәдсез-хисапсыз ислам әсәрләре басылып чыкмакта, бу көнге көндә бу матбагада басылган ислам әсәрләренең гадәде[9] 2 000 000 га кариб[10] саналмактадыр.

Басып чыгарган әсәрләре дә бу көнгә кадәр Русиядә басылган ислам әсәрләренең иң нәфисләреннән булып, хәзергә кадәр Русиядә бунын эшенә каршы килерлек һичбер эш күрендеке юктыр. Милли матбугатыбызны тәртипкә куйган вә аны башка милләтләрнең матбугатларына тоташтырган матбага, һич шөбһәсез, Харитонов матбагасыдыр. Бу матбага башта Казанның Городовой пассажында, 14 нче номерлы кибеттә ачылып, 1908 нче сәнәгә кадәр шул урында дәвам итмеш. Хәзер исә Воскресенский урам чатында, Казанский урамда, Харитоновның үз йортындадыр.

Бу матбага хәзер Казанда гына түгел, бәлки бөтен Волга вә Кама буендагы матбагаларның иң зурысыннан вә иң могтәбәрләреннәндер. Матбаганың эчендә бары 130 кеше хезмәт итмәктә булып, мәҗмүгысы[11] алты бүлмәдән гыйбарәттер. Беренче бүлмәсе печатный (баса торган) бүлмә булып, бу бүлмәсендә 5 баса торган зур машина, 2 американка, 1 бастункә булып, көненә 50000 кадәр нөсхә басып чыгарырга көче җитмәктәдер. Икенче бүлмәсе наборный (хәреф җыя торган) бүлмә булып, бу бүлмәдә русча китаплар җыелмактадыр. Өченче бүлмәсе газетный (газета җыя торган) һәм татарский наборный (татарча хәреф җыя торган) бүлмә булып, бу бүлмәдә фәкать газета эше һәм ислам әсәрләре генә җыелмактадыр. Дүртенче бүлмәсе литографский (ташбасма) бүлмәсе булып, бу бүлмәдә янә дә ике данә машина, ике данә литографский станок бардыр. Бишенче бүлмәсе словолитня (хәреф коя торган) бүлмәдер ки, бу бүлмәдә 4 хәреф коя торган машина булып, сәнәви 500 пот кадәр хәреф коеп чыгарырга

[9] Гадәд — сан.
[10] Кариб — якын.
[11] Мәҗмүгысы — барлыгы.



Американский зал

көче җитмәктәдер. Алтынчы переплетный (китап төпли торган) бүлмәдер ки, бу бүлмәсендә тимерчыбык илә тегә торган 3 машина булып, берсе конторский кенәгәләр тегәр өчен зур, вә калган икесе кечкенә китаплар тегәр өчен кечкенәләрдер. Ике зур пресс (кыса торган машина) булып, башка кирәк булган төрле машиналардан гыйбарәттер.

Шәрәфләр матбагасы

Шәрәфләр матбагасы, Казандагы мөселман матбагаларының икенчесе буларак, 1906 сәнә 13 нче ноябрьдә ачылмыштыр. Яшь борадәран Шәрәфләр вә иптәшләре тарафыннан ачылган бу матбага татар матбагалар арасында үзен тиз күрсәтергә муаффәкъ булды[12]. Матбагаларыбызның иң кирәкле вакытында эшкә башлап, кыска гына вакытта үзләренең матбагасында басылып чыккан нәрсәләрен һәр җирдә күрергә мөмкин, һәр җирдә исемне ишеттерер дәрәҗәсенә китерделәр. Матбагаларында басылган нәрсәләр гомумән халыкның соңгы теләвенә муафыйк яңа әдәбият булып, яңа китаплар алар матбагасында басылып чыга башлады. Ләкин кызып кына эшләп, көннән-көн эшләрен гүзәлләштереп барганда, 30 июньдә Казан губернаторының әмере илә матбага печатьләнеп, матбагада һәммә эшләр шул көенчә юлда калды.

1906 сәнә 13 ноябрьдән 1908 сәнә 30 июньгә кадәр бу матбагада күптөрле китап басылып чыкты. «Казан мөхбире», «Әхбар» газеталары һәм «Тәрбия» журналы бу матбагада басыла иде. Матбага, 5 ай ябылып торганнан соң, «Үрнәк» исемендә яңадан ачылып, иске хәлендә дәвам итә башлады. 1908 сәнә беренче ноябрьдән 1909 сәнә 1 нче сентябрьгә кадәр бу матбагада төрле китап басылып чыкмыштыр.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[12] Муаффәкъ булды — иреште.

АВЫЛ ТАРИХЫН ЯЗЫЙМ, ДИСӘҢ...*

Нурулла Гариф

Авылларыбыз тарихы әле тулаем язылмаган. Килер бер көн һәм бу эш хакимият югарылыгында хәл ителер. Гадәттә ошбу тарихны язу эшенә шул авылның зыялы шәхесе алына. Авыллар тарихы төрлечә бәяләнә. Туасы көн турында уйланулар да, бүгенге халәт-язмышыбызны барлап, уйлар йомгагының кирегә – үткәннәргә таба тәгәрәгәннәре дә бар.

Авыл тарихын язганда еш кына олы яшьтәге якташларыбыздан ишеткән риваять-сөйләмнәргә игътибар итәбез. Аларда – үткәннәр кайтавазы. Шул ук вакытта һәр авылның саллы документлардан гыйбарәт бай мирасы да бар. Авыл тарихын язганда Русия дәүләтенең борынгы актлар архивы *(РГАДА, Мәскәү, Б.Пироговская 17)*, Татарстан Республикасының Милли архивы *(ТР МА, Казан, Кави Нәҗми урамы 7)*, Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге *(Казан, Кремль)*, Башкортстан Республикасының Үзәк архивында *(ЦГИА РБ, Уфа, Карл Маркс урамы, 4)* сакланучы документлар ярдәмгә килә.

Без яшәгән төбәктәге географик шартлар еллар дәвамында үзгәрмичә сакланган. Бу үзенчәлек җир бүленешенә бәйле документларда чагыла *(ТР МА. Фонд. 324)*. Хәзерге Татарстан

* Республикакүләм татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыенында төбәкне өйрәнүче галим, мөгаллим, тарих фәннәре кандидаты Нурулла Гариф үзенең бай эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Аның чыгыш-мәкаләсен сезнең хозурыгызга да тәкъдим итәбез. – *Редакция.*

ОТПУСКЪ

МИНИСТЕРСТВО
Внутреннихъ Дѣлъ.
КАЗАНСКІЙ
ГУБЕРНАТОРЪ.
ПО КАНЦЕЛЯРІИ.
7 Іюля 1913 г.
№ 7866.
Г. Казань.

По Строительному Отдѣленію.

Казанскому Губернскому Правленію.

Центр. Архив. Управ. ТР
СПЕЦИАЛЬН. ОТД.

Въ виду полученныхъ мною свѣдѣній объ опасномъ состояніи Сумбекиной башни и башни Тайницкой, имѣющей проѣздъ изъ Кремля къ р.Казанкѣ, предлагаю Губернскому Правленію распорядиться безотлагательнымъ осмотромъ этихъ сооруженій съ цѣлью установленія, насколько они представляются безопасными и составленный актъ осмотра съ со-

Күп очракта җиде-сигез буын эчендә авыл халкының тулаем диярлек туганлашып бетүе ачыклана. Туганлык хисе бүген дә авылдашларны үзара якынайтыр иде. Татарга җиде буын бабасын белү фарыз да бит әле ул.





җирлегенә нисбәтле беренче карталар 1795 елгы 5 нче ревизиядән соң сызылган. Аларда авыл урамнары, юлларның урнашуы, елгалар, тегермән буасы, кыр, болын, урман чикләре билгеләнгән. Җир бүленешенә бәйле документларда авылның яшәеше, кешеләренең саны һәм аларның эшчәнлеге турында төрле мәгълүмат бар.

Авыл тарихына нисбәтле башка документлар тупланмасында *(81 фонд, 2 тасв.)* йорт хуҗаларының исемлеге, йорт урыннары план-схемада күрсәтелгән. Әлеге төсле карталардан авыл белән янәшә булган елга, тегермән буаларын, күл, чишмә, күпер-басмалар, юлларны күрергә мөмкин. Мәчет, мәдрәсә, зират, базар урыннары, бакчалар шартлы билгеләр белән билгеләнгән. Янган йорт, каралты-кура чикләре сызылган, яңаларының нинди тәртиптә төзелергә тиешлеге күрсәтелгән һәм алар өчен урын тәгаенләнгән. Җир бүленешенә бәйле документларда авыл тирәсендәге елга, болын, урман һәм башка географик объектлар турында хәбәр ителә. Аларның тарихы күп очракта Казан ханлыгы һәм аннан да элгәре чорга тоташуы ачыклана.

Авылларыбыз тарихына бәйле документлар Мәскәү архивларында да үз тикшерүчеләрен көтә. Аларның заказ белән электрон күчерелмәләрен дә кайтартырга мөмкин. РГАДАның 1355 нче фондында борынгы авыл тирәсендәге табигый байлыкларга икътисади тасвирлама биргән кенәгәләр тупланган. Кенәгәләрдә авыл тирәсендәге елгаларның, чишмә-күлләрнең атамасы, аларның киңлеге, тирәнлеге язылган, балыкларның исемнәре теркәлгән. Урман мәйданы, андагы агач, җәнлек, кош атамалары санала. Чәчүлек җире (уңайлы һәм уңайсызга бүленеп), печәнлек, шәхси йорт-җирнең биләгән мәйданы күрсәтелгән. Авыл тирәсендәге завод, анда нәрсәнең күпме күләмдә чыгарылуы һәм кая озатылуы, тегермәндә тартылган игеннең күләме, тегермәннең эш вакыты теркәлгән. Авыл халкының һөнәре, нинди кул эшләре белән шөгыльләнеп көн күрүе турында да мәгълүмат бар.

Авыл тарихын язганда халык санын алу документларын читләтеп узу мөмкин түгел. Нәсел-нәсәп тамыры белән күпләр кызыксына**. Ревизия документлары (ревизские сказки) ярдәмендә нәсел чылбырын җиде-ун буынгача тирәнәйтергә мөмкин. 1710-1858 елларда барлыгы 10 ревизия уздырыла.

Ревизия кенәгәләре белән танышканнан соң *(РГАДА, Ф.350, (1710-1763 еллар); ТР МА, Ф.3, (1818-1858 еллар); ЦГИА РБ, Ф.И-138, тасв. 1, (1797-1867 еллар; тасв. 2, 1795-1863 еллар)* авылда яшәүчеләрнең шәҗәрә агачы барлыкка килә. Күп очракта җиде-сигез буын эчендә авыл халкының тулаем диярлек туганлашып бетүе ачыклана. Туганлык хисе бүген дә авылдашларны үзара якынайтыр иде. Татарга җиде буын бабасын белү фарыз да бит әле ул.

Халык санын, нәсел-нәсәпне ачыклаганда, 1830-1936 елларда муллалар тарафыннан язып барылган метрикә кенәгәләре дә ярдәмгә килә *(ТР МА, Ф.4)*. Туу, вафат булу һәм никахлашу турындагы мәгълүмат теркәлгән кенәгәләр гарәп графикасында, иске татар телендә язылган. Шулай ук аларда яңа туган бала һәм никахлашучы яшьләрнең үз һәм ике яктан да ата-аналарының исем-шәрифе, калымның күләме, вафат булган очракта кешенең нинди авырудан бакый

** Журналыбызның 2015 елгы май санында Балтач районы Карадуган авылында яшәгән төбәк белгече, мөгаллим Бакый ага Зыятдиновның (1930-2014) татар нәсел-шәҗәрәләрен өйрәнү тәҗрибәсе турындагы «Нәсел шәҗәрәләре» исемле саллы мәкаләсен бастырган идек. Шәҗәрә төзергә ният кылучылар өчен шуны укып чыгарга киңәш итәбез. — *Редакция.*

Метрикә кенәгәләре генә дә унар килограмм авырлыктагы калын китап рәвешендә төпләнеп, дистәләрчә томда саклана. Әлеге эш кенәгәләрендәге йөз меңнәрчә документта татар тарихы – әби-бабаларыбыз язмышы.

дөньяга күчкәнлеге турында мәгълүмат теркәлгән.

Мәчет-мәдрәсә һәм мәхәллә авыл тормышының үзәге булып торган. Архивларда мәчет төзелешенә бәйле вакыйгалар, авыл җыеннары турында мәгълүмат, мәчет-мәдрәсә планы, муллаларга кагылышлы документлар тупланмасы, аларның фотосурәтләре дә саклана *(ТР МА Ф.2, тасв. 2, 7, 4, 14, һ.б.)*. Әлеге документларда авыл җыенында кабул ителгән төрле карарлар да бар. Авыл халкының исемлеге дә теркәлгән.

Руханиларның язмышы да гыйбрәтле, игътибарга лаек. Архив документларында аларның революциядән соңгы ачы язмышы да чагылыш таба. Кенәгәләрдә мәчетләрне җимерү, манараларны кисү вакыйгалары да тәфсилләп сурәтләнгән *(ТР МА Ф. 732, тасв. 6; Ф.3610, тасв. 5, һ.б.)*.

Башкортстанның Үзәк архивындагы иң әһәмиятле документларның берсе – Диния Нәзарәтенең фонды *(ЦГИА РБ, И-295)*. Бирелдәге 15 тасвирлама дистәләрчә томнан гыйбарәт. Аларда барлыгы 71128 эш кенәгәсенең исемлеге тупланган. Архивта, заманында Рәсәй империясенә кергән Финляндиядән алып, Татар бугазынача урнашкан мәчет һәм дин әһелләре, авыл мәхәлләсе эшчәнлегенә бәйле эш кәгазьләре тупланган. Аларда дини тормыш, мәхкәмә эшләре, авыл-мәхәллә тарихы һәм анда көн күргән мөселманнарның яшәү-көнкүреше чагылыш тапкан. Метрикә кенәгәләре генә дә унар килограмм авырлыктагы калын китап рәвешендә төпләнеп, дистәләрчә томда саклана. Әлеге эш кенәгәләрендәге йөз меңнәрчә документта татар тарихы – әби-бабаларыбыз язмышы.

Авылның барлыкка килү вакытын билгеләгәндә археологик һәйкәлләр, зиратта саклануы ташъязмалар да ярдәм итә. Татарстан Республикасында 5 меңгә якын археологик һәйкәл бар. Шуның 300е ханлык чорына нисбәтле. Болгар, Алтын Урда, яисә соңрак дәвергә караганнарын да исәпкә алсаң, 1000нән дә артып китә. 700гә якын авылның Казан ханлыгы чорындагы яшәешен теркәгән документлар да бар *(РГАДА. Ф.1209, кн. 152.)*. Халык саны ревизия кенәгәләренә кадәрге чыганакларда да теркәлгән. Авыл тарихы белән фәнни рәвештә шөгыльләнергә теләүчеләр өчен башка төр документлар, тарихи язмалар да кызыклы мәгълүмат бирә *(Ф.350. тасв. 1, эш кн. 1102, 1678 ел, һ.б.)*.

Революциядән соңгы авыл тарихы узган гасырның 30 нчы елларындагы район, төбәк газеталарында ачык чагыла. Авыл советы, күмәк хуҗалыклар оешуга бәйле мәгълүматлар аерым кенәгәләрдә саклана *(Ф.2763, 3214, 1104 һ.б.)*. Документларда шул чорда ачылган мәктәпләрнең башлангыч тарихлары да теркәлгән *(Ф.1105, 5318 һ.б.)*.

Үз авылыңның үткәнен күрше-тирәдәге торак-пунктлар тарихыннан аерып карап булмый. Әлбәттә, документлар белән эшләгәндә аларның тарихына да игътибар юнәлтү мәслихәт. Бу очракта үзеңнең туган авылыңа бәйле мәгълүматлар ешрак та табыла әле.

Без яңарыш чорында яшибез. Киләчәккә өмет баглап, яшь буынны тәрбияләгәндә, үткәнгә, әби-бабаларыбыз яшәгән дәвергә караш тоту бик мөһим. Кешене хәтер яшәтә. Милләтнең тарихи хәтере кыска булса, аңа инкыйраз, юкка чыгу куркынычы яный. ■

ИСКЕ ДЕМОКРАТИЯДӘН ЯҢАСЫНА АТЛАГАНДА

Фоат Садриев

2009 елда «Ватаным Татарстан» газетасының җомга сәхифәләрендә Фоат Садриевның «Авылдан хатлар» исеме астында публицистик язмалары басылып барды. Шул ук елда ул язмалар укучылар соравы буенча аерым китап булып та басылып чыкты. Автор, авылның совет чорыннан алып бүгенге көнгәчә яшәешен күздән үткәреп, бик җитди проблемалар күтәрә, аларны чишү юлларын күрсәтә. Хөкүмәт органнарына, җитәкчелеккә тәнкыйть белән сугарылган ул язмалар басылганда, аларны чыгартмау өчен мөхтәрәм язучыбызга төрле-төрле юллар белән басым ясаганнары да мәгълүм. Вакыйгалар артык куергач, автор язылган ике хатын бастырмыйча кала. Без шуларның берсен укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык.

Социализм чорында демократия булмады, ул сүздә генә йөргән ялган демократия иде, дип язалар хәзерге сәясәтчеләр, политологлар, философлар. Ә менә мин, тулы демократия булмаса да, бар иде, дим. Моның дөреслеген шул чорларның матбугатыннан, китаплардан табып һәм бүген исән кешеләр сөйләвеннән ишетеп була. Узган гасырның илленче елларында без, унөч-ундүрт яшьлек балалар, колхозның отчет-сайлау җыелышларында катнаша башладык. Җыелыш көннәрдә авылның барлык халкы нардумда (народный дом, соңрак клубка әйләнде) икәнен беләбез инде без. Мәктәптә дәресләр беткәч, каптыр-коптыр гына капкалап аласың да нардумга йөгерәсең. Авылның төрле урамыннан җыелган чәүкәләр кебек, нардум идәненең иң алгы өлешенә кереп кунаклыйбыз. Хәзер дә шуңа хәйран калам, безне беркем дә, хәтта укытучылар да куып чыгармады. Безгә җыелышта ни калган соң? Анда искитмәле кызык! Кайбер елларда отчет җыелышлары икешәр көн дәвам итте. Кешеләр өйләренә ашык-пошык капкаларга, малларына азык салырга гына кайтып киләләр. Беркемнең дә хуҗалык эшчәнлеген тикшерүдән каласы килми. Карыннар өзелеп ачса да, җыелыш барышыннан аерыла алмыйча, борын тартырга да онытып, авыз ачкан хәлдә утырганнарымны һич онытасым юк.

Ни бар иде соң анда ул кадәр? Төрле кешеләрнең тулы мәгънәсендә җанлы фикер көрәше! Колхоз идарәсе һәм ревизия комиссиясе председательләре отчетыннан соң тотына халык сорау яудырырга! Ә сораулар үтә нечкә, конкрет. Эштә җибәрелгән кимчелекләр өчен җаваплы бригадирлар, ферма мөдирләре, баш бухгалтер, завхоз, председатель үзе җавап тота, дәлилләр китерәләр, акланырга азапланалар. Аннары чыгышлар башлана. Беркем чиратка язылмаган, сикереп тора да сөйли, кайберәүләр өчәр, дәртәр мәртәбә дә басып сүз әйтә. Ул чыгышларда мактау сүзе булмый иде диярлек. Һәркем җитешсезлекләрнең сәбәпләре, аларны төзәтү турында сөйли, үз тәкъдимен кертә. Колхоз председателеннән башлап, хезмәт минимумын үтәмәүчегә кадәр, «син сүзеңдә тормыйсың, син ялагай, син шомартып кына йөрисең», дип йөзләренә бәреп әйтәләр, шуны фактлар белән дәлилләр, һәрберсенә чыкылдатып бәя куела. Идарә, ревкомиссия членнары, аларның председательләрен сайлаганда, һәр кандидат энәсеннән җебенә кадәр тикшерелә. Берсен эшлексез дип кире кагалар, икенчесенең хәйләләп кенә йөрүе ачыла, өченчесенең бармагы үзенә кәкре, дүртенчесе эчәргә ярата — хет шартлап үл — дөреслеккә каршы берни әйтә алмыйсың. Тәнкыйть уты астында кызарып-бүртенеп утырган кешеләрнең йөзләренә туп-туры карау безгә искиткеч кызык! Без кемнең кем икәнен аерабыз. Кайчакларда халык бик кызып китсә, районнан килгән вәкил, ерылган буаны тыярга азаплангандай, кешеләрне җайлап-майлап ала, чит кеше булгач, аңа буйсынып, ярсуны киметәләр, сүзне басынкырак тонда алып бара башлыйлар. Ләкин җыелышка халыкның хуҗа икәнлеге сизелеп тора. Вәкил артык тәртипләргә тотынса, аның үзенә дә чатнатып: «Син безнең авызны томалама, яме!» — дип кенә җибәрәләр. «Сез» түгел, «син» дип сөйләшәләр иде ул чорда.

Еллар узды. 1958 елда урта мәктәп бетереп колхозда эшли башлагач, комсомол оешмасы секретаре, агитатор, драмтүгәрәк җитәкчесе, стена газетасы редакторы буларак, мин, идарә утырышларыннан башлап, партия, профсоюз җыелышларында, авыл Советы сессияләрендә генә түгел, район күләмендә узучы партия, комсомол активы җыелышларында, хәбәрчеләр слетларында даими катнашып тордым. Аларда тәнкыйть бик көчле иде.

Мин халыкның колхоз тормышына үз фикере белән йогынты ясый

алуын, аның фикере белән санлашуны, коллектив яшәешендә чыннан да аның ихтыяры чагылуын күрсәтмәкче булам. Ул идарә, ревкомиссия утырышымы, бригада, колхоз, партия, комсомол җыелышымы, авыл Советы сессиясеме — кычкырышуга гына кайтып калмады, һәрберсе буенча карар кабул ителде, чаралар планы эшләнде, аларны үтәү өчен җаваплы кешеләр һәм конкрет сроклар билгеләнде. Колхозга кемнеңдер гаебе белән килгән зыян (техниканы аудару, бәрү, терлек үлеме, ашлык бозылу, фермадан илтәсе сөтне әчетү һ.б.) бик җентекләп, вәземләп тикшерелде, һәр очрак буенча тиешле чара күрелде — уртак фикер алышу нигезендә генә бу! Кайсы тармакка нинди кадрлар җитмәүдән чыгып, фәлән кадәр кешене авыл хуҗалыгы техникумнарына, институтларга колхоз стипендиаты итеп җибәрү, диплом белән килүче яшь белгечләр өчен фәлән өй салу һәм башка бик күп нәрсәләр әнә шул карар-чараларга язылды һәм тормышка ашырылды. Сыеры үлгән колхозчыларга фермадан сыер бирү, өе искергәннәргә фәлән вакытка өй җиткерү, армиядән кайткан егетләргә, яшь белгечләргә, урта мәктәпне бетереп, колхозда эшләргә калучы яшьләргә льготалар, тагын бик күп, бик күп нәрсәләрне халык, үзе әйтеп, карарларга яздырды һәм эшләтте.

Элек район вәкилләре «син» дип кенә җибәргән авыл кешесе аларга «сез» дип дәшәргә өйрәнде. Әнә шундый «культуралы» мөнәсәбәтләр ихтыяҗы колхоз җыелышларына милиционерларны да китерә башлады. Идарә председателен, тармак җитәкчеләрен, белгечләрне эшне начар оештырган өчен бик кискен тәнкыйтьләүчеләрне туктату өчен президиумнан: «Ул бит исерек!» дию җитте — милиционер тегене җилтерәтеп залдан алып чыгып та китте. Гөнаһ шомлыгына каршы, бәгырен телгәләгән нәрсәләрне әйтергә кыюлык өчен бераз «чеметеп» килү гадәте бар иде. (Сәхнәгә спектакль куярга чыккан-да да бераз «төчкерткәннәр» халыкның ушын ала бит.) Шунсыз батырчылык итә алмый авыл кешесе. Салганмы, салмаганмы — анысы әле караңгы, әмма халык җитәкчеләренең тәнкыйтьне сөймәвен, аны әйткән чактагыга караганда соңрак сизде. Җыелышлар культуралашты, фикер туган саен урыннан сикереп торып аны әйтүләр бетте, шаушулар тынды. Иң элек докладчыга фәлән минут, чыгышларга фәлән минут дигән регламент кабул ителде. Отчетны тикшерү урынына тармак җитәкчеләре, белгечләр язып килгән кәгазьләрен укып чыктылар. Җыелышларның кызыгы да, мәгънәсе дә бетте һәм аларга халык кул селтәде, йөрми башлады. «Килмәде» дип әйтмәсеннәр өчен кешеләр гәүдәләрен күрсәтсәләр дә, җайлап кына чыгып тайдылар. Чөнки нindидер мәсьәләләрне уртага салып фикер алышу бетте, халыкны җыю, аның тарафыннан кул күтәртеп, нәрсәләрнедер законлаштыруга кайтып калды, тәнкыйть сүзе бер генә юнәлештә — президиумнан аска таба гына яңгырады. Акрынлап теләсә нинди утырыш, киңәшмә, җыелыш шундыйга әйләнде. Авызы томаланса да, халык көттермәде, бу хәлгә үткен анекдот белән җавап бирде. Мәктәптә укучы малай әтисеннән сорый: «Безгә укытучы астан һәм өстән тәнкыйть турында сөйләде. Ничек була ул?» Әтисе балконга күтәрелә дә, малаена якын килергә куша. Малае килеп өскә карауга, тегенең йөзенә төкерә һәм болай ди: «Өстән тәнкыйть менә шул инде ул. Хәзер син миңа төкер — анысы астан тәнкыйть була».

Элек колхоз председателен алыштырырга кеше алып килсәләр, халык теләмәсә, аны куя алмыйча иза чиктеләр. Чөнки халык хуҗа иде, аның көче бар иде, аның белән санлашмау вөҗдансызлык саналды. Үзләренең сүзләре үтмәвен, кеше фикеренең бернинди кыйммәте калмавын аңлаган халык читләшкәч, җыелышларга теләсә кем, хәтта шәһәрдән-мазар ялга кай-

тучылар кереп утыра башлады. Югарыдагылар өчен моннан да уңай нәрсә юк. Теләсә нинди карар кабул иттерү, беркем белмәгән әллә нинди бәндәләрне алып килеп председатель итеп кую китте. Көн саен хуҗалыкның махсус машинасы белән берничә дистә километр арадан (хәтта чит районнардан да) ташып йөртелүче җитәкчеләр пәйда булды.

Үзебездә кысылгач, капиталистик илләрдәге чын демократия белән кызыктырырга тотындылар. Имеш, анда эшсезләр дә ай саен акча ала, һәр кешенең берничә машинасы бар, һәммәсе җәннәттә яши. Аларда партияләрнең үзара ничек көрәшкәннәрен дә белеп тордык бит инде. Бездә дә шулай булса, фикер көрәше нәтиҗәсендә тормышыбыздагы кимчелекләр ачылыр һәм төзәтелер, илебез алга китәр, дип хыялланды халык.

И ул бәхетле мизгелләр! Демократия СССР карынында акрынлап тибенә, үзен торган саен ныграк сиздерә башлады. Аның кендек әбисе булган М.С.Горбачев авызыннан иң элек «плюрализм» дигән тылсымлы сүз туды. Ул инде безнең җәмгыятьтә төрле фикерләр, төрле идеяләр, төрле партияләр яшәргә һәм үзара көрәшергә хокуклы дигән сүз иде. Хәбәрдарлык киң колач җәйде. А.Сахаров кебек исемен телгә алырга да рөхсәт ителмәгән диссидентларны реабилитацияләү, хәтта югары дәүләт органнарына сайлану хокукы бирү башланды. Шул рәвешле тулгаклый торгач, демократия туды. И бәйрәм итеп куйдык та инде үзе дә! Ил белән тәпиен юдык, бәби туе ясадык, Демократия дигән исемен куйдык. Альтернатив нигездә ирекле сайлаулар игълан ителгәч, СССР халык депутатлыгына бер урынга әллә ничәшәр кандидат күрсәттек. Аларның һәркайсы үз программасы белән чыкты, зур залларда, телевизор экраннарында, матбугат битләрендә чын мәгънәсендә фикер көрәше башланды. Моңа кадәр халыкның күңелендә кайнаган, әмма

Туфан МИҢНУЛЛИН
(1935-1912)

Мөслимнең талантлы егете

...Авылдан азга гына да аерылмаган, авыл кешесенең йөрәк тибешен даими тоеп яшәгән, шуңа бөтен иҗатын багышлаган хөрмәтле язучыбыз бар безнең. Ул — Фоат Садриев. Мөслимнең талантлы егете. Фоатның романнары, повесть-хикәяләре, пьесалары аша авылның үткәне, бүгенгесе һәм хәтта киләчәге турында һәрчак уйландык...

Без инде күп әйберләрне күрмәскә, сизмәскә өйрәндек бугай. Фоат безнең җилкәбездән умырып тотып, авылдагы мең төрле үзгәрешләргә игътибарлырак булыгыз, дип, авылга йөзебезне борып күрсәтә. Аның шулай эшләргә хакы бар.

телгә алырга да ярамаган борчуларны ярып салдылар, ул борчулар фикер көрәшенең үзәгенә әверелде. Сайлауларда үзебезнең мәнфәгатьләрне яклаучыларның күңелебезгә иң якыннарына гына тавыш бирдек. Хәтта сайлауларга бару да мәҗбүр итеп куелмады. СССР халык депутатларының 1989 елның май-июнь айларында узган һәм телевизордан күрсәтеп барылган беренче съезды бөтен халык бәйрәменә, демократия тантанасына әверелде. Депутатлар ил, халык өчен янулары, ин-

теллектуаль дәрәҗәләре белән таң калдырдылар. М.Горбачев җитәкчеләрнең дә башын халыкка таба идерде. Цензура бетерелде. Күп партиялелек игълан ителде. Митинглар, демонстрацияләр оештыру иреге бирелде. Дәүләт Әфганстанга гаскәр кертүнең ялгышлыгын танып, аны чыгарды. Дөреслек байрак итеп күтәрелгәч, халыкның күңел офыклары киңәеп, яктырып китте. Демократиябез дә, беренче сөт тешләрен күрсәтеп, елмаеп-көлеп кенә торды. Әмма үсә башлауга, җитмәгән җирләре, бөкрерәк урыннары күзгә чалына башлады. Кайсыбызның үз баласын ямьсез итеп күрәсе килә? Тәрбиячеләр, гувернанткалар армиясе аның чәчләренә матур бантиклар куйдылар, колакларына җем-җем итеп торучы алкалар тактылар, муенына төймә, кулларына беләзек кигерделәр. Каш-күзләренә сөрмә тартылып, битләренә иннек-кершән ягылды. Бәби итәкле озын күлмәк кигергәч, җитешсез җирләре дә күренмәс булды. Гаделлек бөркәнчеге ябынырга өйрәнгән, матур имиджга, матур саннарга юнәлеш тоткан җәмгыятьтә макияжсыз гына булмый ич инде. Оста яучы кебек эш итүче гаммәви мәгълүмат чаралары үз бизәкләрен салып торгач, Демократиябез ару гына кыяфәткә керде үзе тагын. Әмма шунысы кызганыч, кирәккә дә, кирәкмәскә дә иркәләп, мактап торулардан ул кылтаеп китте, сарманнар әйтмешли, якланырга тотынды, тәүфыйксызга әйләнде. Олигархлар, бизнесменнар, түрәләр тирәсендә кыска итәктән маймылланып йөри башлады. Моның нәтиҗәсе озак көттермәде, дөрес юлда йөрмәгәнлектән, аның аяклары кәкрәйде, шактый түгәрәкләнгән көмәне күлмәге аша сизелә башлады. Балигъ булып та өлгермәгән Демократиянең беренче тәүфыйксыз баласы туды. Ил халкы референдумда «СССРны сакларга» дип әйткән килеш, аны таркатып ташлауны мин шул тәүфыйксыз бала эше дип саныйм. КПСС тәрбияләп кеше иткән җитәкчеләр ул партияне дә юк иттеләр. Халык сагайды. Демократиянең балалары бер-бер артлы туа торды. Халык байлыгын әләктерү башланды. Ил байлыгын бушка үзләштерүчеләргә, котырып баючыларга тулы ирек куелды.

Нигә тудырдык соң без аны? СССРны таркатып, Россиягә мөстәкыйльлек алганда, хөкүмәтебез бөтен халыкны «ура» кычкыртты, чечен халкы мөстәкыйльлек сорагач, аны канга батырып ташлады. Татарстанның да ничә еллар буе миллионлаган кешеләрнең йөрәк кайнарлыгы белән яуланган мөстәкыйльлеге дә зәгыйфьләнде. Телләребез, саныбыз төрле булса да, без шушы Россия дигән гаиләнең газиз балалары ич! Тигезлек, федерация мондый булмый лабаса! Мәктәпләрдә ана телендә укытуны кысу цивилизацияле җәмгыять эшеме? Сайлаулар да әллә ни төслегә әйләнде. Күп партиялелекне бик көткән идек. Әмма ул партияләр, йөз куян бер арыслан була алмаган кебек, барысы да сайлау чорында гына яшәп ала торган сезонлы партияләр булып чыктылар.

Рус мәктәпләрен генә калдыруга юнәлеш тоту, паспортта милләтләрне күрсәтмәү — ул милләтләрне юкка чыгаруның бер формасы инде. Алайса башка өлкәләрдә нишләп тигезлек югалды соң? Хезмәткә хокук кайда? Югарыдагылар йөз меңнәр, миллионнар белән акча алганда, гади хезмәт кешеләре акчасызлыктан очын очка ялгый алмый гомер сөрә, эшсезләр армиясе торган саен ишәя. Арада авыл кешесеннән дә хокуксызрагы юк. Ул җитештергән продуктларны пүчтәк хакка сатып алып, кибетләргә әллә ничә мәртәбә арттырылган бәяләр куеп чыгару бернинди экономик законнарга да, әхлак кануннарына да, логикага да сыймый. Айга бер-ике мең акчаны да күпсенүне нормаль җәмгыятьнең берәр нормасына кертеп, аңлатып буламы? Шундый хәлләр еллар буе хөкем сөргәндә, без нинди гаделлек, тигезлек турында сөйли алабыз соң? Акча түләп югары дәрәҗәләр, исемнәр

алгач, акча түләп депутат булгач, акча түләп законлы җәзадан котылгач, акча түләп югары кәнәфигә үрләгәч, нинди демократия була да, безнең җәмгыять белән нәрсә идарә итә соң? Акча демократиядән көчлерәк, аны җиңдемени? Әйе, демократия, ирек юк дип булмый. Ул байлар өчен гөрләп чәчәк ата. Акчаң күбрәк булган саен, синең алда күбрәк халык баш ия. Акчаң күбрәк булган саен, син хаклырак һәм җәмгыять нормаларыннан азатрак. Акча алдарга да, куркытырга да, мыскылларга да, закон бозарга да, урлашырга да, кыскасы, халык тудырган барлык рухи һәм матди кыйммәтләргә тукынырга хокук бирә. Әмма акча хокукы белән яшәүче җәмгыятьне коточкыч һәлакәт көтә. Тигез бәядәге нәрсәләрне алмашу чарасы буларак, акча — тормыш ихтыяҗы. Әмма ул фетишка әверелдерелеп, җиһан тоткасы дәрәҗәсенә күтәрелә икән, бу инде акылдан шашуга тиң. Ул кешенең җанын, бөтен тереклекне үтерә.

Кендек әбисе М.Горбачев булган демократиябездән һәм элеккесеннән нәрсәләрдер саклана ич, шуларны күздән кичерергә, барларга кирәк инде. Безне гомер буе «бөтен кеше — бер кеше өчен, бер кеше — бөтен кеше өчен» дигән принцип белән тәрбияләделәр. Гомумән, кешелек дөньясы үз яшәешен шул принципка таянып алып барган. Рус общиналарында физик яктан көчсезләр, гарипләр аерым игътибарда булган. Аларга хуҗалыгын, гаиләсен тотарга, балалар үстерергә булышканнар. Хәзер ул принципның «бөтен кеше бер кеше өчен» дигән өлеше генә калды. Элек аерым кеше халык алдында баш исә, аны зурласа, хәзер халык бер кешенең күзенә карап калтырап тора. Бигрәк тә авылда шулай.

Политик ирекләрнең иң мөһимрәге — сүз иреге, матбугат иреге, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр иреге. Алар дөреслекне әйтү, хакыйкатьне табу өчен кирәк. Совет чорыннан соң Россиядә дә, Татарстанда да чыга башлаган газета-журналларның исәбе-хисабы юк. Цензура бетерелгәч, журналист каләменә тулы ирек бирелде кебек. Әмма халыкны борчый, бәгырен телгәли торган мәсьәләләр турында язу совет заманнарындагыдан күпкә җитдирәк проблемага әверелде. Дөреслекне рәсми төстә беркем дә тыймый. Ләкин тормыш күгендә аңа каршы уйнап торган кылыч сизелә. Аны беркем дә күрми, тик һәркем тоя. Шуңа күрә матбугат та, авылда җыелышка-мазар килгән халык та авызын үлчәп кенә ача. Хәтта карт-корылар да дәшмәүне, дөреслекне әйтмәүне кулай күрә. Әйтсә, берникадәр вакыттан аның, бумеранг булып әйләнеп кайтып, үзенә һәм балаларына китереп бәрүен белеп тора. Нишләп дөреслек шулкадәр куркыныч нәрсәгә әверелде соң әле? Ул кемнәрне куркыта? Гади халыкны түгел, югарыдагыларны, әлбәттә. Ник куркыта? Кылган эш-гамәлләре гадел булмагангадыр инде. Гадел булмаган гамәлләргә нәрсәләр кергәнен чамалау кыен түгел.

Бу мәсьәләләр белән политик партияләр ныклап шөгыльләнергә тиеш. Ә аларның хокуклары тигез түгел. Президент Д.Медведев партияләрнең тигезлеген тәэмин итүче карар чыгарырга әзерләнә. Була гына күрсен. Илебезнең иҗтимагый-сәяси тормышында бу — тарихи адым булачак. Төрле идеяләр, фикерләр көрәшендә генә хакыйкать табыла алганлыгын, кабатлау булса да, тагын әйтергә туры килә. Әгәр чыннан да шундый фикер көрәше җәелсә, миллионнарча кешеләр партиягә керү өчен гариза тотып киләчәк. Чөнки үз фикеренең тормышны яхшыртуга өлеш кертә алачагына ышаначак. Фикер, гаҗәеп зур тәэсир итүче көч буларак, җәмгыять тормышында лаеклы урынын алачак, дигән сүз. Ә халык фикеренең тирәнлегенә, байлыгына хәйран калмалы. Җир йөзендә аңардан да бөеграк көчнең булганы юк һәм булмаячак та. Демократия — шул көчне хәрәкәткә китерү дигән сүз һәм ул Конституциябездә ап-ачык итеп язылган. ■

Болгарны бүген бөтен дөньяда беләләр. Болгар халкы, VII гасырда Кубрат хан төзегән Бөек Болгар дәүләте, X-XIII гасыр башларында чәчәк атып яшәгән Идел Болгарстаны, аның мәшһүр калаларыннан саналган һәм Алтын Урда ханы Батуның резиденциясе урнашкан шәһри Болгар, XV гасыр тәңкәләре сугылган Болгар әл-Җәдид (Яңа Болгар-Казан), Шәрык базарларында дан казанган, борынгы урыс елъязмаларында телгә алынган атаклы «болгари» күн итекләре... Изге Болгар җирләре... Исә Болгар җилләре... Әйе, Болгар исеме белән дәүләтләр, аларның баш калалары аталган, Болгарны халкыбыз дастаннарда данлаган, җырларда җырлаган, аның турында легенда-риваятьләр чыгарган.

БОЛГАР ҺӘМ СПАС РАЙОНЫ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

....

Фаяз Хуҗин

Болгар һәм әлеге шәһәр урнашкан Спас районы республикабызның башка шәһәр районнарыннан кайсы ягы белән аерыла соң? Әйе, табигате матур — Идел буенда урнашкан, туфрагы уңдырышлы, халкы уңган, эшлекле, авыллары төзек, матур, район җирлегеннән аның данын еракларда, хәтта чит илләрдә дә яңгыраткан күп кенә атаклы шәхесләр чыккан... Барысы да дөрес, әмма шул ук нәрсәләр белән республикабызның теләсә кайсы районы горурлана ала ич. Минемчә, районның үзенчәлеге, аңа дөньякүләм танылу китергән иң мөһим фактор — галиҗәнап Тарих, тарихи истәлекләр, халкыбыз мирасы. Һәм, бер дә курыкмыйча әйтәм: шул мирасны барлаучы, өйрәнүче, пропагандалаучы галимнәр. Районның байлыгы менә шулар. Авыл хуҗалыгында ирешелгән уңышлар белән генә үзеңне дөньяга таныту мөмкин түгел.

Чыннан да карагыз: Спас районында 400гә якын төрле чорлардан калган (иң борынгы таш гасырыннан башлап Казан ханлыгына кадәр) археологик истәлекләр урнашкан. Бу җәһәттән ул бары тик күршесе Алексеевск рай-

оныннан гына калыша (443 истәлек). Әлеге истәлекләр арасында, Болгар шәһәрлегеннән кала Сувар, Балымер, Әҗмәр, Бураково, Танкеевка, Коминтерн, Маклашеевка кебек дөньякүләм билгеле борынгы шәһәр хәрабәләре, зират-каберлекләр, акча һәм алтын-көмеш әйбер хәзинәләре табылган урыннар бар. Чагыштыру өчен әйтеп китим: Казан арты районнарының күбесендә археологик истәлекләрнең саны уннан-егермедән артмый. Мәсәлән, минем туган районым Зәйдә — 22, ә күрше Сарманда барлыгы 5 археологик истәлек теркәлгән.

Ассызыклап әйтәсем килә: хәзерге Болгар җирлегендә татар халкының һуннар һәм Төрки каганлыгы чорыннан ук башланып киткән борынгы дәүләтчелеге формалашкан. Биредә Ислам дине рәсми рәвештә дәүләт дине буларак кабул ителгән. Тикмәгә генә Болгарны «икенче Мәккә» димиләр бездә — халкыбызның хәтере нык аның!

Алып карыйк соңгырак чорларны. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң да бу урыннар бушап калмый, әмма халкыбыз тормышында, аның этник тарихында бик кискен үзгәрешләр башлана. Болгар тирәсендәге иң уңдырышлы җирләрне урыс алпавытларына, дворяннарга өләшәләр. Бу якларга күпләп урыс крестьяннары килеп төпләнә. Урыс байлары яшәгән утар урыннары, йортлары, чиркәүләр бүгенге көнгә кадәр сакланып калган һәм алар тарихи-мәдәни мирасыбызның бер өлешен тәшкил итә.

Болгар төбәгенең соңгырак чорлары тарихында Петр I, Екатерина II, Г.Р.Державин, Н.А.Некрасов, И.П.Панаев, В.П.Молоствов, Н.М.Мусин-Пушкин, Н.И.Лобачевский, А.Ф.Лихачев кебек күренекле дәүләт эшлеклеләренең, язучыларның, галимнәрнең исемнәре теркәлеп калган. 1861 елгы Бездна восстаниесе тарих буенча мәктәп һәм федераль югары уку йорты дәреслекләренә дә кертелгән.

Болгар һәм Спас районының совет чорындагы һәм 1990 нчы еллардан башланып киткән һәм әле бүген дә дәвам итә торган үзгәртеп корулар заманындагы казанышлары турында әйтеп тормыйм. Әлеге төбәк өчен ул казанышларның иң мөһиме, мөгаен, Болгар шәһәрлегенең ЮНЕСКО тарафыннан дөньякүләм әһәмиятле тарихи мирас истәлекләре исемлегенә кертелүедер.

Менә шул тарих 2014 елда Татарстан Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан Спас муниципаль районы Башкарма комитеты катнашында әзерләп чыгарылган «Болгар шәһәре һәм Спас районы энциклопедиясе» дигән фундаменталь басмада киң чагылыш тапкан. Әлбәттә, әлеге басмада Болгар төбәгенең табигатенә, социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси тормышына багышланган материаллар да лаеклы урын алып тора. Китап аклы-каралы һәм төсле иллюстрацияләр белән бай бизәлгән. Полиграфик эшләнеше яхшы.

Энциклопедия битләренә күз төшерик.

Ул Спас муниципаль районы башлыгы К.А.Нугаевның китап укучыларга, шәһәр һәм район халкына, читтә яшәүче якташларына, Болгар кунакларына мөрәҗәгате белән ачыла. Аннан соң Спас муниципаль районы турында кыскача белешмә бирелә. Игътибар беләнрәк укысаң, кызыклы гына фактларга тап буласың. Шуларның берсе: 1930 елда яңа гына оешкан район җирлегендә барлыгы 95 торак пункты булып, аларда 52 мең 504 кеше яшәгән (татарлар саны — борынгы Болгар җирендә! — урысларныкына караганда 10 тапкырга кимрәк: 46 мең урыска 4600 татар туры килә). 1960 елда, район территориясенең зур гына өлешен бөек коммунизм төзелешләреннән берсе булган Куйбышев ГЭСы сусаклагычы биләп алганнан соң, торак пунктлар саны 66га кадәр кими. Бүген районда 45 торак пункты булып, аларда 20 мең чамасы кеше яши, шуларның 950се генә авыл хуҗалыгында эшли. Уйласаң, уйланырлык.

Тагын бернәрсәгә игътибар иттем: әлеге белешмәдә Болгар төбәгенең борынгы һәм урта гасырлар тарихына, археологик материалларга таянып, кыскача күзәтү ясала да, сүз шундук бүгенге көннәргә күчә. Әйе, Татарстанның XVII-XVIII гасырлар тарихы, гомумән, бик начар өйрәнелгән бездә, шулай да белгән кадәресеннән, XIX йөз материалларын да өстәп, кыскача гына белешмәләр бирергә була иде.

Хәзер инде Энциклопедиянең төп өлешенә күчик. Гомумән алганда, мәкаләләрнең барысы да диярлек югары профессиональ дәрәҗәдә язылган. Аларның шактые, бигрәк тә археологиягә караганнары, «Татар энциклопедиясе»ннән күчереп бастырылган (авторларын күрсәтмичә генә).

Археологик материаллар Болгар төбәгенең борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүдә төп чыганак булып тора. Шул чыганакларга нигезләнеп язылган мәкаләләр аша киң җәмәгатьчелекнең тарихи карашлары формалаша, калыплаша.

Археология (Болгар шәһәрлеге, Кожаевка хәзинәсе, Әҗмер авыллыгы, Танкеевка каберлеге һ.б.), археология һәм Болгар архитектурасы (Ак пулат, Кара пулат, Кече манара, Болгар мунчалары һ.б.), археология һәм тарих (Болгар — урта гасырлар шәһәре, Идел Болгарстаны, Алтын Урда һ.б.) төркеменә кергән мәкаләләрнең саны 100дән артып китә һәм, аңлашыла ки, аларның күпчелеге Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда чорына карый. Әлеге төркемгә риваять-легендаларга гына корылган мәкаләләр дә бар (Габдрахман сәхабә коесы, Рәбыйга күле, Сәхабәләр һәйкәле,Туйбикә коесы һ.б.).

Мәкаләләрдә кайбер төгәлсезлекләр, бәхәсле нәрсәләр дә бар. Күпләрегез инде тарих һәм археология фәнендә XIX йөздән бирле Идел Болгарстанының монгол яуларына кадәрге башкаласы турында бәхәсләр барганын беләсездер. Бу бәхәсләр 1960 нчы еллар азагында Биләр шәһәрлегендә казу эшләре башланып киткәч тагын да кискенләште. Шулай булгач, — артык күп тә кирәк түгел ич! — тарихи дөреслекне чагылдырып, әлеге проблеманың бүген дә бәхәсле булып кала бирүен искәртеп үтәргә кирәк иде, минемчә. Аның урынына «Спас муниципаль районы» дигән кереш мәкаләдә «IX—XIII гасырларда Идел Болгарстанының башкаласы — Болгар» (14 б.), ә «Болгар — урта гасырлар шәһәре» мәкаләсендә (67 б.) аның X гасыр башыннан — Идел Болгарстаны, XIII гасыр уртасыннан Алтын Урда составындагы кенәзлек (олыс) башкаласы булганлыгы әйтелгән. Югыйсә бит Биләрнең XII гасыр уртасыннан башлап, хәтта XI гасыр ахырыннан монгол яуларына кадәр Болгар дәүләтенең башкаласы икәнлеге рәсми историографиядә дә кабул ителгән (карагыз: Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951, 39 б.). Мәкалә авторлары моны белмиләрме, әллә вак нәрсә дип саныйлармы, әйтүе кыен.

«Авраамий Болгарский» мәкаләсендәге (29 б.) тагын бер төгәлсезлек турында әйтеп китмичә булмый. Авраамий исемле христианны, Лаврентий елъязмасында бик ачык язылганча, 1229 елда Олуг шәһәрдә үтерәләр (сәбәбе билгеле түгел) һәм гәүдәсен Владимирга алып китеп, аннан «новый мученик» ясыйлар. Биләрнең урыс елъязмаларында «Олуг шәһәр» дип аталуы («Великий город на Черемшане») һәркемгә мәгълүм. Нәрсәгә кирәк иде Авраамийны Болгар белән бәйләргә? Аның сөякләрен («мощи») 1892 елда Болгарга алып килү факты гына «Олуг шәһәр»не Болгар итә алмый ич инде.

Әгәр дә дөрескә чыкса, тагын бер кызык нәрсә: Җамигъ мәчете янындагы Көнчыгыш төрбәдә, имеш, Бурашбәкләрнең затлы нәселенә караган кешеләр күмелгән. Мәкалә ахырында күрсәтелгән хезмәтләрне карап чыктым, мондый информацияне тапмадым. Каян килеп эләккән ул бирегә? Кем ул Бурашбәк — энциклопедиядә аның турында мәкалә юк.

Болгарның атаклы Ага-Базарына багышланган мәкалә дә миндә сораулар тудырды. Беренчедән, «Татар энциклопедиясе»ндә (т.1, 39 б.) аның урнашкан урыны шәһәрдән 6 км, ә «Болгар энциклопедиясе»ндә бары тик 2,5 км ераклыкта, дип күрсәтелгән (30 б.). Әлеге энциклопедиянең «Болгар шәһәрлеге» дигән мәкаләсендә дә шулай: «Ага-Базардан Иерусалим чокыры тамагына кадәр 3 километрдан аз гына артыграк» (72 б.). Ә бит элегрәк бу араны, гарәп чыганакларына таянып, чыннан да бер фарсах, ягъни 6 км чамасы, дип йөриләр иде. Ышанмасыгыз, А.П.Смирнов, Н.Ф.Калинин, Р.Г.Фәхретдинев хезмәтләрен карагыз. Археологлар Б.Б.Жиромский һәм К.А.Смирнов узган гасыр урталарында биредә казу эшләре дә алып барганнар иде. Кайсына ышанырга — аерма зур бит! Кыскасы, археологлар Болгарда җитмеш елдан артык эшләсә дә, Ага-Базарның урынын төгәл генә ачыклый алмаган икән әле.

Икенчедән, беләсе иде, Ага-Базарның Болгар илендә, мәкалә авторы язганча, «эре мәдәни үзәкләрдән» саналып йөрүе нинди фактлар белән расла на икән? Сәүдә үзәге булуы бәхәссез, бәлки, берникадәр һөнәрчелек белән дә шөгыльләнгәннәрдер. Зур бистә булган, дияр идең, Б.Б.Жиромский үзе Ага-Базарның мәйданын, культура катламы сакланып калган урыннарны исәпкә алып, 2000 кв. м (икенче төрле итеп әйтсәк, 20 сотый) дип кенә билгеләгән иде. Казылмаларыннан да мәдәни тормыш белән бәйле табылдыклар килеп чыкмады.

Бер уңайдан әйтеп китим әле, X гасырның беренче чирегендә язган гарәп географы әл-Балхи үзенең китабында Болгар белән беррәттән «Тышкы Болгар» дигән кечкенә шәһәрне дә, «ул сәүдә үзәге буларак кына билгеле» дип, искә алып уза. Тышкы Болгарны бериш галимнәр Ага-Базар белән тиңләштерә, икенчеләре исә (чын Болгар — Биләр ул, дип) — хәзерге Болгарның үзе белән. Тышкы Болгар турында аерым мәкалә бирелсә дә, ярап куясы икән.

Энциклопедиянең, шартлы рәвештә әйткәндә, авыллар төркеменә караган мәкаләләрен дә бик кызыксынып укып чыктым. Авыллар тарихы — татар тарихының иң аз, иң начар өйрәнелгән өлкәсе. Ярый әле соңгы елларда бу өлкәдә һәвәскәр тарихчыларыбыз бик актив эшли башлады, һәм бер-бер артлы авыллар, районнар, хәтта аерым гаиләләр тарихына багышланган дистәләгән китаплар басылып чыкты. Авторлары арасында үзләрен тарих язарга сәләтле дип санаган татар зыялылары: укытучылар, журналистлар, профессиональ тарихчы булмаган галимнәр. Ә безнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре, архивларга барып, төбәк тарихын язарга ашкынып тормыйлар әле. Әйе, авыр эш бу, әмма бик кирәкле, файдалы эш. Халык бит чын тарихка, үз тарихына сусаган — олысы-кечесе әнә шул һәвәскәрләрнең китапларын да кызыксынып, кулдан-кулга йөртеп укый.

«Болгар шәһәре һәм Спас районы энциклопедиясе»нә кергән мәкаләләрдә 150гә якын авыл тарихы теркәлгән. Шуларның өчтән икесе — юкка чыккан авыллар. Аларның саны бигрәк тә узган гасырның 50-60 нчы елларында кимегән: башта Куйбышев сусаклагычы төзегәндә, аннан соң колхозларны эреләндерү чорында. Бүген дә дәвам итә ул куркыныч процесс.

Мәкаләләрнең күләмнәре дә, сыйфатлары да бер дәрәҗәдә түгел. Әлегә яшәп килә торган авыллар тарихы тулырак итеп язылган (мәктәп укытучылары күп көч куйгандыр, рәхмәт төшкерләре), юкка чыккан авыллар тарихы исә әлегә җитәрлек яктыртылмаган. Аларның авторларын гаепләргә ашыкмыйк — төрле чорда, төрле сәбәпләр аркасында тарих битләреннән төшеп калган авылларның бары тик исемлеген төзү генә дә зур хезмәт, тырышлык һәм түземлек сорый торган эш. Без бүген шуңа да канәгать һәм

рәхмәтле булырга тиешбез. Авыллар тарихы — архивларда, юкка чыкмаган алар. Профессиональ тарихчылар да бу эшне хәзер үз кулларына алырга әзер.

Энциклопедиядәге мәкаләләрнең иң күп өлеше — алар 2000гә якын! — Болгар җирлегендә үсеп, белем алып хезмәт куйган, район тарихында азмы-күпме эз калдырган күренекле шәхесләрнең кыскача тормыш юлларын тасвирлый. Әлеге шәхесләр арасында хезмәт батырлары — илебезнең орден-медальләренә лаек булган гади колхозчылар, укытучылар, табиблар, Бөек Ватан һәм Әфган сугышы ветераннары, галимнәр, язучылар, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, эре предприятие җитәкчеләре бар. «Иң зур байлыгыбыз — кешеләр!» — дип әйтергә өйрәнде җитәкчеләребез. Кайчак бу сүзләргә игътибар да итмибез, ә кайчак: «Шулай икән, саклагыз ул байлыгыгызны! — дип кычкырасы килә. Болгарда кеше кадерен беләләр, район даны өчен җан атып эшләүчеләрне күрәләр дә.

Район тарихына мөнәсәбәте булган атаклы шәхесләр арасында урын алган Александр Гумбольдт, Август Гакстгаузен, Владимир Тизенгаузен, Дезире Фюзейе турында белешмәләрдә күп кенә укучыларыбыз өчен яңа һәм гаҗәп кызыклы информация тупланган. Шуларның берсе: Дезире Фюзейе исемле француз хирургы, 1812 елгы Наполеон сугышларында катнашып, русларга әсирлеккә төшкән. Аны башта Казанга, аннан соң Спас шәһәренә, хәзерге Болгарга, җибәрәләр. Биредә ул җирле халыкка медицина ярдәме күрсәтә, чакыру буенча күрше авылларга да барып чыга. Кире Франциягә әйләнеп кайткач, әсирлектә күргәннәрен-белгәннәрен язып калдыра. Әлеге истәлекләр 1991 елда гына дөнья күрә. Элеккеге француз әсире күңелендә Спас һәм аның кешеләре, күрәсең, тирән эз калдырган.

Биографик белешмәләр арасында безнең археологларга багышланганнары да байтак. Бик дөрес эшләгәннәр, дөньяга танылган борынгы Болгар истәлекләрен өйрәнүче галимнәр моңа бик лаек. Тик бернәрсә кәефемне җибәрде: озак еллар Болгарда эшләгән Мәскәү археологлары Б.Б.Жиромский һәм Г.Ф.Полякованың исем фамилияләреннән соң «?» билгесе генә куелган — беренчесенең туганүлгән еллары, икенчесенең туган елы билгеле түгел, имеш. Соң, Галина Федоровна әле 1990 нче елларда гына казып йөрде ич Болгарда, Дәүләт тарих музеенда эшләде, ә Борис Борисович 1970 нче елларда Мәскәүнең «Коломенское» музей-тыюлыгы директоры иде. Шылтыратып сорарга да була бит! (Әлеге җитешсезлек, кызганычка каршы, башка шәхесләр турындагы белешмәләрдә дә очрый.)

Басманың ахырында, кушымта рәвешендә, дүрт һәм күбрәк орден белән бүләкләнгән шәхесләрнең, орденнар белән бүләкләнгән Бөек Ватан сугышы ветераннарының, өч дәрәҗәдәге «Ана даны» орденнары белән бүләкләнгән күп балалы аналарның һәм Куйбышев шәһәренең 7 нче төрмәсендә атылган сәяси репрессия корбаннарының исемлеге китерелә. Боларын да бик файдалы белешмә, дип кабул итәргә кирәк.

Йомгаклап әйтәсе килгән сүзем шул: без бәя бирергә тырышкан энциклопедияне әзерләп чыгаруга бик күп көч куелган. Күләме алтмыш басма табактан артып киткән фундаменталь хезмәттә аерым җитешсезлекләр булуына гаҗәпләнергә дә, борчылырга да кирәкми. Киләчәктә дөнья күрәчәк район энциклопедияләре өчен ул өлге булырлык дәрәҗәдә камил эшләнгән: структурасы җыйнак, концепциясе дөрес. Моның өчен басманың баш редакторы Гомәр Сабирҗановка, аның урынбасары Җәмил Мөхәммәтшинга һәм редакторы Виктор Марянинга, мәкалә авторларына олы рәхмәтебезне җиткерәбез. ■

«ШУЛВАКЫТТА МИН КУЛЫМА КИТАП АЛАМ...»

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры Әнәс Тәлгат улы ӘСКӘРОВ белән «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, язучы Рәдиф СӘГЪДИ әңгәмәсе

— *«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы (ул чакта башкача атала иде) совет чорында ук алдынгы сафта саналып килде. Әнәс әфәнде, әүвәл сүзне үзегез җитәкләгән әлеге оешманың бүгенге хәл-торышы турында сөйләшүдән башласак иде. Тукай сүзләрен үзгәртебрәк әйтсәк, ничек хәлләрегез, ничек көн-күрмешегез?*

— Бүгенге көндә полиграфия базарында хәлләр катлаулы. Типографияләрнең яшәеше заказчылардан тора, күләменә карап бәя куела. Шуннан чыгып, типографиянең мөмкинлекләре күпме дәрәҗәдә барлыгы да ачыклана. Китап бер генә төрле түгел. Әйтик, бүгенге көндә дини әдәбият, дип әйтәбез икән, аңа татар-мөселман юнәлеше дә, православ әдәбияты да керә, шуннан соң мәктәпләр, урта һәм югары уку йортлары өчен уку әсбаплары, һәм балалар өчен басмалар аерым урынны алып тора. Безнең типографиядә бүгенге көндә Мәскәү нәшриятлары белән дә 40тан артык контракт төзелгән. Ул килешүләрнең барысы да тиешле дәрәҗәдә эшли. Мәскәү белән беррәттән, Башкортстан Республикасы белән дә тыгыз элемтәдә торабыз. 6-7 нәшрият безнең белән һәрдаим элемтәдә. Ижау, Әстерхандагы нәшриятлар белән дә багланышлар ныгый. Түбән Новгород өлкәсеннән исә 3 нәшрият заказ бирә, Оренбург өлкәсеннән 2 нәшрият продукциясен бездә чыгара. Барысын бергә җыйганда, хәттин зур гына заказ килеп чыга. Ай саен 60 млн.нан 70 млн.га кадәр товар продукциясе эшләп чыгарабыз. Көн саен безнең предпри-

ятие 3 миллион — 3 миллион 500 мең сумлык басма товар эшләп чыгарырга тиеш. Бүгенге көндә полиграфия комплексының яшәешен алып бару өчен менә шушы шартларның үтәлүе бик мөһим. Узган ел китапларны пленкага төрү буенча яңа линия алдык. Һәр экземплярны аерым пленкага төреп чыгара торган автомат линия ул. Һәрбер пачканы аерым төрү бик уңайлы юнәлеш. Китапны ерак юлларга илткән вакытта яхшырак саклана, дым эләгеп, китаплар бозылмый. Шул юнәлештә мин тагын бер мәсьәләне искәртеп китәр идем. Бүгенге көндә газеталарның тиражы кими, ИЗО продукция юнәлешендә дә, ни кызганыч, түбәнәю бара. Мәктәпләр өчен, югары уку йортлары өчен дәреслекләр, балалар өчен китаплар, ислам, православие юнәлешендәге басмаларның тиражы, шөкер, кимеми. Бу өч юнәлеш тә үзен аклый. Берничә ел инде кризис, дибез. Кризис ул үз эшен эшли. Ә матур әдәбият китапларының тиражы төшә, тиражлары кимесә дә, аларның исем саны кимеми. Саннары арту исәбенә, бу базарда «тотрыклылык» дигән әйбер саклана. Бүгенге көндә аны тотып тору җиңел хәлләрдән түгел. Бик күп очрашулар үткәрергә, гел хәрәкәттә булырга кирәк. Әйтеп киткәнемчә, юнәлешләрне билгеләү мөһим. Гел сөйләшүләр алып бару, элемтәләрне ныгыту зарур. Шуш рәвешле эшлекле эш алып бармаганда, бу система — челтәрнең өзелүе бик тә ихтимал. СССР вакытында ничек иде: һәр айга планлы эш дип, алга максатлар куябыз да, нинди юнәлештә эш итү ягын ачыклыйбыз. Киләчәктә безгә 2 яңа машина кирәк. Каты тышлы китапларны җеп белән тегеп чыгарыр өчен заманча тегү машинасы алачакбыз. Россиянең иң зур нәшрияты «Просвещение» дә безнең белән хезмәттәшлек итә. Без ул заказларны әлеге машиналардан башка өлгертә алмыйбыз. Алар куйган җитештереп чыгару вакыты таләбе бик кыска. Чөнки Мәгариф министрлыгы белән нәшриятларның килешүе төзелгән. Китап әзерләнгәч, бик кыска вакыт арасында басылып чыгарга да тиеш. Шуңа күрә дә, яз-март айларыннан октябрь-ноябрь айларына кадәр, типография тәүлек әйләнәсе эшли.

— Берзаман кайбер редакторлар чыгарасы журналларын тотып, Чабаксарга чаба башлады, имеш, анда бәя түбәнрәк икән. Мари белән Кировка баручылар да җитәрлек булды...

— Балык тирән урын эзли, дигән кебек, һәр кеше дә эзләнүдә. Базарда демпинг бар. Әгәр дә типографиянең тәүлек дәвамында эш алып барырлык көче җитми икән, ул инде бәяләрне төшерә башлый. Ни өчен Чабаксарга баралар? Дөрес, аларның күпчелеге кире әйләнеп кайтты. Кировта да эшләтеп карадылар. Ләкин аларда сыйфат шактый түбән. Чабаксар типографиясендә инде 20-30 ел бернинди техник үзгәреш кертелгәне юк. Бер типографияләре хәтта сатарга куелды. Аларда яңа машиналар күптән алынмаган, бөтенесе иске-москы. Чыгарган китапның сыйфаты да булырга тиеш бит! Кулга тотып карарлык, кеше сокланырлык булсын ул. Китап кешене җәлеп итеп торырга тиеш. Чабаксарда, Кировта һәм Мари Республикасында иске типографияләрнең калдыклары гына. Без 3 ел элек 100 миллион сумнан артык кредит алып, типографиянең 70%тан артык машиналарын (бастыру, тегү һ.б.) өр-яңага алмаштырдык. Яңа китап линияләре куйдык. 5 буяулы бастыру машиналарын эшкә җиктек. Аңлашыладыр ки, техниканы яңарту өлкәсендә зур көч сарыф итәбез. Элегрәк киткән заказчиклар безгә кире әйләнеп кайтты. Бүгенге көндә алар белән элемтәләр яңадан ныгый.

— Димәк, бу затлылык белән бәйле инде?

— Әлбәттә, затлылык һәм бәя белән. Башка төбәкләр үзләренә китерү өчен бәяне киметкәндәй итә, килдең исә бәяне үз урынына кире күтәрә дә куя.

— Сыйфат мәсьәләсендә алар сезгә көндәш була алмый, димәк?

— Сүз дә юк, сыйфат мәсьәләсендә безнең белән ярыша алмыйлар. Әлеге вакытта аларның моңа мөмкинлекләре җитеп бетми.

— Хәзер безнең татар теле дәреслекләре ишле бастырыла. Ул ничек таратыла, Россиядә яшәүче татарларга да барып җитәме?

— Безнең Мәгариф министрлыгы Татарстан китап нәшрияты белән еллык план төзи. Шуның нигезендә уку әсбаплары безгә килә. Алар үзгәрешсез, ел саен бер күләмдә чыгып килә, кимү күзәтелми, хәтта аз гына арта да бара. Китапларны тарату мәсьәләсе белән, әлбәттә, Татарстан китап нәшрияты үзе шөгыльләнә.

— Сез — Арча районы, Ташкич авылы егете. Арча — татар әдәбиятына-мәдәниятенә бик күп шәхесләрне биргән төбәк. Китап дөньясына кереп китүегез ничек булды?

— Әле башлангыч мәктәптә укыганда, аның китапханәсе дә бар иде. Укып чыкмаган бер генә китап та калмады. Еллар үтү белән ул сыйфат миндә югалмады, хәтта армиядә хезмәт иткәндә дә сердәшем — китаптан аерылмадым. Матур әдәбиятка булган мәхәббәт үз эшен эшләде. Казанга килеп урнашканнан, ягъни 1987 елдан бирле шушы полиграфия эшенә тугры калдым.

— Полиграфистлар кайда әзерләнә?

— Полиграфист булу өчен полиграфияне генә белү аз. Мин белемем буенча юрист, механик һәм сәүдә белгече. Элегрәк коммерция буенча директор урынбасары идем, вазифам шушы оешманы эшле итү, акчалы итүдән гыйбарәт иде. Теләге булмаган кеше полиграфияне укып кына өйрәнә алмый. Аны эшләп, тәҗрибә туплап өйрәнергә кирәк. Бүген КХТИда полиграфия буенча махсус белгечлек бар. Алар, безгә килеп, мастер-класслар үткәрә, практиканы да биредә уза, төп белгечләр белән аралаша, үзләренә кирәкле технологияне үзләштерә. Без исә аларга экскурсияләр оештырабыз.

Полиграфистлар әзерли торган иң төпле университетлар — Мәскәүдә һәм Украинада гына. Бездә эшләүче белгечләрнең дә күпчелеге — Украинада укып, бирегә «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы төзи башлаганда эшкә килүчеләр.

— Әңгәмәгез өчен рәхмәт! ■

ҖӘГЪФӘР ТАРИХЫ

Фәйзелхак Ислаев

Татар-мөселман дөньясында Җәгъфәр изге исемнәрдән санала. 922 елда болгар бабаларыбызның илбашы – илтабар Алмас ислам динен кабул иткәндә шушы исемне ала, шуңа күрә безнең борынгы тарихыбыз «Җәгъфәр тарихы» дип атала. Җәгъфәр – заманында бөтен татар дөньясын шаулаткан, милләтебезне йокыдан уяткан, инкыйраз авыруына тиешле иммунитет булдыручы, халкыбызның ачы язмышын, киләчәген сурәтләгән классик язучыбыз Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең төп герое.

Укучыга тәкъдим ителә торган язмам алар хакында түгел — ә студент елларында «Җәгъфәр» (икенче кушаматы — Карахмәт) исемле якташым, яшьтәшем, фикердәшем Рәшит Фәйзерахман улы Ягъфәров, аның тормыш юлына, кылган һәм кыла алмаган гамәлләренә кыскача күзәтү- уйланулар. Һәр кеше гомере — аңлашылып бетми торган серле бер тарих. Әйдәгез, тәвәккәлләп, Рәшитнең катлаулы тормыш китабының кайбер сәхифәләрен ачып, бергәләп укып карыйк.

ТИРӘН ТАМЫРЛАР

Рәшит Фәйзерахман улы Ягъфәров 1946 елның 6 февралендә Урал тауларының көнбатыш итәгендә урманнар арасында посып кына урнашкан кечкенә генә Кучтәнтибаш авылында (хәзерге вакытта Пермь крае, Барда районы) гади колхозчы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга аваз сала. Бу көтелгән вакыйгадан соң Фәйзерахман абзый белән Әминә апаның бер-бер артлы янә биш бала туганлыктан, Рәшиткә ишле гаиләдә әти-әнигә беренче булышчы булып үсәргә туры килә. «Гаиләдә алты бала үстек. Иң өлкәне — мин. Киңәш бирүчем дә, юл күрсәтүчем дә үзем булдым», — дип язачак бу яшьлек еллары турында ул. Аның балалык еллары, үсмер чагы сугыштан соңгы, авыл кешеләре өчен ифрат авыр елларга туры килә. Түмтүгәрәк коңгырт йөзле, шомырт кара елтыр күзле, чутыр кара булып туган бу малай табигать кочагында җиләк-җимеш ашап, өйдә һәм колхоз кырларында эшләп чыныгып, бик шук, орчык сыман тиктормас җитез, бар нәрсә белән кызыксынучан бала булып үсә.

Группадашы, танылган шагыйрь



Сабакташ дусты белән. Мәктәп еллары

Мөдәррис Әгъләмов Барда яклары белән якынан танышкач, урынлы шивә-диалект үзенчәлегеннән көлемсерәп, түбәндәге шигъри юллар язып куйган:

Кыялар «кыйлар» сүзләрне,
Кыялар телем-телем —
Никадәрле кыйсалар да —
Бу минем туган җирем!

Кечкенә авылда туганлыктан, Рәшиткә үз авылында 3 сыйныф белем алырга гына мөмкинчелек була. Аннары ул якын-тирәдәге Күчтәнти, Карман, Сараш мәктәпләрендә укый һәм 1964 елда аттестат алып урта мәктәпне уңышлы тәмамлый. Мәктәп елларында ук ул тырышлыгы, үҗәтлеге, дәресләрне яхшы үзләштерүе, төрле чараларда актив катнашучы булып башка укучылардан нык аерылып тора. Рәшиткә бигрәк тә татар теле әдәбияты укытучысы Һәнүзә Хәлилова-Мортазинаның тәэсире көчле булган ахры, чөнки ул Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, укуны тәмамлап диплом алганнан соң, туган ягына кайтып эшли башлый.

ЖУРНАЛИСТ

Рәшитнең журналистика өлкәсендәге беренче адымы мәктәптә укыган еллардан ук килә, «Колхоз юлы» дип аталган район газетасында авыл тормышына багышланган тәнкыйди мәкаләдән башлана. Ул заманда газета сүзе иң зур авторитет, үзе партиянең даими күзәтүе астында. Аңлашыла ки, мондый язма колхоз рәисендә ризасызлык тудыра. Журналист сүзенең кайтавазы нинди икәнлеген бәлки аңлап та җиткермәгәндер, тик алга таба матбугатта кыю, туры әйтелгән сүзләр өчен Рәшиткә күп тапкыр җавап бирергә, судларга тартылып, штрафлар да түләргә туры киләчәк.

Профессиональ журналистика өлкәсендәге беренче чыныгуны ул 1969-1970 елларда «Таң» газетасының әдәби хезмәткәре һәм бүлек мөдире булып эшләгәндә үтә, редакция каршындагы «Таң йолдызы» әдәби иҗат берләшмәсенә җитәкчелек итә. 1970-1971 елларда берьеллык хәрби хезмәтен тутырып кайткач, янә ту-

ган ягында төбәк газетасының бүлек мөдире, Барда җирле радиотапшырулар студиясендә редактор һәм диктор булып эшли.

Рәшит журналистикада рухланып, сөенә-сөенә эшли, төрле темаларга мәкаләләр язып, газетаның эчтәлеген күпкә баета, йөгерек телле каләмен чарлый. Ул еллар турында каләмдәше Сәгыйть Нурмөхәммәтов болай дип язган: *«Үзенә дә бик ошаган материал язгач, Пушкинга охшатып «Ай-да Рәшит!» дип әйткән чаклары булды. Әмма ул вакытта да газетчыларга үз ирекләре белән актуаль темалар күтәреп мәкалә язу мөмкинлеге юк иде»*.

Казанда аспирантурада укыганда, институтта һәм башка урыннарда эшләгәндә дә аның фәнни һәм публицистик мәкаләләре көндәлек матбугатта даими рәвештә басылып бара, милли-азатлык хәрәкәтен яктыртучы ялкынлы публицистка әверелә. 1992-1993 елларда «Мирас» журналының бүлек мөдире булып эшләп алу чорында да, борынгы мирасыбызны халкыбызга кайтару эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе була.

ГАЛИМ

Рәшит Ягъфәров — иң беренче ул үзенчәлекле фольклорчы-галим. Аның балалар фольклорына багышланган диссертациясе, китап-хезмәтләре, җыентыклары халык авыз иҗаты белән кызыксынучы галим-голәмәгә, зыялыларга яхшы таныш.

Рәшитнең балалар авыз иҗаты белән фәнни яктан кызыксынуы беренче яктан балачактан килә, чөнки ул яшәгән төбәктә халык хәтерендә сакланган әкият-риваятьләр белән чынбарлык бергә яшәгән. Рәшит үзе: *«Мин әле хәзер дә Гөлчәчәкнең кайсы яланнарда йөргәнен, Аждаһаны болыт кайсы саздан алып киткәнен күрсәтә алам»*, дип әйткән. Икенче яктан, аның эчке табигатеннән, холкыннан, балалар күңеленә хас самимилектән. *«Һәрнәрсәдән кызык таба, дөньяның кояшлы утрауларын, андагы изге күңелле фәрештәләрен күрә торган саф күңелле нәниләрне бары Рәшит кенә аңлый белгәндер»* (пермь татарларының телен тирәнтен өйрәнгән танылган галимә Дөррия апа Рамазанова сүзләре).

Бардада җайланган тормышны кинәт үзгәртеп, ике бүлмәле фатирны калдырып, 1973 елда Р.Ягъфәровның гаиләсе белән Казанга күченүе дә киләчәген гыйльми эш белән бәйләү теләгеннән килә. Бер елдан соң ул максатына ирешә — Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор бүлегенә аспирантурага укырга керә.

Фольклорның иң четерекле тармакларыннан берсе булган балалар һәм балалар өчен олылар иҗат иткән, моңа кадәр фәнни дисертация итеп өйрәнелмәгән теманы алып, уңышлы ерып чыга. Гадәттә, аспирантның фән өлкәсендә алдагы уңышлары фәнни җитәкче белән тыгыз бәйләнгән була. Рәшит фәндә беренче адымнарын танылган фольклорчы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илбарис Надиров җитәкчелегендә башлый, бу өлкәгә зур өлеш кертүчеләрдән Каюм Насыйри, Нәкый Исәнбәт эшчәнлекләренең лаеклы дәвамчысы булып формалаша. Яшь галим бу фән юнәлешенә үз системасын һәм терминатамаларын тәкъдим итеп, халык авыз иҗатын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Диссертация әзер булуга карамастан, яклау советлары ябылганлыктан, озак кына яклый алмый йөрергә туры килә. Ниһаять, 1985 елда, Алма-Ата шәһәренә барып, «Татар балалар фольклорының поэтик жанрлары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклап кайта.

Төрле шартларда фәнни эшен дәвам итеп, ул 18 фәнни һәм фәнни-популяр китаплар, төрле басмаларда 600дән артык мәкалә әзерләп бастыра. Фән

өлкәсендә эшләгән кеше боларны искиткеч зур, бөтен гомерен фәнгә генә багышлаган галимнәр арасында да сирәк очрый торган казаныш икәнен яхшы аңлый торгандыр.

Рәшитнең фән өлкәсендә иң зур казанышларының берсе итеп, 1993 елда Татарстан китап нәшриятында бастырылган «Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры» исемле 336 битле китапны атап булыр иде. Бу томга автор-төзүче үзе төрле төбәкләрдә күп еллар дәверендә язып алынган 650 такмак, такмаза, сынамыш, үртәвеч, бала юаткыч, бишек җырлары, әкият, табышмак, мәзәкләр кертелә.

«Татар халкының уен фольклоры», «Уен – күңел бәйрәме», рус телендә «Татарский детский фольклор» һәм башка фәнни хезмәтләре һәм методик эшкәртмәләре мәктәп һәм балалар бакчалары тәрбиячеләре, мәктәп укытучылары тарафыннан тәрбия чараларында киң файдаланыла, алар өчен кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә.

Бихисап фәнни, фәнни-популяр, публицистик һәм иҗтимагый-сәяси мәкаләләр авторы, фән дөньясында танылган фольклорчы галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе булуга карамастан, ни кызганыч, берзаман институтта Рәшитне татар авыз иҗатын аңламый торган кеше итеп бәяләп, аны эштән азат итү турында сүз куертыла башлый. Талантлы галимгә аяк чалырга теләүчеләрнең планнары тормышка ашырылмый кала, аңарга гомеренең соңгы мизгеленә кадәр Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре булып эшләргә мөмкинчелек бирелә.

Балалар фольклорын фәнни өйрәнүчегә шигъриятне дә, әкиятне дә, уенны да, театрны да, этнологияне дә, тарихны да яхшы белү зарур. Бу елларда ул югары әзерлекле, киң карашлы, бердәнбер татар балалар фольклоры галиме булып җитешә, докторлык диссертациясен әзерли, бүлектә тикшерү үтә. Кызганыч, бүлектәге бу сөйләшү киләсе яклауны өзә, чөнки коллегалары әзерләнгән диссертациягә чыгышларында югары бәя бирүгә карамастан, «әлегә хезмәт якларга әзер түгел» дигән карар кабул итәләр, яклауга юл ачмыйлар. Диссертация язучыларның жаргон телендә ул «зарубили диссертацию» дип атала. Тикшерүдән соң мин Рәшитне тынычландырырга тырыштым, тик ул озак еллар бергә эшләгән коллегаларының фәннән ерак булган карашлары белән килешә алмый иде. Шулай итеп, фән дөньясында Рәшитнең хезмәтләре югары бәяләнсә дә, әдипкә фән докторы дигән диплом алырга насыйп булмый.

МӨГАЛЛИМ

Без укыган заманнарда авыл баласы өчен иң югары дәрәҗәдәге профессия — укытучы. Рәшит тә бу хакта болай дип әйтә: *«...Укытучыларны мин үз-үземне белә башлаганнан бирле илаһи затлар итеп күз алдыма китерә идем»*. Шуңа күрә ул Сараш урта мәктәбен тәмамламыйча, район үзәге Бардадан ерак булмаган Уса педагогия училищесында бер ел укып ала. 1955 елдан башлап биредә башлангыч мәктәпләр өчен татар укытучыларын хәзерләү төркеме уңышлы эшләп килгән вакыт. Кызганыч, хәзер инде биредә андый төркем дә юк, татар мәктәпләрендә предметларны татарча укыту да юкка чыгарылды.

Иң беренче укыту тәҗрибәсен Рәшит Барда урта мәктәбендә татар әдәбияты дәресләрен бирүдән башлый. Белемгә омтылган балаларны яраткан, татар әдәбиятын һәм телен тирәнтен белгән, күп язучылар һәм шагыйрьләр белән аралашкан яшь укытучыга беренче адымнарны ясау катлаулы булса да, авыр булмагандыр.

Бу өлкәдә нәтиҗәле хезмәтен, диссертация яклагач, Казан дәүләт педагогия институтында татар фольклоры укытучысы (1985-1990) вазифасын үтәгәндә уңышлы дәвам итә. *«Сту-*

Апас районының Борындык авылында фольклор экспедициясе вакытында. КДПИ, тарих-филология факультетының 109 нчы төркеме. Алгы планда – Рәшит Ягъфәров, Наил Нури. 1985 ел, 15 июль.
Н.Нури архивыннан

дент еллары — бик күңелле еллар. Әгәр дә сине укыткан укытучылар тарафыннан ихлас, җылы караш тойсаң, укыйсы килү теләге тагын арта. Шундый укытучыларның берсе — татар фольклорының серләренә тирәнтен төшенергә ярдәм итүче Рәшит абый Ягъфәров иде» — дип яза аның турында студентларыннан берсе Мәдинә Хәйбуллина.

Биредә эшләгән дәверендә студентлары өчен фольклор экспедицияләре оештырып, күп материаллар туплый һәм аларны кадерле ядкяр итеп Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсенә тапшыра. Хәзер алар биредә Рәшитнең шәхси фондында саклана.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының квалификациясен үстерү һәм камилләштерү өчен Рәшитне Татарстан Республикасы Укытучылар белемен үстерү институтына чакыралар. Ул биредә татар теле һәм әдәбияты кафедрасын оештыра һәм аның беренче мөдире булып кафедра эшен җайга сала (1990-1992). Суверен Татарстан республикасы ул вакытта мәктәпләрдә татар телен укыту буенча искиткеч зур эшләр алып барды, бу эшне оештыру, аны камилләштерү өчен махсус татар теле һәм әдәбияты кафедрасын оештырды.

Бу елларда бердәм татар милли мәгариф системасын булдыру өчен барган көрәштә Рәшит иң алдынгы сафта барды. Ул милли мәгарифнең үсешен гаиләдән, балалар бакчаларыннан алып югары уку йортларына, аспирантура, докторантурага кадәр дәвам иткән өзлексез система буларак күз алдына китерә, шул фикерләрне нигез итеп алып, махсус «Татар мәгарифен үстерү» фәнни концепциясен эшләүче галимнәр төркеменә җитәкчелек итә. Бу хезмәт республикада татар мәгърифәтен үстерүнең теоретик нигезләрен барлыкка китерүдә зур роль уйный. Бөтентатар «Мәгариф» ассоциациясе оештыра һәм аның рәисе булып татар мәктәбен үстерү мәсьәләләрен күп еллар игътибар үзәгендә тота.

АРТИСТ

Рәшит кечкенәдән үк җыр-биюгә гашыйк, оста итеп нәфис сүз сөйләүче булып үсә, гармунда уйнарга өйрәнә. Университетта белем алган елларында ул сәхнә серләрен, махсус театр студиясендә 3 ел дәвамында актерлык осталыгын, сәхнә телен, театр тарихын, музыка белемен, җыр-бию һәм башка предметларны өйрәнеп, актер һөнәрен өйрәнә. Муса Җәлилгә багышланган «Моабит дәфтәре» дигән фильмда татар легионерлары арасында әчкерсез елмаеп балкып торучы Рәшитне күргәч, күпләр аңарга артист язмышы юраган була.

Бардада эшләгән елларда халык театрында Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Әнгам Атнабаевның «Ул кайтты» спектакльләрендә Рәшит төп рольләрне профессионал дәрәҗәсендә уйный. Биредә үк ул үзен режиссер сыйфатында сынап карый, Мостай Кәримнең «Айгөл иле» спектакле белән күп авылларда тамашачыларны шатландыра.

Аспирантурада укыган, институтта эшләгән елларында Рәшит артистлык талантын төрле кичәләрдә мул файдалана. Гамирҗан Дәүләтшин фикеренчә, «концерт, кичәләрдә Рәшитне уздыручы юк. Ул анда драма артисты да, җырчы, биюче дә, тальян, Саратов гармуннарында башын кырын салып өздереп уйнаучы да, үз шигырьләрен укучы да». Кайбер дусларының күзәтүенчә, фәнни хезмәткәр, мөгаллим яисә милли хәрәкәтнең лидеры булуына карамастан, ул һаман да артист булып кала. Аның фикеренчә, «Кеше — яшәү сәхнәсенең артисты».

СӘЯСӘТЧЕ

Үткән гасырның сиксәненче еллар уртасында Михаил Горбачев башлаган үзгәртеп кору сәясәте Татарстан Республикасының суверен-мөстәкыйль яшәеше өчен көрәшкә юл

Авылдашы, җырчы Сәнифә Рангулова белән. 1990 нчы еллар

ачты. Таркаулыкның соң дәрәҗәсенә килеп җиткән татарларны оештыру, халкыбызның киләчәген үз кулына алу мөмкинлеге ачылудан файдалану өчен сәясәт үзәгенә каһарман татар егет-кызлары белән рәттән Рәшит тә баса. Бу вакыйгалар хакында Рәшит үзе болай язды: *«Татарның кайда да кимсетелеп, кыерсытылып яшәве миңа нык тәэсир итте. Милләтнең бу хәлдән чыгару юллары турында уйлап, газапланып яшәдем. Хәтерлим әле, 1989 елда Татар Иҗтимагый үзәгенең беренче корылтаен азан белән башлап җибәрдек. Шулчакта минем күңелемдә әллә нәрсә өзелде, күзгә яшь бәреп чыкты һәм мин шунда үземнең милләт язмышы белән аерылгысыз булуымны аңладым кебек. Күңелемдә иман яңарды һәм ул җаным белән бергә чыгар инде, мөгаен»*.

Төрле чараларны оештыручы, туры сүзле, җитәкчеләр арасында бил бөгүне яратмаган Р.Ягъфәров татар милли хәрәкәте лидерларына әверелә, Бөтентатар иҗтимагый үзәген (БТИҮ) оештыручыларның берсе, милли хәрәкәт өчен иң авыр булган 1999-2005 елларда аның рәисе булып халкыбызга хезмәт итә.

Сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе буларак, Рәшит Пермь төбәген, аерым алганда Барда районын Татарстан белән төрле өлкәләрдә хезмәттәшлекне җайга салуны башлап йөрүче һәм бу өлкәдә иң зур өлеш керткән шәхес. Бу эшне ул Казан-Пермь, Казан-Барда арасында мәгариф, мәдәният, тел, милли кадрлар әзерләү һәм башка тармакларны эченә алган күпьяклы килешүләр төзүдән башлый. Ул бигрәк тә Арча районы Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәтнең мәчет-мәдрәсәсен төзекләндерү эшен оештыра, Габдулла Тукайның нәсел җепләре Барда белән бәйләнгәнлеген яңадан исбатлый.

1993 елда Барда төбәгендә «Кама буе татарлары һәм башкортлары: тарих, милли яңарыш проблемалары һәм перспективалары» дигән фәнни-гамәли конференция аның тырышлыгы белән уңышлы уза. Мин, шәхсән үзем, Рәшитне шушы чарада беренче мәртәбә күрдем, таныштым, аның «Татарларның тарихы һәм үсү проблемалары» дигән докладын тыңлап «нинди төпле фикерле шәхес», дип сөенеп утырдым. Шул ук елны аның ярдәмендә гаиләм белән Казанга күчеп килеп, гомере өзелгәнче аралашып яшәргә насыйп булды.

ШАГЫЙРЬ

Рәшит мәктәп елларында, үткән гасырның 60 нчы еллар башында ук каләм тибрәтеп, шигырьләр яза, авыл клубы сәхнәсендә балалар өчен спектакльләргә пьесалар иҗат итә. Ул үзенең бу беренче эчкерсез мавыгулары турында болай дип әйтә: *«Хәтерлим әле, беренче шигырьләремни өчендер гел бәхетсез мәхәббәт турында гына була торган иде. Бервакыт мин ул әсәрләрне барысын җыеп Сараш интернатының мичена тыгып яндырдым. Мәгънәсе шул: Һади Такташ та шулай иткән, имеш, чын шагыйрь шундый булырга тиеш...»*.

Рәшитнең беренче шигырьләре Барда район газетасында басыла. Үзенчәлекле шагыйрь булып формалашуда Казан университетында Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Харрас Әюпов, Мөдәррис Әгъләмов, Дөлфәт Маликов (Зөлфәт), Разил Вәлиев, Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Флүс Латыйповлар белән бервакытта, кайберләре белән бер группада укыганлык та нык тәэсир иткән бугай. Шулай да ул язган шигырьләрен башка яшь шагыйрьләр шикелле сәхнәләргә чыгып укырга ашыкмаган. Ә менә өченче курста чакта «Иске тальян» шигыре белән ул үзен зур шагыйрь икәнлеген исбатлый, Башкортстанда яшәп иҗат итүче мөхтәрәм Наҗар Нәҗмидән котлау телеграммасын алуга ирешә.

Олы әдиптән фатиха алганнан соң, ул бу әсәрен һәм башка шигырьләрен еш

кына сәхнәләрдә, Тукай клубында укып, тыңлаучыларның тирән мәхәббәтен яулап өлгерә. Ул вакытта аның көндәлек матбугатта, Казанда һәм Бардада чыккан күмәк җыентыкларда шигырьләре басыла килә. Аның мәхәббәткә, атаананы, туган якны сөюгә багышланган лирик шигырьләре шушы чорга карый. *«Рәшит гомер буе романтик рухлы «сәер» кеше булып калды. Бу рухы аны бик күп киртәләрне үтәргә, кыенлыкларны көтелмәгән юллар белән җиңәргә ярдәм итте»*, — дип сагынып һәм сокланып яза гомерлек дусты һәм фикердәше тарихчы Гамирҗан Дәүләтшин.

«Шигърият чишмәләре», «Тулпарларым», «Тулпар моңы», «Генерал этәч» һәм башка китапларындагы шигырьләре үзенә генә хас образлылыгы, тирән фәлсәфи фикерлелеге, тормышчанлыгы һәм нечкә юмор хисенә бай булуы белән аерылып тора, халык поэзиясендәге сүз-сурәтләрдән оста файдалана белүе ачык чагыла, аларда гасырлар буе рәнҗетелгән татар җаны сыкрый.

Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Авыр безгә, авыр синсез тору.
Бер егылгач, авыр икән тору
Һәм яңадан дәүләтеңне кору...

САУБУЛЛАШУ

Рәшитнең тәне Казанда булса да, җаны туган ягында шикелле иде. Чөнки ул тиктомалдан гына елына берничә мәртәбә туган якларына, юкка чыккан авылына кайтып илһам алып, рухланып китмәгәндер. Авыру булуына карамастан, ул 2008 елның җәендә Күчтәнти авылының 400 еллык юбилеен оештыра, Казаннан мәртәбәле кунаклар алып кайтып, төрле төбәкләрдән бәйрәмгә кайткан якташлары, туганнары белән аралашып, бөтен чараларда актив катнашып, сәхнәдә шигырьләрен укып, биеп йөри. Күчтәнтибаш авылы урынындагы яшьти каенына: *«Йә, соңгы мәртәбә кайтуым булыр»*, — дип хушлашып китә...

Ул үзенең озын гомерле булмаячагын сизеп яшәгән бугай, чөнки бер шигырендә:

...Хәзер чамалап уйныйм да,
Чамалап кына көләм.
Чөнки барыбер түйганчы
Яши алмасын беләм,
— дип язмаган булыр иде.

Зур иҗат планнары, матур хыяллар белән яшәгән Рәшитнең гомере 2008 елның 25 августында Казанда өзелә һәм Барда зиратында җирләнә. Илаһи затларга охшаганнарны Аллаһы Тәгалә үз куенына тизрәк сыендырырга тырыша, дигән гыйбарә дөрес. Бөтен гомерен, иҗатын халкына багышлаган Рәшит Фәйзерахман улының тормышына яхшы дәлил булып тора ул. Гомер буена яшьлегендә баскан юлына тугры кала, милләтне азатлыкка чакырып, фани дөнья белән хушлаша.

Рәшит инде безнең арада күптәннән юк булганлыгына ышанып булмый, чөнки ул безнең хәтердә, күпкырлы иҗатында, җырларында яшәүне дәвам итә. Чын татар рухлы Рәшит Фәйзерахман улының иҗади мирасын өйрәнү, яшь буында кызыксыну уяту, пропагандалау максатыннан Барда районында төрле чаралар күрелә: **«Ягъфәров укулары»** оештырыла, район хакимиятенең матди ярдәме белән «Җәгъфәр» дип аталган хатирәләр китабы 2010 елда нәшер ителә. Тик бу әле аның күпкырлы мирасын өйрәнүгә беренче генә адымнар.

Тазалыгын, бөтен тормышын, көчкуәтен милләтенә хезмәт итүгә багышлаган Рәшит бөтен төрки-татар дөньясында танылды. Инде үзе дә бакыйлыкка күчкән Әнвәр Хәйри фикеренчә, *«Ул үз исемен үзе исән чакта ук тарихка кертеп калдырган талантлы милләттәшебез. Андый шәхесләрнең кыйммәте тора-тора арта гына! Мин ышанам: киләчәктә әле Рәшит Ягъфәровның киңкырлы эшчәнлеген өйрәнеп, күп китаплар, монографияләр, диссертацияләр язылыр. Ул моңа лаек шәхес»*. Амин, шулай булсын! ■

عائله درسلری

ГАИЛӘ ДӘРЕСЛӘРЕ*

Фәхрелбәнат Сөләймания

КЫЗ ВӘ ХАТЫННАРНЫҢ АТА-АНАГА, ЯКЫН КАРДӘШЛӘРГӘ ВӘ ДУСЛАРГА КАРШЫ ВАЗИФАЛАРЫ ВӘ ГОМУМИ ЭШЛӘРЕ

Гәүдәбезнең хасил булуына сәбәп булган ата-аналарыбызны артык сөймәк вә аларга никадәр күп кадер вә хөрмәт кылмак лязим булачагын һәрбер вөҗданлы адәмнең белүе шөбһәсездер. Бер ана баласын дөньяга китерә, тереклегенең куәтеннән бер кисәк булган сөте берлә аны туйдырыр. Кочагында үстерер, сөекле йөрәк җимешенең рәхәте өчен татлы йокыларын, бөтен рәхәтлекне куяр. Аның тәрбияле вә бәхетле булуы өчен җан вә йөрәгеннән тырышыр. Аның өчен чикмәгән җәфасы, итмәгән фидакярлеге калмас. Тереклегенең соң сулуына кадәр аны сөяр. Баласы бераз авырса, аның сәламәтлеген кайтарыр өчен бер тоташтан чапаланыр[1]. Аңа һәр заманда җаным дип дәшәр. Аның бу сүзе бик тугрыдыр, чөнки балалар ананың тәненнән, җаныннан бер кисәктерләр. «Җәннәт — аналарның аяк астындадыр», — хәдис шәрифе аналарның никадәр артык хөрмәт вә мәхәббәткә лаек идекен күрсәтер өчен җитәрлектер.

Ана кадерен кирәгенчә белер өчен ана булмак лязимдер. Ханым-кызлар! Аналарыгызны сөегез, аларга хөрмәт, хезмәт кылыгыз ки, алдагы көндә, үзегез ана булган заманыгызда балаларыгыздан кадер-хөрмәт күрерсез. **Аналар — балаларының башында мактаулы таҗдыр.** Аларның хәер-догалары балаларның бәхетенә сәбәп булыр.

Алланың хикмәте берлә тәнебезнең әүвәлге тамчысын мәйданга китергән — атадыр. Бу кадәр генәме? Юк, ул гына түгел! **Анабыз безгә имезгән сөтне хасил иткән азыкка кадәр вә камил адәм булып җиткәнче ашаган, эчкән вә кигән нәрсәләребез бар да аталарыбызның тырышуы вә мәгыйшәт эшләрендә һиммәтләре аркасында бар булгандыр.** Безне аталар тәрбияли, үстерә, һәртөрле хаҗәт нәрсәләребезне әзерли, безнең өчен эшли, арый, тирли, үстереп мәктәпкә бирә, безнең рәхәт вә сәгадәтебез өчен тәмам җаны-тәне берлә тырыша. Болай булганда аталарыбыз да хөрмәт кылынырга лаек, итагать вә ригаять кылынырга тиештер.

Инде дөньяга килгән бер баланың никадәр зәхмәт вә мәшәкатьләр берлә, ни дәрәҗәләрдә фидакярлекләр берлә үсеп адәм булганы уйланса, ата вә ананың матди вә мәгънәви кыймматләре хисапка алынса, ата-аналарның һич үтәп

* Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында.

[1] Чапаланыр — җәфаланыр.

бетерү мөмкин булмаган хаклары, аларга каршы хөрмәт вә мәхәббәт күрсәтүнең тиешлеге хәзер кабул кылыныр.

Җәнабе Хак ата-аналарына вә карендәшләренә итагатьле вә мәхәббәтле булганнарны сөяр. Ата-анага олуглап буйсынмак, хөрмәт вә хезмәт итмәккә дин вә инсаният йөзеннән мәҗбүрләрбез. Вөҗданлы, тугрылыклы балалар һәр заман ата-анасын сөймәк, аларга һәрвакыт ригаять итмәк, һичбер вакытта рәнҗетергә ярамаганлык вазифалары берлә йөкләнгән булганлыкларын бик ачык белерләр.

Бу мәхәббәт вә хөрмәтнең дәрәҗәләре һичбер вакыт ата-ананың һөнәрләренә яки табигатьләренә карап артык вә ким булмас. Ата-ананы, бер түбән дәрәҗәле яисә начар холыклы булса да, камил ихляс берлә сөймәк, олугламак, буйсынмак лязимдер. Күмерчелек берлә мәшһүр булган бер атаны яки чая вә холыксыз булган бер ананы начар һөнәр иясе яки холыксыз, дип сөймәгәнлек, тиешле булган хөрмәтне кылмаганлык тәрбиягә, әдәп вә инсафка хилафтыр. Алар никадәр түбән дәрәҗәдә булсалар да — ата-аналардыр. Намуска хилаф булмаган, тереклек өчен файдасы булган һөнәр вә эшләр һичбер вакытта гаепләнә торган эшләрдән саналмас. Язучылык, кибетчелек, гаскәрилек ничек кирәк булса, икмәкчелек, күмерчелек, мал ташучылык та халык өчен шулай ук кирәкледер. Атагыз урам төзәтүче дә булсын, анагыз су ташучы да булсын вә һәр көн сезне холыксыз, вак сүзлелек берлә газап та кылсын — аларның хөрмәт вә ригаять берлә кулларын үбәргә бурычлысыз. Алар сырхау вә фәкыйрь булсалар, актык сулуларына кадәр бакмак, мал вә тән берлә ярдәмдә булмак бурычыгыздыр. Ата-аналарның йөзенә ачуланып карамак, алар янында каты вә зур тавыш берлә сүз сөйләмәк, Алла сакласын, алардан көлмәк, мыскыл итмәк, үчекләмәк тәрбиягә артык хилаф вә Алла кашында ачуга сәбәп булган эшләрдәндер. Аларның сүзләренә карышмак дөрес түгелдер. Һичбер вөҗданлы ата яки ана баласына шәригать вә гадәткә хилаф булган бер начар эшне эшләргә кушмас.

КАРЕНДӘШЛӘРГӘ НИЧЕК БУЛЫРГА КИРӘК?

Карендәш ыругларга килсәк, ничек ата-анагызны сөяргә вә хөрмәт итәргә тиеш булса, аларның якыннары булган карендәшләр дә хөрмәт вә мәхәббәт, хезмәт вә итагатькә лаек булачаклары билгеледер. Болар арасында олуг булганнарының кулларын үпмәк, хәлләрен белергә вә күрешергә бармак, авыру булсалар кулдан килгән кадәр карамак, хезмәтләрендә булмак, аларны юатмак, күңелләрен табарга тырышмак, мохтаҗ булсалар ярдәм итмәк, ничек кенә булса да аларга яхшылык кылмак — карендәшлекне күрсәтмәк лязимдер. Кечкенәләрен дә сөймәк, аларга шәфкать вә мәхәббәт күрсәтеп, дошманлыкка сәбәп булырлык вә хәтер калдырырлык эшләрдән сакланмак вазифасы берлә бурычлы булганыгызны онытмагыз. Карендәш вә якыннарыгыз сезгә ят булып торсалар да, сезне хурласалар вә орышсалар да, сез янә аларны сөегез, аларны хөрмәтләгез. Инсаниятегез берлә, йомшаклылыгыз берлә аларны оятлы итегез. **Начар эшкә начарлык берлә каршы тору начарлыктан башка бернәрсә дә чыгармас.** Бер күңелне сындырмак бик асаттыр, ләкин төзәтүе бик кыендыр. Һөнәр — шелтәгә тиеш булган күңелләрне сындырмый, яхшылык берлә әсәрләндереп, күркәм хисләргә өндәмәктер.

ЯКЫННАРЫГЫЗ

Абзаларыгыз, туталарыгыз, килен вә җиңгәләрегез, ир карендәшләрегез, кыз карендәшләрегез, туганнарыгызның балалары, ирегез, каената вә аналарыгыз, каенага вә энеләрегез, килендәшләрегез, каенсеңелләрегез, үзегезнең бөтен якыннарыгыз вә карендәшләрегез, ирегезнең

якыннары алдында сөекле вә хөрмәтле булырга кирәк. Аларга салкын чырайлар күрсәтми, һәрвакыт махсус ригая вә ыспайлыклар берлә эш кылмак, йомшак вә ягымлылык берлә сөйләшмәк, аларны рәнҗетмәслек лязимдер. Бу саналганнардан кайсы гына булса да булсын, хаҗәте булганнарына көчегез җиткән кадәрле ярдәм кылмак, көчегез җитмәсә тел берлә булса да аларны юатмак, мал берлә ярдәм итә алмасагыз, гәүдә берлә эшли алырлык эшләрне эшләп, күңелләрен табарга тырышмак бурычыгыз җөмләсеннәндер.

Әби-бабаларыгыз булса, бу да сезнең өчен үзалдына бер зур бәхетлелектер. Болар картайганлыклары сәбәпле сезне борчысалар да, сабыр вә түземлелек берлә вак сүзләренә түзеп, һәрвакыт рәхимлелек, йомшаклык берлә хөрмәт вә хезмәт итегез. Алар сүзне аз ишеткән өчен күп сораучан булалар. Бу хәлләренә ачуланмый, сораган сүзләренә ягымлылык берлә тәрбия даирәсендә җавап бирмәгә, аңламаган сүзләрен яхшылап аңлатып, хәер догаларын алмага тырышыгыз. Бергә йөргәндә зурларның бераз артыннан йөрмәк, бер җиргә утырылганда алардан түбәнрәк урында утырмак, алар килеп кергәндә аякка басып, хуш күреп кабул итү әсәре күрсәтмәк, табында олуглардан әүвәл ашарга башламассызлык, һәрбер эштә көләч йөз берлә олугларның хезмәтчесе, кечкенәләрнең дә, шулай ук бер шәфкатьле юлдашы булмак инсаниятькә лязимдер.

ДУСЛАРГА НИЧЕК БУЛЫРГА КИРӘК

Ханым-кызлар! Сезнең дә үзегезгә күрә иптәшләрегез вә дусларыгыз бардыр. Дусларыгызны күркәм холык вә күркәм эш ияләреннән сайлагыз. Чөнки җүнсез иптәштән адәмгә җүнсезлек килер. Яхшылар берлә бергә булмак — изгелекләрне таратучыдыр. **Адәмнең үлчәү билгесе — йөрешә торган кешеләредер.**

Дусларыгызга кылыначак эшләр һәр заман тәрбия вә нәзакәт даирәсендә булырга тиеш. Эшне бөтенләй тозсызлыкка әйләндерергә дә ярамас. Фәкать, салкынлык берлә дә булмый, уртачалык вә ыспайлык берлә генә, муафыйк сүзләр сөйләү берлә генә утырышмак, аларның ачуларын китерә вә кәефләрен җибәрә торган урынсыз уен-көлкеләрдә булмассызлык, аларны рәнҗетмәссезлек тиештер. Аларны башкаларга хурламаслык яисә алар берлә бергәләшеп башкаларны гаепләп вә хурлап сөйләшмәслек, аларның күңелегезгә охшамаган кимчелекләрен йөзләренә ормассызлык лязимдер. Ара-тирә дусларыгыз берлә күрешә бармак, аларны һәрвакыт яхшы эшләргә кызыктырмак, ярдәмгә мохтаҗ булганнарының ярдәменә җитешмәк, халык арасында төрле начар сүзләргә сәбәп булырлык эшләрдән сакланмак, оятсыз вә әдәпсез кызлар берлә катнашмаслык инсаниятькә лязим булган гадәтләрдәндер.

Дусларыгызның шатлыгына шатланмак, кайгы вә хәсрәтләре булганда кайгыларын уртаклашмак, һәрвакыт аларга яхшы нияттә булмак лязимдер. «Үзегезгә эшләнүе теләмәгән нәрсәне башкаларга эшләмәгез», — дигән сүз бу тугрыда сезгә кыска, ләкин төпле нигезле бер юл күрсәтә алыр.

Дусларыгызга каршы ачу, үпкә, көнчелек кеби начар хәлләргә керешә күрмәгез. Хәттә һичбер кешегә дә мондый эшләр вә тәкәбберлек әсәрләре күрсәтмәгез. Барыбыз да адәмнәрбез, адәмнәр һәрберсе бер нәселдән килмештер. Һәркемгә бер-берсенә адәмлекнең, инсаниятнең лязим иттергән даирәсендә күркәм эшләр берлә инсаният кадерен сакларга тырышмак лязимдер.

Дәвамы бар

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Телне афәттән саклар өчен иң җиңел юл — мәгънәсез халыктан аулак булу, аш-су мәҗлесләренә йөрмәү вә мәгънәсез кешеләргә катышмау.

● Телнең, кечкенә генә булса да, әсәре бик зур. Тел сәбәпле олуг хадисәләр[1] чыга вә адәм баласының башына дәһшәтле фәлякәтләр[2] килә, шуның өчен Рәсүлулла хәзрәтләре телгә хуҗа булырга вә үлчәп сөйләргә боерадыр.

● Үлемнең кисәктән вә көтелмәгән, хәтта хыялда да юк вакытта килүе мөмкин, бәлки бу хәл күбрәк тә. Шуның өчен аны һәркайчан зикер итү, хыялда вә хәтердә тоту — онытмауга вә кулдан килгән кадәр әзерләнүгә сәбәп булыр.

● Үлем искә төшү сәбәпле кечкенә генә хисап ителгән бер бозыклыкның кылынмый калуы да бик файдалыдыр. Ләкин үлемне искә төшерү, дөнья үтү вә дөнья эшләренең юлда калуларына кайгырып түгел, бәлки барачак җиргә барыр өчен әзерлек күрү нияте берлә булырга тиеш.

● Хатыннарның фазыл[3] вә кәмаләтләре киемнәренең кыйммәтле вә җиһазлары күп булуда, асылташ тагулары вә модага ригаять[4] итүләрендә түгел, бәлки тәдбирле вә икътисадлы булуларында, һәм дә гаиләдә аналык вазифасын итә белүләрендәдер. Милләтнең байлык вә фәкыйрьлекләре хатыннарның икътисадка ригаятьле булулары вә модага илтифат[5] итмәүләре берлә мөтәнасибтыр[6].

● Авыл халкы бәгъзе вакыт бик юк нәрсәләр өчен ачуланышып, бере-бере өстеннән мәхкәмәләргә кәгазьләр бирешәләр вә хөкемләшеп, көннәрен уздырып, каннарын бозып йөриләр. Әгәр дә авылның яхшы картлары шушы кешеләрне килештереп йөрсәләр, кайсы гына очта ике кеше арасы бозылганын ишетү берлә, ут сүндерергә баручылар рәвешендә тизлек берлә барып, шунларның ачу утларына ут сибеп сүндерсәләр, кулларын тотыштырып яраштырсалар, дөньяда рәхмәт ишетерләр, нәфел намаз, руза савабын алырлар иде.

● Әгәр дә һәркем үз холкын төзәтсә вә үз гаепләреннән пакьләнсә, ислам милләте бу көн анадан туган кебек саф бер милләт булачак вә дөнья беткәнгә кадәр бер гаилә вә бер хәят булып гомер сөрәчәктер.

● Дөньяның бөтен хәле хыял вә өмидләрдән гыйбарәт.

● Бездә мөселманлык үлчәве кием белән булып, үзләренә мәгълүм булган формаларда йөрүчеләрне мөселман, чалма белән чапан яки җөббә кигәннәрне галим дип атыйлар.

● Күз, йөз вә аяклар белән үчекләүләр, берәүнең файдасына булган хак сүзне сөйләми, усаллык касды[7] белән тик торуларның һичбере ярамый. Бу эшләр камил мөселман булуга мөнафидер.

● Ачу — бик зарарлы эшләргә сәбәп булган гыйбрәттер. Ачулы кеше шундый эшләр эшли, шул эш, читләргә түгел, хәтта үзенең якыннарына, дусларына, бәлки үзенә дә зарар буладыр.

● Кешеләрнең гакыллары камил, сабырлары лязим дәрәҗәдә булуның дөрес үлчәве исә ачу вакытларында үз-үзләрен тота белүләредер.

● Мал булыр да бетәр, әмма кеше хакы бетмәс, киләчәктә моның хисабы соралыр.

Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

[1] Хадисә — вакыйга.
[2] Фәлякәт — бәла-кайгы.
[3] Фазыл — өстенлек, камиллек.
[4] Ригаять — игътибар.
[5] Илтифат — хөрмәт, олылау.
[6] Мөтәнасиб — тигез, бер чама, нисбәтле
[7] Касд — ният.

«Яшь Гаташ хыялы тик тормый: күккә бага ул»

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рәдиф Гатташ

(Башкортстан белән бәйле сәхифәләр)

«Сабакташым, шулай ук әдәбиятка гашыйк күрше Күккуян авылы егете Фәнүс Фатыйхов төшергән фото. Уфада, Тукай урамындагы университет тулай торагында дәрес әзерләгәндә дә яшь Гаташ хыялы тик тормый: күккә бага ул. Бәлки, янымдагы кыз (Венера атлы!) илһам бирә?» 1960 ел

***

«Уфада университет буенча өлкән төркемдәшем, язучы, журналист, элекке офицер Вазыйх Исхаков белән дуслыгыбыз (1985 елның гыйнварында китте ул...) гомерле булды. Татарның атаклы революционерлары М.Вахитов, Х.Мәүлетов, сугыш яугирләре Я.Чанышев, Ә.Бәхтизин һ.б. турындагы роман-повестьлары, публицистик китаплары Уфада да, Казанда да дөнья күрде. Беренче шигъри тәҗрибәләремне, хуплап, үстерергә теләп, «Яшь көстәр» альманахына биреп, бастырып чыгаручы да ул булды. Иҗтимагый аң, тарихи күзаллау дәресләрен дә алдым өлкән дустан: рәхмәтлемен аңа!» 1960 ел

***

«Яшьлекнең кумиры һәм гомер буе без, яшьрәкләр, ихтирам иткән, чын халыкчан шагыйрь һәм гаҗәеп колоритлы шәхес Әнгам Атнабаевның гаиләсе белән дә таныш идем. Агыйдел бу-

енда ял иткәндә Хәйдәр Басыйров атлы дустым (журналист, китаплар язган Чакмагыш егете) төшергән сурәт». 1963 ел

◀ «Вазыйх Исхаков белән дуслыгыбыз гомерле булды»

***

«Шул ук — атаклы Атнабай — безнең яраткан шагыйребез И.Юзеев белән Казан университеты студентларының кунагы булды. Бу бик маҗаралы мәҗлес булды: кунакларны озаткач, тулай торакта бүлмәдә юктан чын ызгыш-сугыш чыгып, университетның «Ленинец» газетасында бер «дус» ялган информация белән, Атнабайны да хаксызга җәнҗалга «катнаштырып», мәкалә дә бастырган иде. Ул мәкаләне Уфага, хәтта обкомга ук ирештергәннәр. Хатыйп дус Миңнегулов белән без аңа «опровержение» язып, имзалар оештырып, Уфага да хат язуыбыз хәтердә әле...»

«Агыйдел буенда...»

«Маҗаралы мәҗлес»

«Нажар Нәҗмигә баш ию»

***

«Нажар Нәҗми белән татар әдипләренең дуслыгы гаҗәеп бер җыр-легенда кебек иде. 1999 елда вафат булгач, туган авылында һәм Дүртөйледә һәйкәлләре куелгач та, аңа баш иергә бардык. Бу — 2008 ел фотосы: бергә кайткан Роберт Миңнуллин төшерде (бергә кайтуларның берсендә). Халисә Мөдәррисова һәм ике республиканың халык артисты Илсөяр Газетдинова белән Н.Нәҗми исемендәге мәдәният йортында».

***

«Уфадан китүенә егерме елдан артык гомер узгач, янә университетта, «Акчарлаклар» татар әдәбият түгәрәгенең 30 еллыгында, элекке укытучылар, яшь иҗатчылар һәм башкорт шагыйрьләре, әдипләре белән бергә, Госман Садә белән без — Казаннан, «Әллүки» түгәрәгеннән чыкканнар һәм студент кунаклар. Атнабай, әлбәттә, «Акчарлаклар»ның иң якын дусты иде!» 6 апрель, 1984 ел

«Акчарлаклар»

«Туган яктагы бер кичә»

***

«1988 елның май аенда Башкортстанда Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре узды. Мин Г.Ахунов җитәкләгән төркемдә идем. Чакмагыш, Дүртөйле, үземнең Кушнаренко районында булдык. Нажар ага Нәҗми белән бергә. Туган яктагы бер кичәдән бу».

***

«Гомернең иң илһамлы мизгелләре бөек җырчыбыз Фәридә апа Кудашеваны тыңлау, үзе белән очрашулар — Казанда каршылау-озатулар булды. Бу рәсем — бөек җырчыны соңгы кат күреп, сөйләшү истәлеге. Шәмсия Җиһангирова белән бергә өчебезне әлеге Роберт дус төшергән сурәт». 2010 ел ■

«Фәридә Кудашева хозурында»

ГАРИФ БАБАЙ ДӘРЕСЕ

Фоат Галимуллин

Әле без малай чагында авылыбызда Гариф исемле бер бабай бар иде. Кечерәк кенә буйлы, какча гәүдәле, ап-ак сакал-мыеклы, җиңел сөякле. Шактый олы яшьтә булса да, бик җитез иде ул! Шул бабай җәй көннәрендә су буенда каз бәбкәләрен саклап йөртә, кәҗә, сарык бәтиләрен тау итәгенә үлән чемченергә алып чыга. Ак күлмәге өстеннән камзул кия, башында исә түбәтәй. Башка бабайлардан аермасы шунда, кулында һәрвакыт диярлек яулыкка төрелгән ниндидер китаплары булыр. Ул аларны укымый да шикелле, әмма үзе белән йөртә. Карчыгы мин белгәндә юк иде кебек. Күрәсең, әле без туганчы ук вафат булган. Ул бердәнбер улы Васил абый гаиләсе тәрбиясендә яши.

Менә шул Гариф бабай, каз бәбкәләре, кәҗә-сарык бәтиләре су буенда рәхәт чиккән вакытларда, аларга карый-карый, шулар белән сөйләшә-сөйләшә, чирәмдә утырып тора. Юк, тик кенә утырмый, авыз эченнән, кайчакта шактый ук тавышын көчле генә иттереп көйли. Янынрак үтеп йөрүчеләргә дә исе китми, җырлавын белә. Еш кына «Тәкый гаҗәп тыңларый бар» дигән сүзләрен абайлап калабыз. Җырының башка урыннары әллә ни аңлашылмый, ә менә шушы сүзләр бу көнгә кадәр колакка эләгеп калган. Малайлар арасында бабайның исеме дә «Тәкый гаҗәб» кенә.

Безгә, малайларга, бу бабай бик серле булып тоела. Шулай булмыйча, әнә безнең очта Закир Галие, Дияр Шакиры, Гыймади, Әлим, Мостафа абзыйлар бар. Аларның берсе дә аның кебек җырлап йөрми. Җырлары да нинди бит әле. Әллә нинди хәзерге кешеләр белми торган моңлы җырлар, сүзләре дә аңлашылмый. Ниндидер китапча иске сүзләр.

Әби әйтә:

— Гариф абзаң бик зур мәдрәсәләрдә укыган, озак укыган. Безнең авылда аннан да гыйлем кеше юк. Бөтен гомерен китап укып, аларны күңелдән сөйләп уздырды. Башка эшкә күңел салмады. Мал арттырам, дип вәсвәсәләнмәде. Әүлия нинди була дисәләр, менә Гариф бабагыз кебек буладыр инде. Үзен дә бик кадерләп йөрттеләр. Сәвит чыккач кына кирәге бетте, — ди.

...Кайвакыт ул безнең белән дә сөйләшеп ала. Ник дигәндә, ул җырлый башласа, без дә аның янына елышабыз. Якын ук бармыйбыз, унбиш-егерме адымнар чамасы читтәрәк утырып торабыз. Якынаерга үзе кушмый.

— Минем җырлаган җырларымның мәгънәсен белми торыгыз. Юкса, мине гаепләрләр. Син балаларга дини җырлар өйрәтәсең, диярләр. Әнә шуннан торып кына тыңлагыз, көе ишетелерлек булса, шул җиткән.

Аннан соң, көрсенеп әйтеп куя:

— Их, заманнар, бар иде рәхәт чаклар, үзем өчен генә түгел, кешеләр алдында да мөнәҗәтләр әйткән вакытлар, авызларын ачып тыңларлар иде...

Менә ара-тирә шулай сөйләшкәләгән вакытларда ниндидер аңлашылып бетмәгән сүзләр әйтеп куйгалавы белән дә сәер тоела ул безгә. Без үзара нәрсәне дә белергә теләсәк, моны Гариф бабайдан сорарга кирәк, ул әйтер, дип әйтеп куябыз. Чыннан да бабаебыз бер дә җавапланмый калмый торган иде.

Арабызда Билалетдин дигән малай бар. Ул — Мәрьяматтәй улы. Безгә күпмедер туган тиешле. Әбиебез, олылап, аны абыстай дип йөртә. Шул ма-

Фоат Галимуллинның бабасы Галимулла Яруллин туган йорт. Арпаяз авылы. Галим һәм әдип шушы бинада башлангыч мәктәптә укыган (1948 -1952). Хәзер бу йорт файдаланылмый. Әле дә шушы хәлендә тора. Совет хакимияте елларында өске катта мәктәп, аскы катта ашханә була. Сугыш елларында кечкенә Фоатны да шунда пешкән «Америка боткасы» ашарга дип беркетәләр. Өйдә балага ашатырлык та ризык булмый.

лай бик башлы, әллә нәрсәләр белә, белмәгәнен үзе уйлап чыгара.

Бервакыт без бәхәсләшеп киттек. Безнең авыл Арпаяз дип атала. Аңа ник шундый исем кушканнар? Нигә нәкъ менә Арпаяз? Ник Бодайяз, Борчакяз, Тарыяз түгел? Нигә нәкъ менә арпа?

Билалетдин, ике дә уйламыйча, әйтеп куя:

— Безнең авылда элек бай кешеләр яшәгән. Арада берсе аеруча бай булган. Алтыннары бер сандык тулы икән. Әмма ул аларны сандыкта түгел, ашлык кисмәгендә саклаган. Шул кисмәккә алтын тутыра да, өстенә калын гына катлам итеп арпа салып куя. Бер кисмәк арпа, имеш. Бервакыт, ул үзе өйдә юк чакны туры китереп, моның өенә караклар төшә. Бу йортта алтын барлыгын тәгаен беләләр. Эзләмәгән җирне клдырмыйлар, әлеге кисмәкнең дә өстен ачып карыйлар. Әмма алтыннарны таба алмыйлар. Шуннан соң хуҗа, бик канәгатьлек кичереп әйткән, имеш:

— Мин каракларны арпа белән язырдым! Ягъни, тагын да аңлаешлырак итеп әйткәндә, алдадым!

Шуннан соң бу авылны Арпаяз дип йөртә башлаганнар, имеш.

— Минем дә әнидән шулайрак дип ишеткәнем бар-барын... Әйдә, шулай да без бу турыда Гариф бабайдан сорыйк.

Барыбыз да бердәм булып, гадәттә Гариф абзый җырлап утыра торган Кәримәттәй бакча башындагы үр өстенә таба йөгерәбез. Чыннан да, абзыебыз үз урынында иде. Ул бу юлы җырламый, күзлеген киеп, әнә шул һәрвакыт үзеннән калдырмый торган юка гына төргәкне сүтеп, бер китабын укый. Күрәсең, бик мавыккан. Шуңа күрә әйләнә-тирәсенә килүебезне сизмәде дә кебек. Ник дигәндә, янына килеп баскач, сискәнеп киткәндәй итте. Тиз генә яулык белән китапны төреп тә куйды. Аннан, сорау көткәндәй, безгә карап тора башлады.

Иң беренче булып Билалетдин телгә килде:

— Бабай, менә миңа ышанмыйлар.

Кайчандыр кемдер, алтынны арпа белән каплап куеп, каракларны алдаган да, шуннан безнең авылның исеме килеп чыккан, дим. Миңа моны әни сөйләде, ә аңа бабасы әйткән булган.

Гариф бабай кинәнеп көлемсерәп куйды. Аннан әкрен генә сөйләп китте:

— Ә-ә, аны әйтәсең икән. Әйе, шулай дип әйтәләр әйтүен.

Ул арада Шәвәли дә өстәп куя:

— Минем әни дә кыш көне кич утырганда бу әкиятне хатыннарга сөйләгән иде.

Бабай сорап куя:

— Бик танып бетермим, синең атың кем әле?

— Безнең атыбыз юк шул.

Малайлар егыла-егыла көләләр, бабайга да кызык була.

— Исемең ничек дим, исемең?

— Ә, аны әйтәсең икән, Шәвәли...

— Җиһанша малае буласың инде, алай булгач. Атаң сугыштан кайтмады. Мәрьям дә, синең әниең Маһинур да яшь чакларында ишеткәннәрен сөйләгәннәр. Авылның исемен сез әйткәнчә аңлату күптәннән халык телендә йөри. Мин дә бала вакытттан ук ишетеп яшәдем аны. Яши-яши, китаплар укый-укый төпченә торгач, башкачарак уйлый башладым.

Без, кемдер кушкандай, барыбыз да Гариф бабай алдына урнаштык. Кем утырып тора, кем ятып дигәндәй...

Бабаебызның моңа бик кәефе килде. Ул үзенең белгәннәрен яшьләргә сөйләячәк! Бу юлы моның өчен шелтәләмәсләр, шәт. Сүз дин турында түгел бит. Ул беразга тынып калды. Аннан сүзне сорау бирүдән башлады:

— Безнең авылның исемен ничек итеп әйтәләр? Арпаязы диләрме, әллә Арпаяз дипме?

Бу юлы минем абыем Хәкимулла өлгеррәк булып чыкты:

— Безнең Өшендәге Шәмсевәлия тәтә Арпаязы, ди. Арпаязына барам, Арпаязы чишмәсе, ди.

Баян Тимергалие аңа каршы килә:

— Нинди Арпаязы булсын, Арпаязга барам, Арпаяздан кайтам, диләр.

Бабай, көлемсерәп, бәхәсне тыңлап тора.

— Арпасы арпа инде, бодай түгел. Оланнар, быел арпаны кайсы басуга чәчтеләр?

— Үрмәкә басуында, — дип, үзенең белгәнен күрсәтә Хәйрулла Мөнире.

— Үрмәкәдә үк икән, бик ерак шул. Ат белән алып барып кайтмасалар, минем аяклар белән барып җитешле түгел икән... Сез әйткәч, арпа басуын күрәсем килеп китте бит әле. Гади халык икмәге быел ничек үсә икән?

Бабай яңадан сүзнең җеп очын кулына алды:

— Әйе, хәзер халык җиңел генә Арпаяз диеп сөйләшә сөйләшүен, әүвәле бары тик Арпаязы гына диләр иде. Менә әйтегез әле, «яз» белән «язы» дигәндә, бу лөгатьләр, ягъни-мәсәлән, сүзләр нәрсәне аңлаталар, дип уйлыйсыз?

— Яз?! Аны да белмәскә! Салкын кыштан соң җылы яз килә. Сыерчыклар кайта!

— Менә шул-шул. Син баштарак үзең үк әйткән яздыру, адаштыру дип аңлатудан бөтенләй баш тарттың. Инде әйт, арпа сүзе белән яз сүзе нигә безнең авыл исемендә бергә кушылганнар дисең?

— Белмим шул, бабай. Моны син әйтерсең дип килгән идек.

— Нәрсә әйтим? Борынгылар юкка гына Арпаязы димәгәннәрдер. Арпа язы. Ягъни-мәсәлән, арпаның язы дип аңлашыла. Уйлап карасаң, арпаның язы, бодайның язы, солының язы буламы икән? Дөрес, көз көне болайрак дип әйтәләр әйтүен: быел бодай елы булды, бик уңды; быел борчак елы булды... Әмма бу уңыш җыеп алынгач әйтелә торган сүз. Яз көне нәрсәнең ничек уңасын фаразлау кыен, шуңа күрә алай әйтеп тә булмый. Шулай икән, язы дигәндәге мондый мәгънә бик үк туры килми.

— Алайса, язы сүзе нәрсәне аңлата икән соң?

Моны гел малайлар белән уйнап йөрүче таза кыз Нурания әйтә.

— Язы сүзенең мәгънәсен белмисез сез. Шуңа аптырыйсыз. Язы — басу, кыр дигәнне белдерә. Белмәсәгез, белегез. Арпа язы — арпа басуы, ягъни мәсәлән, арпа чәчелгән кыр була. Шулай икән, безнең авыл тирәләрендә элек-электән арпа чәчкәннәр, арпа үстергәннәр. Аңладыгызмы инде, тишек борыннар?

— Аңладык та, — ди Әһлетдин, — ә нигә арпа күп чәчкәннәр? Нигә бодай түгел, ясмык түгел?

— Нигә, нигә? Моңа да җавап биреп була. Бу җирләрне арпа бик яраткан, мул булып үскән, дип уйлыйм. Нәрсә мул уңыш бирсә, шуны күбрәк чәчәргә тырышканнар. Сүз дә юк, бодаен да, солысын да үстергәннәрдер. Ипи пешерергә, атка ашатырга бик тә кирәк бит алар. Ул вакытларда бигрәк тә.

Бабай үз-үзенә генә сөйләнгәндәй, дәвам иттерде:

— Арпа турында сүз чыккан икән, шуны да әйтергә кирәк, ул борынгы заманнардан бирле игелгән, дип беләм. Иске китапларда аның турында сүзләр очрап тора. Коллар, ирексез кешеләр ризыгы булган ул. Кешене кол иткәндә әйтә торган булганнар: моннан соң аңа арпа ипие генә ашатырга! Төп ризыгы шул булсын! Әле менә сез килгәндә, мин «Йосыф китабы»н укып утыра идем.

Бабай, яулыкны сүтеп, тузып беткән китап чыгарды. Малайлар, аны әйбәтрәк күрер өчен, бабай алдына иелделәр. Яшел-кара төсле гарәпчә хәрефләр белән чуарланган китап битләре кулдан язылган иде. Малайлар, әлбәттә, аның бер генә хәрефен дә танымыйлар. Шуларны укый белүче бабай алар алдында тагын да серлерәк булып тоела башлады. Гариф абзый, әкрен генә актара-актара, кирәкле урынны эзләп тапты:

— Менә, Йосыфны кол итеп сатканда, агалары малайның яңа хуҗасына болай диләр:

Һәргиз аңа изгү сүз сүзләмәгил,
Тәгам арпа үтмәки виргел имди.

Нәрсә диләр? Аңа, Йосыфка, яхшы, җылы сүз әйтмәгез, ашарына арпа икмәге генә бирегез. Арпа икмәге генә ашау — ул инде кеше кол хәлендә дигән сүз икән. Хәзер, сәвит вакытында, алай түгел, арпа ипие булса, бик рәхәтләнеп ашар идек тә... Бу борынгы вакытларда шулай булган.

Билалетдин — акыллы баш — барыбыздан да уздырып сорап куймасынмы:

— Бу нинди китап соң? Йосыф дигән кешене нигә кол итеп сатканнар? Җитмәсә, агалары шулай эшләгән дисең, бабай?

Бабай сискәнеп китте, куркынып, як-ягына каранды. Үзенең, кызып китеп, мавыгып, чикне узып киткәнлеген сизде. Тиз-тиз генә китабын яулыкка төреп куйды.

— Юк, болай гына, бу бернинди дә китап түгел. Бер иске язу шунда. Йә, каз бәбкәләремне алып кайтырга вакыттыр...

Гариф бабай урынынннан торды, су янында үлән чемченеп йөргән каз бәбкәләре янына таба атлап китте. Без, шушы бәләкәй генә гәүдәле, түбәтәе астыннан ап-ак чәчләре күренеп торган бабайның мәктәптәге укытучыларыбыздан да күп белүенә тәмам гаҗәпләнгән малайлар-кызлар, аптырап карап калдык.

Бераздан барыбыз бергә Кырмач болыны буендагы буага су коенырга йөгердек. Нурания генә, иһ, нигә мин дә малай булмаганмын дигәндәй, өенә кайтып китте...

20 гыйнвар, 2016.
Аккош күле ■

Редакциядән: Даими авторыбыз, филология фәннәре докторы, профессор **Фоат Галимулла улы ГАЛИМУЛЛИНГА** 21 мартта 75 яшь тула. Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез. Мөхтәрәм галимнең яңа хезмәтләре белән журналыбызның 2016 елгы саннарында таныша аласыз.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

....

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Тәгамь бир һәркеменә, калмасын ашсыз.
Берәү дә йөрмәсен «мин калдым ач», дип.

Коры-сары белән сыек ашларны,
Җимеш белән шикәр-балны алмаштыр.

Хәлең җитсә, ертыш йоласын үтә,
«Теш хакын»[1] бир, шулчак артык сүз бетә.

Аш-су турында сүз төкәнде, тәмам.
«Кайтыйм», дисә кунак, озат капкадан.

Чакырулы булыр бу ашка дүрт төр,
Баручы төре дә гадәттә дүрттер.

Берәү ашка килә кем өндәсә дә,
Кыстатмыйча ашый биргән нәрсәңне.

Ләкин үз өенә кунак чакырмас,
Ашый *бер борынга*[2] өйдә ялгыз баш.

Икенче берәүләр ашка барырлар,
Үзләре дә, күр дә тор, чакырырлар.

Өченчеләре исә чакырсаң, килми,
Үзләре дә ашка чакыра белми.

Тере димә андый затны, үлек ул,
Кеше белән кеше була белми ул.

Тагы бертөрлесе ашка бик йөрми,
Ләкин үзенә еш кунаклар өнди.

Менә моның һәйбәт юсык-юрыгы,
Бөкә-белкә мактый аның кылыгын.

Кирәк — ашка йөре, кирәк — йөремә,
Күп ашау саулыкка китерми бер дә.

Күп ашаган бәндә һәрчак хаста ул,
Йөзе саргылт булыр, авыр атлавы.

Менә нәрсә әйтә бер имче, күрче,
Сәламәтлек һәм дә холык белгече:

«Тамактан керә чир, агулый ашың,
Чир картайта, кеше яшәми яшен.

Тамагын тыйган зат яшәр дарусыз,
Агарынып йөрмәс, алсу булыр йөз».

Менә шулай кунак – табын тәртибе,
Өндәү һәм өндәүгә баруның ибе.

Белгәнне сөйләдем аш-су турында,
Бу хакта сүзләрне туктатыйк шунда.

Кирәк – ашка йөре, кирәк – йөремә,
Күп ашау саулыкка китерми бер дә.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

[1] Ертыш – «бүлгәләп кунакларга бирелә торган тукыма-кумаш кисәкләре», татар-башкортларда бигрәк тә туй мәрасимендә кулланыла. Теш хакы – «күчтәнәч» мәгънәсендә булса кирәк.

[2] Чагыштыр – хәзерге телебездә *«оч борынга керү* – очәүләшеп мәҗлес оештыру».

Бу дөньяның шулдыр юсык-юрыгы —
Кеше белән кеше булу кызыгы.

И, күңелем нуры, хаклык сөючем,
Сүземә игътибар ит, зинһар өчен.

УЙГЫРМЫШ ҮГДЕЛМЕШКӘ ҮЗЕНЕҢ ДӨНЬЯДАН ЙӨЗ ЧӨЕРЕП, ТЕГЕ ДӨНЬЯНЫ КӨТҮЕН СӨЙЛИ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – Сүзеңне
Ишеттем, инде син тыңла үземне.

Синең бу сүзләрең дөрес. Аларны
Тоткан зат һичшиксез тотар дөньяны.

Ләкин ул эшләрне кылыйм, дигәнче
Белү кирәк, углан, шуны тирәнтен.

Кеше шундый михнәт белән казганган
Мөлкәт нигә гомер бик аз калганда.

Бу дөньяны куып йөрсә ки кеше,
Ятып кала тагать-гыйбадәт эше.

Күр, син килгәләгән шушы арада
Азмы гыйбадәтем калды казага?

Бирәү белән шулай булашсаң, инде
Күпләр нишләр? Гафу, кичләмә мине.

Авыл-шәһәр ара йөргән чагымда
Ничә сүз һәм эшләр чыгар тагы да?

Кайчан гыйбадәткә вакыт табылыр?
Димәк, миңа тагать юлы ябылыр.

Тиле яшьлек үтеп, картайган мәлдә
Яшәдем тагатьтә һәм кылдым тәүбә.

Инде кыргыйлыкка кабат китимме?
Килешерме миңа бу эш, рәхимлем.

Ни күп белек бирдең, дәрья гыйлемлем,
Ишет инде мине, әүлиям минем.

Егетлектә кыл син карыйлык эшен,
Җитешми, картайгач, вакыт һәм көчең.

Егетлектә тырыш, гыйбадәттә бул,
Картайгач, зыяны булмас аның, бел.

Бу дөньяны куып йөрсә ки кеше,
Ятып кала тагать-гыйбадәт эше.

Яшьлектә һәрякка изге юлны тот,
Олгайгач, сөнгә бара ич дәрт, ут.

Ни шәп хәл ки, күрче, егет чагында
Кеше кямил булса барча ягыннан.

Ни кызганыч хәлдер, картайгач, кеше
Кылмакчы булса нәкъ егет кылмышын.

Дөнья малы кирәк тереклек өчен,
Яшәү бетсә, мөлкәт җуя мәгънәсен.

Гомрен сарыф итеп мөлкәт җыючы
Үлгәнендә әйтер: кая куйыймчы.

Мин кылсам син әйткән дәүләт хезмәтен,
Белеп дуслык, тәртип, халык гадәтен,

Азакта ни файда миңа, үземә,
Кирәк булгач ике парча бөз генә...

Тырышып, бер тирләү һәм бер туңудан
Нәтиҗә икедер тик, мөселман.

Бере – дөнья малы шатлык күңелгә,
Икенчесе – сүзең үтә иленгә.

Дөнья малы кирәк тереклек өчен,
Яшәү бетсә, мөлкәт җуя мәгънәсен.

Шәп булыр иде дә шундый хәлеңдә
Үлем килми, яшәп калсаң мәңгегә.

Бар иде ул хәлләр, тик үлем килде,
И, акыллым, дөнья нәрсәгә инде?

Кеше котлы булса, билгеләре бар:
Аның игелеге балкыта нурлар.

Кешене өйрәтсә котсыз кемсәләр,
Картлыгы килгәндә бигрәк пис[3] алар.

Гыйльме киң бер белкә шәп сүз калдырган
(Ишет һәм хәтерлә, ал йөзле туган):

Кеше котлыгы шул – олыгая барып,
Исәрлеге бетсә, изгелек артып.

Төгәл билгеле карт зат котсызлыгы:
Йөгертә нәфесе һәм комсызлыгы.

Кайда ул җир шаһы булам, дигән зат –
Тимер шәһәр корып яшәгән Шәддат?

Кайда ул җаһил эт – җиргә һәм күккә
Шаһ булмакчы Нәмрут, каракош җиккән?

Кайда ул «мин – Тәңре» дигән фиргавен[4]?
Су төбенә бәрде Тәңребез үзен.

Кайда ул хисапсыз мал җыймыш Карун?
Җир аяусыз йотты үзен һәм малын.

Кайда ул гарептән шәрыккә кадәр
Җир яулаган «мөгезле Искәндәр»[5]?

Кайда таягыннан зур елга ясап,
Диңгездә коры юл ярдырган Муса?

Кайда ул җеннәргә, хәтта, баш булган
Дөнья хөкемдары Сөләйман?

Кайда ул үлекләр тергезгән Гайсә?
Аның үзен тотып астылар хачка.

Кайда кешеләрдән иң-иң сайланмыш
Мөхәммәт. Ул да юк – дөнья хәзер буш.

Бу мәзкүрләрне дә тоткач, соң үлем
Аярмы сине, и, холкы күреклем.

Бу рәвешледер ул бу дөнья заңы,
Кирәк ничек уйла, истә тот аны.

Багып күр син җирнең кара куенын:
Ничә кеше керде – тик юк туемы.

Ачып, күрсәң иде җир катламнарын –
Ничек ятканнарын асыл затларның.

Ни шәп бәкләр кара җиргә катылган,
Ни белкә-бөкәләр череп юк булган!

Җир астында колны бәктән аермам,
Һәм аермас күзем байны ярлыдан.

Тап-таза һәм көяз, шәп егетләрнең
Юк монда тын-өне һәм кан тибрәве.

Менә шундыйлар да ябынгач җирне,
Синме соң, йә минме калырбыз тере?

Йөрүле-торулы ярсу зат-инсан,
Бер тарафка сапмас барган юлыннан.

Үземнән китәрдем арзу-теләкне,
Бер Алладан үзгә юктыр йөләгем[6].

Кешене кол иткән соклык-комсызлык,
Нәфестән котылдым, инде күзем тук.

---

[3] Пис – «күңел кайтаргыч, әшәке» (татар сүзлекләрендә еш кына китерелә).
[4] Мөселман язучылары фиргавен дип бер генә кешене – Муса пәйгамбәрне куып, диңгезгә баткан фиргавенне генә беләләр.
[5] Мөгезле Искәндәр – Александр Македонскийның кайбер һәйкәлләрендә ике мөгез сыман чыгынты – тиара бизәге күренә. Шуннан чыгып, мөселманнар аны «Искәндәр – Зөлкарнәй» – «Ике мөгез иясе Искәндәр» дип атаганнар. Аның «ике мөгезле» булуына баглап төрле хикәятләр, мәсәлләр чыгарылган. Ике мөгезле тиара исә борынгы Мисырдан килгән.
[6] Йөләк – «арка үзәге, умырткалык», күчермә мәгънәдә «төп терәк» – (бу сүз татар сөйләшләрендә дә бар).

Ни ди, әнә заһит булган кемсәләр,
Дөнья кайгыларын куйган кемсәләр:

Дөньяда үземә кирәкне таптым —
Хирыс күзлегемне еракка аттым.

Читкә куйдым дөнья максат-арзусын.
Теләгем төкәнде, әйтелде сүзем.

Бу дөнья, асылда, чәчүлек мәйдан —
Ни чәчсәң, нәкъ шуны урырсың анда.

Игелекләр чәчсәң, уңар игелек,
Игелектән чыгар аш һәм кигелек.

Яман орлыклардан яманлык туар,
Ул исә җилкәңә менеп үк кунар.

Нәфес – арзулардан арынмасам, мин
Изгелек хәленә ирешәлмәмен.

Сине куймый икән, син дөньяны куй,
Синнән туймый икән, син дөньядан туй.

Син аны куймасаң, куяр сине ул,
Син аннан туймасаң, туяр үзе ул.

Әгәр шулай икән – нигә бу дөнья?
Шулай уйный икән – сана уенга.

Теге дөнья эше уеңда булсын,
Уең мәңге яшәү турында булсын.

Тагын да игерәк дөньяны ташлап,
Ахирәтне генә кайгырта башлау.

Ике дөнья бер куш, иясе дә бер,
Ник бу дөнья? Язмыш тегесендәдер.

Түрәткәнне тапсаң, түрәлү – сиңа,
Ябалтканны тапсаң, ябалу – сиңа.

Түрәткәнгә тагать итүне куеп,
Түрәмешкә хезмәт итимме оеп?

Ике төрле була хезмәтче хәле,
Йә хезмәте ярый – арта сәмәне.

**Теге дөнья эше уеңда булсын,
Уең мәңге яшәү турында булсын.**

Йә – ярамый. Үзе имгәк диелә
Вакыты заяга китә, ул бөлә.

Яраса хезмәт, бий күтәрсә тагы,
Ирексез ул, сәрай җибәрми аны.

Бер ач, бер тук ялчы йөгергән чакта
Бий мәшәкать чикми, ял итеп ята.

Әгәр хезмәтләре ошамаса, күр,
Әрәм була менә бөтен бер гомер.

Кайда хезмәткәргә, әйтче, файдасы
Бу хезмәттә табыш – асу[7] кайда соң?

Ни ди, ишет, әнә бер Ил иркене[8]
(Хезмәтче хакында дөрес хөкемле):

«Багып күрсәң, начар бийләрдә эшләү:
Хезмәтеңчә генә бәяләмәсләр.

Хезмәтең яраса югалыр иркең,
Ярамаса, абруй төшәр көннән-көн».

Ышанма хезмәткә, и, хезмәте бар:
Шәп хезмәткәр булыр, ахры, бер тавар.

Бийем мактар, дисәң, сасытып сүгә,
Бий шатлана, дисәң, ул кашын төйгән.

Төгәл белеп булмый аның кылыгын:
Алынырмы аннан тиеш алыгың[9].

Төпсез, егет, читсез, дөнья кәрабы,
Җил ул, күләгә ул, юктыр карары.

Сагым[10] кебек ич ул – күренә генә,
Тотыйм, дисәң, бетә, юк була кинәт,

Бу идарә коры[11] килер кизүле,
Тиз үк корыр, бер тере ул, бер үле.

Дәвамы бар ■

[7] Асу – «табыш» – татар сөйләшләрендә хәзер дә кулланыла.
[8] Иркен – «феодал» (булса кирәк). Әркян «дәүләт эшлеклесе» булырга да мөмкин.
[9] Алык – «алына торган нәрсә (эш хакы һ.б.)», алыкман – «(товарда) нетто; урылган игеннән чыгасы (көтелгән) ашлык күләме».
[10] Сагым – «мираж; проекция».
[11] Кор – гомумән «билбау», монда «вазифа», пост.

ШАГЫЙРӘ ГАЗИЗӘ БАҺАВЕТДИН КЫЗЫ СӘМИДОВА

Җәвад Алмаз

ШАГЫЙРӘНЕҢ КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

Газизә Сәмидова* матбугатта танылган шагыйрә түгел. Аның ярты гасырга якын вакыт эчендә язып килгән шигырьләре Көнчыгыш институтының Ленинград бүлеге китапханәсендә кулъязма хәлендә генә сакланган.

Бу кулъязма берничә вак дәфтәрләрдән тора. Беренче дәфтәр 1876 елда башланган. Аның беренче битендә мәчет сурәте, икенче битендә ул вакыт өчен характерлы булган намазлык, комган, тарак, башмаклар, каюлы читек, кайчы кебек нәрсәләр һәм йорт кошларының рәсемнәре төшерелгән. Дәфтәр битләренең чите төрле конфет, сабын кәгазьләре белән бизәкләнгән. Һәр дәфтәрнең беренче битенә борынгы кулъязмаларга охшатып бормалы сызыклар белән нәкыш йөртелгән.

Дәфтәрдәге һәрбер сызык бөтен нәрсәне матурларга, гомер буе саф, керсез яшәргә омтыла торган яшьүсмер кызларны күзаллата, андагы ягымлы күренеш җанга җылылык бирә; шул ук вакытта бу битләрдәге гадилек һәм сабыйларча җитдилек чак кына елмаю кузгата.

ШАГЫЙРӘНЕҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ

Кулъязмаларда кайбер тарихи вакыйгалар һәм Газизәнең үз шәхси тормышына карата булган даталар бар. Шуларга таянып һәм кайбер шигырьләрнең эчтәлегеннән чыгып, Газизәнең тәрҗемәи хәлен шактый тулы күзалларга була. Газизә 1862 елда Әстерхан өлкәсе Ташлыяр (Ташлы Яр, Каменный Яр) авылында дөньяга килә. Аның әтисе Баһаветдин бине Шәмсетдин бине Сәйфелмөлек бине Сәмит бине Якуп бине Йосыф бине Сөләйман бине Кадерле бине Кәкле шул ук авылда сәүдә белән шөгыльләнә.

Сәмидовлар нәселе бу җиргә асылда Саратов ягыннан күчеп килгән булса кирәк. Газизәнең шигырьләрендәге тел үзенчәлекләре дә шуны күрсәтә.

Баһаветдин үз вакытының ачык фикерле кешеләреннән булган ахры. Ул кызы Газизәгә үз вакыты өчен шактый яхшы белем алырга мөмкинлек тудыра. Газизә гарәп телен яхшы өйрәнә. Бу аның гарәп табышмаклары һәм мәкальләрен тәрҗемә итүендә ачык чагыла. Мәсәлән, гарәпчә

«Тәгамүҗ-җәвади дәвагн
Вә тәгамүл — бөхли даун», —

дигән мәкальне Газизә:

Юмартның ашы — авыруга дару,
Саранның ашы — кешегә агу, —

дип зур осталык белән татар теленә тәрҗемә итә.

Газизә рус һәм калмык телләре белән дә шөгыльләнә. Дәфтәрләренең берсендә гарәпчә, татарча, русча һәм калмыкча гарәп хәрефләре белән язылган саннар, русча-татарча көн исемнәре, рус хәрефләре белән язылган аерым сүзләр шул хакта сөйли.

Ләкин Газизә башка телләрне өйрәнсә дә, үз ана теле булган төрки телгә (ул чакта татар әдәби теле шулай дип аталган), ягъни татар теленә аеруча мәхәббәт белән карый һәм бу хисен түбәндәге ярым шаярып язылган сүз уенында чагылдыра:

* Газизә Сәмидова — күп чыганакларда Сәмитова дип бирелә. Ред. искәрмәсе.

Укыдым фарсы,
фарсы бәңа торды каршы,
Укыдым гарәп, гарәп китте тарап,
Калым артыннан карап.
Укыдым төрки —
җанымның күрке.
Һәм төркем барга һәм күркем бар.

Әлхәмделиллаһи, төркем белән тәүфигым рәфикъ улсын. Амин. Яраббилгаләмин!

Әй мөселманнар!
Укыңыз гыйлемлек.
Җаныңа юлдаш (ул) гомерлек.
Барча күргән язуларны
уку шатлык.
Укый белмәү, сукыр кебек,
зур хурлык.
Китап күрми күңел азып бетәдер,
Надан булып гомер зая үтәдер.

Бу юллар кулъязмада чәчмә формасында язылган. Биредә шигырь формасында бирелде. Чөнки ул — шигырь. Аның рифмасы да бар, мәгънәсе дә. Газизә бу шигырендә башка телләрне

күпме өйрәнсәң дә, үз ана телеңне аларга алмаштырырга ярамый, ана теле ул — җан күрке, дигән фикерне үткәрә.

Газизә телләр белән генә түгел, тарих белән дә кызыксына. Ул татар халкының борынгы мәдәният үзәге булган Болгар шәһәренең хәрабәләрен барып күрә һәм Шәһре Болгар хәлләре дигән баш астында «Өлкән Болгар», ягъни Болгар дәүләтенең 1414 елда әле дәүләт буларак яшәгәне хакында яза. Бу дөрес мәгълүматны Газизәнең кайдан алганы билгеле түгел. Татар телендәге башка чыганакларда Болгарның юк ителүе Аксак Тимергә бәйләнгәнгә, Газизәнең бу мәгълүматы аеруча дикъкатькә лаек. Чөнки рус елъязмаларының әйтүенә караганда, князь Василий Темный җибәргән князь Федор Пестрый җитәкчелегендәге рус гаскәре 1431 елда гына Болгар шәһәрен бөтенләй юк итә.

Шәһре Болгар хәрабәләрен тасвирлаганда Газизә шундый кыска һәм саран, ачык һәм төгәл гыйбарәләр куллана ки, алар фәнни хезмәткәрләр өчен үрнәк була алырлык. Менә бер өзек:

«Шәһре Болгарда хан мәсҗеде булган икән... Югарылары беткән. Тирәсендә ишелгән ташлар бар. Ак таш булган. (Мәчетнең) буе илле аршин, иңе кырык аршин микъдары. Дүрт почмагында дүрт баганасы бар. озынлыклары уникешәр колач. Һәр бүрәнәсенең калынлыгы ике аршин кадәре.

Михрабның иңе өч сажин. Барчасы таштан булган. Мәсҗеднең эчендә язулы ташлар... Сул тарафында мәдрәсәсе бар. Таштан булган. Сәккез кырлы. Ишек тарафында зиндан булган. Түгәрәк икән. Мәдрәсәнең эчендә һәм язулы ташлар бар — кабер ташлары. Шәһре Болгарның көнчыгыш тарафында ике таг (тау) бар. Арасында Габдрахман коесы».

Газизә бу коеның гади генә булса да планын ясап күрсәтә. Моннан башка Шәһре Болгар янындагы «Рабига күле»н шулай ук оста тасвирлый. Бу күлнең схематик планын төшерә. Кайсы ягында урман, кайсы ягында тау икәнен күрсәтә дә, «бу күлнең тирәсендә төрле чәчәкләр (үсә). Ак күбәләкләр күп. Кеше баргач, очалар да, янә килеп (чәчәкләргә) куналар», дип шагыйранә җөмләләр белән күл тасвирын тәмамлый.

Гам дәгелдөр китә дөнья каладин,
Мөшкил ула кала дөнья китәдин.
(Исән кешедән дәүләт китү
кайгы түгел.
Дөньяны калдырып үлеп китү —
авыр хәл), —

дигән борынгы мәкальне китергәч, Газизә 1552 елда Казан-Болгар рус кулына керде, дип икенче дөрес датаны китерә.

Кулъязмалар белән танышканда бернәрсә күзгә ташлана: Газизәнең дуслары күп була. Алардан егермесенең исеме телгә алына. Якынлык дәрәҗәсенә карап, Газизә бу дусларын төрлечә атый: дустым, нәзек дустым, җан дустым, яшьтәш дустым, җан былбылым дустым, җан сөйгәнем дустым, ахирәт дустым һәм башкалар.

Борынгы гадәт буенча татар хатын-кызлары арасындагы дуслык дәрәҗәләрен белдерә торган бу атамалардан ахирәт дусты иң зур дуслыкны белдерә. Газизәнең исә ике ахирәт дусты була: Минһаҗетдин кызы Нилбикә белән мулла Камалетдин кызы Котлыҗамал.

Газизәнең моннан соңгы тәрҗемәи хәлен аның шигырьләреннән аерып карарга мөмкин түгел. Алар бер-беренә үрелеп бара.

ГАЗИЗӘНЕҢ ИҖАТ ЮЛЫ

Революциягә кадәр күпчелек татар кызларының башына килә торган фаҗига Газизәнең башына да килә. Аны яратмаган кешесенә ярәшәләр. Борынгыдан килә торган бу йолага каршылык күрсәтү мөмкин түгел. Бу хакта ата-анага яки башка кешеләргә сүз ачу кызлар өчен кичерелмәслек зур

гаеп, усал телләр өчен исә гайбәткә азык һәм намуска кара тап кына булачак. Менә шундый чакларда синең кайгыңны бер генә кеше — ахирәт дусты гына бүлешә ала.

1881 елда Газизә ахирәте Котлыҗамалга яшьлек дәверендә беренче мәртәбә башына төшкән ачы хәсрәтен уртаклашып, шигырь белән хат яза. Газизәнең моннан элек язган шигырьләре дә бар. Беренче шигырьләр дәфтәре 1876 елда башланган. Ләкин югарыда телгә алынган шигырь бәхәссез булганга шуннан башларга туры килә.

Газизәнең бу шигырендә иксез-чиксез кайгының үзәк өзгеч моңлы аһәңе яңгырый, дөньяның ачысын беренче мәртәбә татый торган яшь йөрәкнең күкләргә чыккан аһ-зары, явыз язмышның ыржайган тешләре алдында ихтыярын югалткан яшь кызның имәнеч тавыш белән ярдәм сорап кычкырганы ишетелә. Бу көчле хис хөр яшәү максаты белән янган кыз йөрәгеннән табигый рәвештә, көчле дулкын кебек, ташып чыга да, турыдан-туры укучының йөрәгенә тоташа. Үзенең табигыйлеге белән бу хис сине шулкадәр биләп ала ки, шигырьне укыганда андагы тел кытыршылыклары, күзгә ташлана торган мишәр урынчыклары да сизелми башлый. Шагыйрәнең исә бер үк вакытта үз әсәренең каһарманы да булуы шигырьне татар кызларының үтмештәге авыр язмышы хакында таныклык бирүче документка әйләндерә. Менә ул:

Биек кенә тауның әй башында
Сәүдәгәрләр кибет бурыйлар.
Кече яшьдин бер яр сәүгән идем,
Бүтән ярны бәңа юрыйлар.

Җиләнемне җәйдем әй җиләскә,
Кояш кызуына күмәскә.
Беләмсен, ахирәт, әй юкмы, сән
Келиләр сәүгәнгә бирмәскә.

дип башлый Газизә бу хат-шигырен. Авыр кайгы аны җырларга да, еларга да мәҗбүр итә:

Йырлар язган, диеп сез әйтмәгез,
Йыр юата бәнем үземне,
Йырлый гына торга елый куям,
Яшь юадыр бәнем йөземне.

(Шигырь кыскартып алына. Бу һәм моннан соңгы китереләчәк шигырьләрнең кыскартылган урыннары өч нокта белән бирелә).

Ләкин ачы күз яше билгесез киләчәкнең караңгы томанын тарата алмый, күңел нидер сизенә:

Эчкенәем тарта, кайгым арта,
Ниләр сизә икән бу башым?
Кичә-көндез ага күздән яшем,
Нидән тарта икән уң кашым?

Кайгы тулып, эчкенәм тарланып,
Йөзгенәем кыза нурланып.
Кайгым да артканга түзәлмичә,
Йыр чыгарып йырлыйм, хурланып.

Кара урманнарда кар тирән,
Атлатып булмыйдыр ат белән.
Ничек кенә көлеп сүләсәң дә,
Серләр килешмидер ят белән...

Килдем бу дөньяга йөрергә,
Ходай ни язгандыр күрергә.

Соңгы ике юлда бик аз, бик көчсез булса да, әле өмет чаткысы ялтырый. Бу өмет Газизәнең икенче шигырендә яратмаган кешесенә үлем теләүгә кадәр алып бара:

Матур кыз калфагың күтәр,
Ике каш араңнан җил үтәр.
Ян сәүмәгән ярның кадере китәр,
Ян сәүгән ярларга ни җитәр.

Сәүгәннәр сәүгәнгә булсайде,
Сәүмәгән яр дөнья куйсайде, —

ди ул, балаларча беркатлылык белән. Ләкин язмыштан узмыш юк. Аны сөймәгән кешесенә биреп, 1882 елның май аенда туй ясыйлар. Шул көннән башлап күңелнең иң ерак читендә җемелдәгән соңгы өмет чаткысы да сүнә. Тормышка (кияүгә) озатылгач, Газизә өчен өзлексез кара көннәр башлана.

Дәвамы бар ■

МӘҢГЕДӘШЛӘР

Сәйдә Зыялы

Сәйдә Зыялы

«Хөрмәтле Сәйдә апа!
«Шигырь!» дигән ләззәтле мизгелгә очраган һәр кеше — мәңгелектә яши. Без — синең белән мәңгедәшләр!
Нияз. 27.01.1986 ел».

«Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясендә чыккан «Учак» исемле шигырьләр җыентыгына Нияз миңа шушы сүзләрне язып бүләк иткән иде…

Әйе, без — мәңгедәш!
Нияз, тик кызганыч:
Мәңгелеккә күчтең иртәрәк;
Дөнья — кырыс,
давыллары — шашкын:
«Син — шагыйрь!» — дип,
тормый иркәләп…

Һай, бормалы безнең язмыш яры…
Яр ишелә бәргән дулкыннан;
Җимерелә ярлар, актарыла…
Дулкын бәргән ярда упкын бар!
Бәргәләнә җанда уй дулкыны!
Уй дулкыны тынмый — агышта!
Кара төндә чыгып кача йокы,
Җан уралып кала сагышка…

Сары сагыш урын ала җанда —
Шагыйрьләргә сагыш гел юмарт…
Сагыш булып күз алдында тора —
Нияз, Фәннур, Кадыйр, Эдуард…

Шигырь укып тора сыман Рәшит
(Күңел аны мәңге сагыныр!) —
Ирек мәйданында ирек даулап,
Ачлык игълан иткән шагыйрь ул!

Әйтә килде шагыйрь туры сүзен.
Уйлый белгәннәрне уйлатып;
Күңелләрне уйлар уеп ала —
Ә үзләрен инде югалттык…
Югалттык шул инде, югалттык…

Йокысызлыкка уралган караңгы төннәрдә арабыздан иртә, бик иртә киткән каләмдәшләр кабат-кабат искә төшә. Күренекле тәнкыйтьче, шагыйрь, ялкынлы публицист, «Идел» журналының баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәй юл һәлакәтенә юлыкты. Шагыйрьләребез Нияз Акмал, Фәннур Сафин, Рәшит Әхмәтҗан, Кадыйр Сибгатуллин, Эдуард Мостафин да көтмәгәндә бакыйлыкка күчте. Атаклы юмор остасы, әдип Фаил Шәфигуллинны да кыйнап үтерделәр. Халыкчан шагыйрь Харрас Әюп хатыны Лүзия белән иртән йөгерергә чыккан җиреннән вафат булды. Шагыйрь Наис Гамбәрнең йөрәге кинәт тукталды. Эдуард Мостафин эзсез югалды… Исемлекне дәвам итәргә була, әмма минем көчем җитми: күзгә яшь тула, мөлдерәмә күңел чайкала…

Бүген мин, аларның һәммәсенә дә догамны багышлап, хезмәттәшем, каләмдәшем, дустым Нияз Акмал турындагы кайбер истәлекләрне генә яңартам…

…Нияз белән без «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») гәзите редакциясендә бер бүлектә эшләдек. Бу — 1970 нче елларның ахыры иде. Ул елларда «Яшь ленинчы» шагыйрьләргә бай иде. Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Нияз Акмал — һәммәсе шушы редакция хезмәткәрләре. Акмал белән мин фәкыйрегез — мәктәпләр бүлеге журналистлары. Әдәбият бүлегендә утыручылардан көнләшеп алган чаклар да булгалый. Алар бүлеге әзерләгән мәкаләләр җыелышларда мактала. Шулай булмый хәл дә юк: аларның авторлары — һәммәсе язучылар. Шәүкәт абый Галиев, Илдар абый Юзеев, Аяз абый Гыйләҗев, Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләм — барысы да әдәбият бүлеге авторлары. Ә без, мәктәпләр бүлегендәгеләр, авторларны үзебез эзлибез, үзебез әзерлибез. Пионер сборлары уздырырга, «Арткы партадан репортаж»лар бирергә, «Эндәш» клубы утырышларында катнашырга

Нияз Акмал

әледән-әле командировкаларга чыгабыз. Каләм тибрәтүче укучыларны, укытучыларны барлыйбыз. Юк, юк, мәктәпләр бүлегендә эшләвебез шигърияткә, әдәбиятка булган гыйшкыбызга һич тә комачауламый, һәр көн, эшкә килүгә, бер-беребезгә кичтән язган шигырьләребезне укыйбыз. Нияз ул елларда күп язды, ялкынланып язды, «Сарман җыры» поэмасын иҗат итә башлады:

…Ә хәзер без башлыйк,
Һәм җырлардан башлыйк —
Җанга якын шушы җырлардан!
Халык белән бергә, чордан чорга,
Уза алган һәрбер җырга дан!..

Ниязның сөйләме матур, тавышы көчле. Ул һәр шигырен яттан белә. Хәтере — гаҗәеп яхшы!

…Бер елны без апрель аенда Биектау районының Ямаширмә мәктәбенә барырга җыендык. Мәктәпкә алдан ук хәбәр иттек. Безне көтәләр! Биектауның комсомол комитеты белән дә алдан ук сөйләшеп куйдык.

Тәгаенләгән көнне, иртәнге сәгать тугыз тулганчы ук, Биектауга килеп тә җиттек. Райкомолда безне уку йортларындагы, мәктәпләрдәге тәрбия эшчәнлегенә җаваплы секретарь — яшь кенә кыз каршы алды. Без елмаеп килеп керсәк тә, секретарь кызның йөзе шактый күңелсез иде.

— Биектаудагы берәр мәктәпкә генә барырбыз инде, — диде ул безгә, хәл-әхвәл сорашкач...

Без, кинәт әйтелгән бу тәкъдимгә аптырап, Нияз белән бер-беребезгә карашып алдык.

— Бу мөмкин түгел! — дидем мин. — Безне балалар көтә, укытучылар көтә. Алар махсус пионер сборы әзерләде. Ә без аны гәзит битләрендә яктыртырга тиеш!

— Машина — ватык... Ничек барасың? — диде секретарь, үзсүзләнеп.

Райкомоллардагы машиналарның төзексезлегенә, җитәкчеләрнең балалар матбугатына исләре китмәвенә без күнеккән инде — кем әйтмешли, каешланган!..

— Ярар, — дип сүзгә кушылды Нияз. — Ямаширмә җир читендә түгел! Дәресләр беткәндә, үз көебез белән дә барып җитәрбез...

Секретарь сөйләшүнең мондый борылыш алуын көтмәгән иде ахры — күзе акайды.

— Ничек? — дип сораганын сизми дә калды.

— Поездга утырабыз да Коркачыкка хәтле барабыз! Аннары — тәпи-тәпи инде, — дидем мин...

Иманым камил, бу мизгелдә секретарь кыз өчен миннән дә явыз, миннән дә киребеткән башка бүтән юк иде!..

Чираттагы электр поездын көтеп, Коркачык станцасына барып җиткәнче, кояш төшлеккә күтәрелде. Көн җылынды. Юлга кар сулары чыкты, җепшетте. Ә безгә хәзер биш чакрым тирәсе тәпилисе. Без — журналистлар — уңайсызлыкка күнеккән халык. Җәяүләп тә, ат чанасына утырып та йөрибез. Зур тәгәрмәчләре белән як-якка пычрак бураны туздырып баручы «Беларусь» тракторы да — безнең өчен уңай транспорт. «Яшь ленинчы»лар шул рәвешчә командировкага йөрде, республиканы аркылыга-буйлыга иңләде...

Ә менә секретарь кызыбызга сулы, җепшек карлы юлдан бару һич ошамый. Ул эндәшми, сөйләшер сүз тапмый, ирене турсайган. Нияз, аның бер алдына, биш артына төшә-төшә, «Сарман җыры» поэмасын укый:

...Сарман буйлары ла яшел алан,
Сарман буйлары ла тал-тирәк...
Тирәккә дә,
Кешегә дә, дөнья,
Көн итәргә җылы көн кирәк!..

Поэманың эчтәлеген, аһәңен, шагыйрьнең үткен фикерен безнең кызыбыз аңлыйдырмы, юкмы — анысын белгән юк. Ә мин, Ниязны рәхәтләнеп тыңлый-тыңлый, Ямаширмәгә килеп җитүебезне тоймадым да!

Мәктәптә бик матур итеп пионер сборы узды, соңыннан без сөйләдек. Гәзиткә мәкалә бирергә мисаллар җитәрлек. Күңел күтәренке. Шул мәлне мәктәп директоры миңа мөрәҗәгать итте:

— Сәйдә ханым, бүген китмәсәгез иде. Иртәгә әдәбият түгәрәгенә йөрүчеләрнең иҗат «җимешләрен» укуны оештырыр идек!..

— Ярар. Укучылар иҗатын гәзиткә дә чыгарырбыз!

Ул арада безне ашханәгә дәштеләр. Мин директор белән сөйләшкәндә читтәрәк укытучылар арасында торган Ниязым кинәт юкка чыкты. Йөрәгем «жуу!» итеп китте. «Кая булыр бу? Әллә, Ходаем, берәр укытучы өенә алып керергә булдымы икән үзен?» Шулай, башымдагы мең төрле сорауга җавап табалмый борчылып утырганда Нияз балкып килеп керде.

— Карета подана! — диде ул, авызын ерып.

Баксаң, колхоз рәисе янына барып, Биектауга кайту өчен машина белешеп йөргән икән. Мин секретарь кызга күз салдым. Аның йөзенә сизелер-сизелмәс кенә алсулык йөгерде…

Гаҗәеп кешелекле кеше иде Нияз. Зур талант иясе иде! Беркайчан да кешедән көнләшмәде, башкалар иҗаты турында начар сүз әйтмәде. Әгәр берәр язучының яңа әсәре турында тиешсез тәнкыйть кузгатучы булса, аның җене чыгар иде.

— Син үзең иң элек бу әсәрдән яхшырак итеп яз! Аннары — сөйләрсең! — дип, тәнкыйтьченең авызын томалар иде.

Язлар кебек якты, җәйләр кебек җылы күңелле иде ул…

«Мәңгедәшләр!» —
диеп пышылдыйм да,
Дәвам итәм шигыреңне, Нияз:
«…Табигатькә генә кайта яз», —
дип
Җавап бирде миңа кайтаваз…»

Олуг Табигатьнең кайтавазларын ишетә белүче, күңелендә кабат-кабат язлар яңартучы талантлы шагыйрь, прозаик иде шул Нияз дустыбыз…

Мәңгедәшләр шул без,
мәңгедәшләр…
Шагыйрьләрнең күңеле бик сизгер;
«Шигърият» дигән мәңгелектә
Гомерең дә синең бер мизгел.

Мәңгелек һәм мизгел…
Уй дулкыны
Бөтереп ала, чорный акылны;
…Зәңгәр күктә якты нурын сызып,
Әйтерсең лә йолдыз атылды.

2012 ел, сентябрь.

«АК ЧӘЧӘКЛӘР» ӘСӘРЕ: АЛТМЫШ ЕЛ ЭЛЕК

Бер бәйләм беркетмә

8 октябрь, 1965 ел.
Проза секциясе утырышы.

Катнашалар: язучылар, редакция хезмәткәрләре, студентлар.
Көн тәртибендә: Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын тикшерү.
Утырышны проза секциясе җитәкчесе **Атилла Расих** ачып җибәрә:

— Бу тикшерү авторга да, башка иптәшләргә дә файдалы булыр, дип уйлыйм. Шул исәптән безнең әдәби осталыкка карашыбызны сынау да булыр. Әсәр күптән басылды, әмма җитди тәнкыйть мәкаләсе күренмәде. Бәлки бу фикер алышу тәнкыйтьчеләргә бер этәргеч ясар.

Сүзне тәнкыйтьче **Рафаэль МОСТАФИН** ала:

— Романны халык яратып укыды. Хатлар күп килә. Журнал күбрәк тарала башлады. Мин быел күп җирләрдә булдым, роман турында күп фикер ишеттем. Быел иң популяр әсәр булды бу роман. Әсәр басылып беткәнче үк хатлар килә башлады. Журналның киләсе саннарын көтеп алдылар. *(Берничә хат укый.)*

Урыннан сорау: Тәнкыйть сүзләре булдымы?

Рафаэль Мостафин сүзен дәвам иттерә:

— Бер врачтан медик терминнарга карата замечание булды.

Беренче кат укыганда әсәр мине мавыктырмады. Сайрак, тирән түгел, яңа фикерләр алып булмаган кебек булды. Әбүзәр абый — бик матур образ. Язучының көндәлеге бик кызыклы. Икенче кат укыганда мин күбрәк әсәрнең йомшак якларын күрдем.

Габдрахман абыйның барлык геройлары өч төрлегә бүленә: яхшылар, яманнар һәм кимчелекле геройлар. Башка язучыларда бу алай түгел. Бу нәрсә, минемчә, авторның фактларны үз калыбына салуын күрсәтә. Егерме

Атилла Расих

Фатих Хөсни

Әмирхан Еники

Г.Әпсәләмовның китап укучылар белән аралашкан вакыты. Алма-Ата. 1962 ел

икенче съезд күренешеләре бар. Автор бу турыда бик төчеләнеп яза. Артык парадный үтте бит ул съезд. Ә автор моны күрми. Бу геройның тирән фикерлелеген күрсәтми. Тагын: зур әдәбият әсәре һәрвакыт яңа горизонтлар ача. Беллетристикада андый ачышлар булмавы да мөмкин (Белинский сүзләре бу). Бу беллетристиканы кимсетү түгел, үз чорында андый әсәрләр роль уйныйлар. «Ак чәчәкләр»дә беллетристик алымнар шакктый ачык. Габрахман абый — сюжет остасы. Ләкин бу сюжет, геройның характерын ачу роленнән бигрәк, детектив роль уйный (мисаллар: Мансурның кайтуы, Мансурның хәлен этиләре белми, Диләфрүз белән Юматша, һ.б.). Миндә шундый тәэсир калды: язучы күп материал җыйган, һәм аны дыңгычлап, төеп булса да тутырган. Мәсәлән, көндәлек. Аны алып ташлаудан романга зыян итмәс иде. Бу әсәргә балласт кебек. Андый урыннар романда шактый, аларны алып ташласаң, минемчә, матур гына повесть калыр иде.

Кайвакытта артык сентиментальностька бирелеп китү җанны әрсетә? Мәсәлән, Мансурның Диләфрүзгә өйләнергә карар кылуының мотивлары.

Бәлки, мин кимчелек дигән нәрсәләрне башкалар үзенчәлек диярләр. Мелодраматик моментлар да күпләрнең күңеленә хуш килә.

Язучының үз укучысы бар. Әмма бу әсәр мине канәгатьләндермәде, сайрак әйбер. Төп фикер: яхшы кешелекле врач яхшы дәвалый, начар врач начар дәвалый. Тормыш катлаулы бит, ә ул катлаулыкларның чагылышын мин бу әсәрдә күрмәдем.

Сүзне **Фатих ХӨСНИ** дәвам итә:

— Мин романны иренеп укый башладым — арылган, әсәрнең ничек язылганын беләбез. Укый-укый мавыктым һәм укып чыктым. Икенчедән, без авылларда булдык һәм беләбез: Габдрахманны укыйлар, кызыксыналар.

Әйберне яхшы, дип әйтү өчен ике билге кирәк: 1) халык яхшы дип ябырылып укысын, 2) язучылар, тәнкыйтьчеләр яхшы, дип тапсын.

1918 елда Петроградта референдум уздыралар һәм ачыклана: халык Игорь Северянинны күп укый икән. Хәзер бу шагыйрьне сирәк кеше белә.

Габдрахман әдәбиятта кеше кулаягы тимәгән темаларны кузгата. Бу юлы ул врачлар тормышын яхшы ук каерып ташлады.

Өченче як: кызыклы гына, күңелне ышандыра торган кешеләр бар. Миңа кечкенә кешеләре ошый: Фатихәттәй — җылы, табигый; Диләфрүз — кеше ул! Асия, Хәтирә апа, авылдагы апалар. Төп образлар пьедесталга бастырылган.

Әбүзәр абзыйның квартира обстановкасы, үзара мөнәсәбәтләрнең яхшылыгы, пакьлек, сафлык — бу бик яхшы.

Әма моңа карамастан, миндә китап — китап тәэсире калдырды. Тормыш тәэсире түгел. Әдәбиятлык, ясалмалык исе килә, тиешенчә тормыш түгел. Тормышка карата дөреслек, сафлык, хыянәтсезлек, саклык кирәк. Нилектән бу ясалмалылык:

1. Уңай образлар чиксез, чамасыз яхшы. Алар — пьедесталда. Автор аларга тенденциоз мөнәсәбәттә.

2. Кирәкмәс урында, гади генә әйтәсе урында пафос белән, «красивый» итеп әйтергә тырышу. Ә Пушкин әйтә: «Прозаның бөтен прелесте — гадилектә», — ди. Романда гадилек җитенкерәми, кирәк-кирәкмәсә купшылык артыннан куу бар.

3. Кайбер бик четерекле күренгән ситуацияләр ансат кына чишелә дә куя. Мәсәлән, Гөлшаһидә — Мансур линиясе. Ансат аерылалар — ансат кушылалар. Без яшьләрне өйрәтәбез бит, мондый мәсьәләләрне бөтен җитдилеге, катлаулылыгы белән куярга кирәк.

Гөлшаһидә — авылда нишләгәндер — җыр да чыгарганнар, съездга делегат итеп сайлыйлар, шәһәрдә тагын парторг та тегене эшли, моны эшли, әйтерсең, аннан башка берәү дә боларны күрмәгән. Ә төп эшендә, ничек эшли ул — бусы күренми. Мансур шулкадәр баллы-шикәрле: бармаклары скрипач-пианистныкы кебек, эшне челтәр бәйләүче кебек пөхтә эшли, күзе аучыныкы кебек. Везет бу Мансурга! Бу Габдрахманның күп әсәрендә шулай. Бу безнең уртак чиребез. Уйланырга кирәк. Тормышны онытып, ясалма чәчәкләр ясап утырабыз. Тормыш чынлыгы, менә нәрсә кирәк әдәбиятка.

Әсәрдә картинность, ясалмалылык күп (укып күрсәтә). Төчелек. Тормышта алай булмый ул!

Гөлшаһидә — Мансур. Инде кушылганнар икән, аларда психологическая логика булырга тиеш, дәлилләргә кирәк. Монда дәлилләү җитми.

Тел турында. Авыррак яза Габдрахман. Шулай да алга китеш шактый. Эзләнә, өйрәнергә тырыша. Бу китапта да уңышлар бар. Әмма тешкә тиярлек әйберләр шактый: калькалар, урыс сүзләре, уңышсыз фигыльләр (мисаллар: кояш тауларны алсу нурга манчыган — манган кирәк ләбаса! — Тыгыз җил....Гөлдери моны төнәми — өнәми кирәк. Чын йөрәктән сөйләшү — чын күңелдән кирәк! — ...сарымсак исе бөркеп тора — Аңкып тора кирәк! Ике ятып бер уйламыйсың — төшемә дә керми кирәк — мәкаль бу лабаса! Кухняның эче дә, тышы да пычрак... — кухняның тышы кайда? Савыт-сабалары маемсыр — ни дигән сүз бу? Поклонницалар...порядочный кешеләр... Үлем-бетем — үлем-җитем бит ул! Кәкрәйгән, таушалган баскыч — кыйшайган, кыршылган кирәк. Роман китап булып чыгып килә, ди. Телне бик нык карарга кирәк бит. Инде китапта да телне бозмыйк.

Мәсгут ШӘРИФУЛЛИН сүз ала:

— Романда зур тема күтәрелгән. Автор материалны нык өйрәнгән.

Әсәр мине мавыктырып китә алмады. Сюжетның ныклыгы юк. Иң төп герой Әбүзәр абый — көрәше юк, противниклары юк. Булса да противниклары — вак кешеләр. Ул зур кеше, дөньяга билгеле, укымышлы, аның противниклары да зур булырга тиеш иде. Ман-

Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр» романы турында сөйли. Казан, М.Горький ис. ял паркы. 1965, 16 июль

сур белән Гөлшаһидәнең мәхәббәтен күрмәдем мин. Аерылышуның сәбәбе, зур сәбәбе булырга тиеш иде бит. Янып-көеп йөрүләре дә ясалма кебек. Сюжет төеннәре бик ансат чишелә. Кульминация һәм развязканы мин күрмәдем. Автор тар сукмактан барырга тырышкан кебек, киң тормышка чыгу юк. Роман дневниксыманрак тоелды миңа. Геройларның яхшымы, яманмы икәнлеге башта ук билгеле. Мин врач халкы белән таныш. Алар шактый культуралы кешеләр. Романда алар тупаслар, дорфалар. Тонкирак булырга тиеш бит ул. Янгураның профессор булуына ышанмыйм: бик тупас кеше. Администрациядә эшләүчеләр ахмаклар. Геройлар юктан да елый. Авторның да, укучыларның да моңа һич исе китми. Геройлар бик тиз сүзгә килә.

Гөлшаһидә-Гайсә мөнәсәбәте ачыкланмаган. Автор ихтыяры белән йөргән кебек.

Кече кешеләр бик ошады миңа: Фатихәттәй, артист, Бибисара.

Р.Мостафин «Ак чәчәкләр» романы хакында сөйли. Ласточкин ис. мәдәният йорты. 1970 ел

Тел ягы әйбәтләнә, шулай да турыдан-туры русчадан тәрҗемә ителгән сүзләр күп.

Г.Ахунов «Ак чәчәкләр» романына кагылышлы сорауларга җавап бирә. 1970 ел

Сүз чираты **Ибраһим ГАЗИ**га җитә:

— Миңа ошаган җире романның — көндәлекләр. Кызык итеп, тормышның үзеннән алып язылган. Әдәби әсәр эченә кергән публицистика манералары бик ошады. Әбүзәр абый да ошады.

Роман турында шактый уйландым. Аның беренче романнарында романтизм моментлары бик көчле иде. Романтизмның хосусияте шул — образларны тулы итеп эшләмәү. Соңгы романы романтизмнан арынып җитмәгән. Бу романтизм аны, урысча әйткәндә, и спасал, и топил.

Әбүзәр агайның образын ала. Материалны бер дә карамыйча *(бәлки сайлап тормыйча, дип әйтергә теләведер. — **Л.Л.**)* төеп-төеп тутырган. Бу шактый зыян китерә. Кайчан ышанып җитеп тә булмый: Мәскәүдән килгән хатынны, Асияне терелтү. Асия активисткага әверелә. Әбүзәр ага үлгәнне дә, үлеп барганны да терелтә. Чама юк, мин инде елмая башлыйм, бөтен романга күләгә төшә. Бу, минемчә, шартлыромантик методның реалистик әсәргә килеп керүеннән килә.

Чама юк, бөтен буяулар өелгән. Арттырулардан бер дә тартынмый автор, сахарин сала, артык кызылга буйый.

Мансур белән Гөлшаһидә арасында мәхәббәт юк бит, егетләр. Җылылык юк. Ни өчен алар аерылалар? Сюжетны шулай корырга кирәк бит, автор аларны мөмкин кадәр озаграк, роман азагына кадәр кавыштырмаска тырыша.

Балалар уены кебек килеп чыккан. Сознательно ясаган ул бу сюжетны. Мондый романда бик сак булырга кирәк бит.

Мин тискәре геройларның артык кара, ямьсез булуына да ышанмыйм. Бу да романтизм тәэсире.

Роман бөтенләй шушы настроениегә корылган.

Романтизм методы белән язылган әйберләр кирәк түгел димим, кирәк, билгеле.

Сүз җайлап кына **Флүн МУСИНга** күчә:

— Укучы буларак, фикеремне әйтәм. Темасы буенча яңа. Мине әдәби әсәрнең проблемалы булу ягы кызыксындыра. Ләкин бу әсәрдә мин укучыны кызыксындырырлык, яңа, актуаль проблема күрмәдем. Бу өлкәдә яңа проблема ачылмаган. Атилла Расихның «Ике буйдагы»нда андый проблема бар. Шуңа мөнәсәбәттә, шуның тирәсендә көрәштә геройларның характеры ачыла. Ә бу романда андый проблема юк. Врачларның көндәлек тормышы гына алынган. Әбүзәр абый — дөньяга танылган, укымышлы, ә нинди эше белән танылган ул — анысын аңламадым. Профессиональ үзенчәлекләр геройларның характерында сизелми. Бу яктан да әсәр аксый. Гомумән, кешеләр. Гөлшаһидәне кая да җибәрергә була — барыбер Гөлшаһидә булачак.

Гомәр ага **БӘШИРОВ** сүз дилбегәсен үз кулына ала:

— Миңа бу җыелыш ошый. Ел башында *(уку елы башлануын, көзге сезон ачылуын искәртеп әйтә, күрәсең. — **Л.Л.**)* секция эше болай башлану яхшы. Габдрахманның романын секциягә куюы да бик ошый.

Хатлар бик яхшы фикердә инде. Зур әдәбият таләбеннән чыгып сөйлибез без. Габдрахман безне дөрес аңлар, шәт. Мин романны яратып укыдым.

Шундый зур әсәрне укыганда, әдәбиятка нинди яңа образлар килә, дип уйлыйм мин. Миңа кечкенә кешеләр ошады: мәсәлән, Диләфрүз — сафлыгы, матурлыгы, самимилеге бик яхшы тәэсир калдырды. Николай Максимыч — әйбәт фикер калдырды. Әбүзәр ага — борынгы татар интелегенциясенә хас булган яклары белән ошый.

Гөлшаһидә китапта бик күп урын алган. Кем ул? Яхшы образларның үзенә хас сыйфатлары була. Кем ул Гөлшаһидә? Матур хатын, врач. Гомумән, матур хатын-кыз. Үзенә генә хас үзенчәлекләре күренми.

Әбүзәр абый китапның соңында үлә. Бу миңа ошамады. Аның прототибы — Әбүбәкер Терегулов дигән кеше. Моны укыгач, Әбүбәкер абый ни уйлар? Минемчә, андый нәрсәгә барырга кирәкми иде.

Романның яртысына кадәр ярыйсы гына бара. Аннан соң тарту-сузу башлана, бик көчле ясалмалылык килеп чыга.

Янгураны алыйк. Ниләр генә эшләми бу кеше! Баштан ук ачык: ул әшәке кеше. Әмма ул тагын әллә ничаклы әшәкелекләр эшли. Ник кирәк бу? Романны алып бару өчен кирәк. Юматшаны алыйк. Ул килеп керә, киеренкелек тутырырга кирәк — автор аны машина астына ташлап, үзен сытып бетерә. Бу егетнең характерын ачу өчен кирәкми. Мондый нәрсә кирәк түгел иде.

Реалистик романның үз традицияләре бар бит. Тормышның, үзенең бик катлаулы яклары бар — шуларга таянырга кирәк иде. Арзанлы эффектка корылган нәрсәләр күп романда.

Теге элекке романнарыннан яхшырак. Картлар телен матур гына биргән. Шушы юлдан барып, турыдан-туры русча калькадан котылырга кирәк.

Тәнкыйтьче **Хәсән ХӘЙРИ**нең сүзләре ни хакта булыр икән? Аны тыңлап карыйк:

— Күпчелк очракларда мин иптәшләрнең фикеренә кушылам. Әмма кайберәүләр белән килешеп булмый. Әпсәләмов биш роман язды һәм үсеп килә. Беллетристика, чтиво, дип әйтү дөрес булмас иде. Һәр язучының үз стиле бар, алар бер-берсенә охшамыйлар. Әмма күп кенә язучылар Әпсәләмов стиле белән килешә алмыйлар. Сугыштан соң яңа бер үзенчәлекле стиль белән язылган яңа төр әсәрләр бирә

башлады Әпсәләмов. Күрәсең, моны кабул итәргә кирәктер. Укучылар күптән инде кабул итте аны. Публицистик әсәр яшәргә хаклы, минемчә. Романтизм алымнарын автор киң куллана. Китапчылыкны ташлап, ясалмалыкны ташлап, бу стиль дә Әпсәләмов алган юнәлештә үсәргә тиеш.

Бу роман, укыгач ук, миңа ошамады. Романда автор үсмәгән, бераз чигенгән әле. Иң биек нокта — «Сүнмәс утлар» һәм хәзергә шулай булып кала да.

Төп бәла — идеальный герой эзләү, аны пьедесталга утыртырга тырышу. Бу ясалмалыкка китерә. Гөлшаһидә үзенең рухи үсешендә хәрәкәттә бирелми бит. Автор аның юлына чәчәкләр сибеп, бөтен киртәләрне алып ташлый, шунлыктан характер ачылмый кала. Идеаль геройны ясау — бу романда аеруча каты сизелә.

Әбүзәр абый — пассив кеше, аның роле юк.

Романның эчке пружинасы бик йомшак. Образлар бик шәп, әмма аларның табигый хәрәкәтен бирә алмаган автор, аларны җитәкләп йөрткән.

Монда проблема бар: гуманизм, кешелеклелек проблемасы бар. Фән нигезендә килсәң, хирургия һәм терапия проблемасы.

Роман, минемчә, укылыр. Автор роман өстендә тагын эшләр әле. Бәлки, ашыгучанлык аркасында килеп чыккандыр бу җитешмәүчелекләр.

Янгура һәм Тютеев — иң яхшы образлар. Ни кызганыч, сатира методы кулланылмаган.

Әбүзәр абыйның үлеме, анонимкалар — бар да ясалма.

Әбүзәр-Янгура, Янгура-Мансур мөнәсәбәте нәрсәгә корылган? Янгура — культ калдыгы икән. Әмма анонимкалардан башка нәрсә моны нигезләми. Начарлыкны культ белән аңлату — бу схемага әйләнеп бара. Моннан сак булырга кирәк.

Ниһаять, **Әмирхан ЕНИКИнең** салмак тавышы ишетелә:

— Мин романны укып бетрә алмадым, ни белән беткәнен белмим. Журналлар кулдан-кулга йөрде дә йөрде.

Минем башымда бернәрсә урнашып җитмәде әле. Бу роман бик күп нәрсәләрне бутап ташлады. Нинди критерий белән килергә? Хатлар күп килә, халык укый — бу бик күңелле.

Әмма мин шактый аптырауда. Мин башта бик мавыгып укыдым. Аннары акрын-акрын кызыксыну сүрелә башлады.

Нинди аршын белән килергә бу әсәргә? — дип аптырап калдым. Әсәргә кирәген, иң зарурын гына язарга кирәк, минемчә. Күңелгә тулган вакыйгалар, эпизодлар, картиналар йөзләрчә булырга мөмкин. Әмма шуларның иң кирәген яза белү кадәресе. Романда умыртка сөягенең, кирәген ала, кирәкмәгәнен рәхимсез рәвештә читкә кага торган үзәк сызыкның — үзәк сызык кешеләр язмышыннан тора, кешеләр бастырылып куелган бит инде — булмавыннан киләме әллә бу? — дидем.

Яхшы язылган кисәкләр бар романда. Минем өчен яңалык: авыл күренешләренең матур язылган булуы. Яңа квартирага күчүе, Асия белән очрашу — күпертмичә, арттырмыйча, реалистларча язылган кисәкләр бар. Әмма алар роман өчен ни дәрәҗәдә кирәк соң? Мин аптырап калам.

Әпсәләмов иҗатында новаторлык ике нәрсәгә кайтып кала, күрәсең:

1. Заман өчен яңа теманы тотып ала белү.

2. Яхшы кешеләр иҗат итү.

Ләкин бу бит, гомумән, әдәбият алдына куелган бурычлардан килеп чыга. Әмма бу дөрес тезисларны механическиерак аңлау юк микән Әпсәләмовта, минемчә.

Яхшы кеше образын ничек тудырасың? Яхшы кеше уйлап табасың да, аны вакыйгадан-вакыйгага, ситуа-

циядән-ситуациягә җитәкләп йөртәсең — мондый метод бар.

Менә мин тормышның катлаулы бер әхвален алам. Шул вакыйгада кешеләр үзләре ачыла. Менә тормышның бар бер өлгергән проблемасы, бу проблема тирәсендә вакыйга, шул вакыйгада кешеләр ачыла. Минемчә, менә шулай.

Менә иптәш Әпсәләмов беренче метод белән бармыймы икән, дим мин.

Әбүбәкер абзыйны гына алыйк. Мин аны беләм. Ул бик интересный кеше, чын мәгънәсендә интеллигент, сәнгать белән кызыксына. Без аның өендә бер ун көн тордык. 30 нчы ел, өендә прием алып бара иде. Аның янына артистлар, художниклар килә иде. Менә романны укыганда ул үзен бик кыен хис итәр сыман.

Ул болай кызыл түгел. Дөрес, бик яхшы кеше ул, әмма прописной истиналар сөйләп йөрмәс иде.

Дөрес, роман укылыр. Әмма әдәбиятның спецификасы турында онытмаска кирәк иде.

Язучы **Сафа САБИРОВ** ның сүзе кыска:

1. Әсәрләрне басканчы тикшерергә кирәк.

2. Нәшриятка секция рекомендация бирсен иде.

Сүз авторга — **Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ**ка бирелә:

— Минем өчен бу җыелыш яңалык түгел. Разгром ясаячакларын белдем һәм курыкмадым. Кайбер иптәшлр сөйләгәндә мин оялып утырдым — аларның әдәбиятны примитивный аңлавы өчен оялдым. Дөрес, кешеләр сөйләргә хаклы, сөйләсеннәр, әмма аларга карап берни дә үзгәрмәс.

Һәр әсәр аерым бер идея үткәрергә тиеш, әдәбият партияле булырга тиеш. Һәр кеше үз ноктасыннан торып сөйли, үз манерасын гына яхшы, дип саный. Әдәбиятка субъектив караш бу. Р.Мостафин үз фикерен күптән әйтте һәм шуннан баш тарта алмый.

Романның кимчелекләре бар, билгеле, аларның күпчелеге китапта төзәтелде дә. Мин тормышны үземчә аңлыйм, үземчә якын киләм.

Бу җыелышны күптән әзерләдегез һәм кыйнадыгыз, ләкин мин аяктан егылмадым. Фатих Хөсни нәкъ балага сөйләгән кебек сөйли. Нигә кирәк ул?

Мине тирәнтен уйлатырга мәҗбүр итәрлек сүз булмады монда. Мин тагын шул юл белән барачакмын. Минем укучыларым бар, алар фикере минем өчен беренче чиратта әһәмиятле.

Секция җитәкчесе **Атилла Расих** йомгаклау сүзе ала:

— Габдрахман Әпсәләмовның чыгышы мине гаҗәпләндерде. Төп теләк: авторга ярдәм итү. Чыгышлар бик әзерлекле, әйбәт, эчтәлекле, теоретик яктан нигезләнгән булды. Әдәбиятның принциплары бар, без аппостоллар түгел. Прозабызның сыйфатын күтәрү — зур бурыч. Шунлыктан, бу теләктән чыгып, без дөресен әйтергә тиеш. Иптәшләр дөрес әйтте.

1. Автор үзе язган өлкәне яхшылап өйрәнмәгән. Әбүзәр ага ни өчен профессор ул? Ул образ һавада асылынып тора һәм прописной истиналар сөйләп йөри.

2. Детективлык бар, куян куыш уйнап йөрү бар.

3. Сусальность бар, шикәрдән, балдан катырып ясалган образлар бар, син аны инкарь итә алмыйсың. Аккошлар төшерелгән базар паласлары кебек урыннары бар.

4. Тел кимчелекләре бар.

Тәнкыйтьтән өстен булу мөмкин түгел. Мин уйлыйм, Габдрахман аңлар, уйланыр, дип.

Фикеребезне матбугатта да кычкырып әйтергә кирәк. Без укучыларны, яшьләрне тәрбияләргә тиешбез.

Председатель: Атилла Расих.
Секретарь: Мәдинә Маликова.

Беркетмәне ***Ләбиб Лерон*** *укыды.* ■

МӨНИР АБЫЙ НИГЪМӘТ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК

Фатих Кутлу

Түбәндәге язмам көндәлегемә 2012 елның 8 мартында теркәлгән икән Алабуга Дәүләт педагогия институтындагы укытучым Мөнир абый Нигъмәтнең якты истәлегенә багышланган ул язманы дөньяга чыгарырга теләп, күптән хыялланып йөри идем. Ниһаять, аны, бераз тулыландырып, «Безнең мирас» укучыларына тәкъдим итәргә булдым.

Сигезенче март якынлашып килә иде. Кызымның мәктәбеннән хатын-кызлар бәйрәменә берничә номер әзерләвемне үтенеп сорадылар. Мәктәпкә барып, ир-ат укытучылар белән бергә сценарий язарга керештем. Кызыклы номер уйлап баш ватканда, Алабуга институтында укыткан хөрмәтле мөгаллимем Мөнир абый Нигъмәтнең хатын-кызларга багышланган, 224 сүздән генә торган бер җөмләле котлау хаты келт итеп исемә төште. Үзенә шылтыратып шул хатның электрон вариантын сорарга булдым. 3 мартта (якшәмбе көн иде) Мөнир абыйның кесә телефонына шылтыраттым. Телефонымда ят тавыш ишетелде. Номеры алышынган икән. Шуннан соң мин безне педагогикадан укыткан мөхтәрәм мөгаллимебез Сәлахи абый Таҗиевка шылтыратып алырга булдым. Аңарда Мөнир абыйның өй телефоны гына бар икән, өйгә кайткач шылтыратып әйтермен, диде. Рәхмәт яусын аңа, күп тә үтмәде, шылтыратып, Мөнир абыйның өй телефонын әйтте.

Шул ук көнне кич белән Мөнир абыйларга шылтыраттым. Телефон трубкасын алган кеше Мөнир абыйның улы Сәйдәш булды шикелле. Ул әтисенең кодаларына кунакка киткәнен, кич белән сигезләрдә генә кайтасын әйтте. Мин кабат шылтыратканда сәгать унынчы киткән иде инде. Мөнир абыйны телефонга чакырдылар. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, теге котлауның электрон варианты бармы, дип сорадым. Бар икән, шөкер... «Иртәгә интернет аша җибәрермен», — диде. Мин, укытучымны сөендерергә теләп, сүземне болай дәвам иттем:

— Бәлкем, әле ишетмәгәнсездер: Аяз Гыйләҗевнең төрекчәгә мин тәрҗемә иткән «Өч аршын җир» повесте быел Төркиядә үткәрелгән «Төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы әсәр тәрҗемәсе» номинациясендә җиңүче булды. Безгә татар телен, әдәбиятын сез өйрәттегез, яраттырдыгыз, без сезне онытмыйбыз», — дидем.

Ул шундый шатланды һәм болай диде:

— Фатих, син күпме төрек студенты арасында татар теле һәм әдәбияты белән җенләнүче, шушы юнәлештә эшләүче бердәнбер кеше булдың. Шуңа бик шатланам, горурланам. Син — безнең табышыбыз! — дип әйткәч, минем күңелем йомшарып китте, күзләремә яшьләр тыгылды.

Шул ук көнне, кичке сәгать уннар-

Университетны тәмамлаганга биш ел уңаеннан мөгаллимнәребез белән төшкән фото. 2004 ел

дан соң, котлау хаты электрон почтама килеп иреште.

7 март көнне сәгать дүрт тирәсендә бәйрәм тантанасы билгеләнгән ресторанга бардым. Кичә барышында 224 сүздән торган бер җөмләле әлеге котлауны укып, хатын-кыз укытучыларны шаккаттырдык. Җырлар да җырладык, мәзәкләр сөйләдек, кыскасы, бәйрәм бик күңелле узды. Кичке сәгать җиделәрдә өйгә кайтып кердем. Тугыз тулырга алты минутта исә кесә телефоным шылтырады. Сәлахи абыйның хәбәре аяктан екты: «Фатих, Мөнир абыегыз бүген кичке сәгать җиделәр тирәсендә, инсульт кичереп, вафат булган. Әйтмәсәм, үпкәләрсең, дип шылтыратырга булдым», — диде. Телсез калып, бик озак басып тордым. Шулчак, исем китеп, уйлап куйдым: Камал театры директоры Шамил абый Закировка соңгы тапкыр 22 февраль көнне шылтыратып сөйләшкән идем. Дүрт көннән соң, ягъни 26 февраль көнне, аның вафат булуы турында хәбәр алдым. Менә Мөнир абый белән дә соңгы тапкыр 3 март көнне сөйләшкән идек, шулай ук дүрт көннән соң, аның вафат булуы хакында хәбәр килеп иреште. Әстәгъфирулла!

Шушы котлау хатын сәбәпче итеп, Мөнир абый белән мине Аллаһы Тәгалә соңгы тапкыр сөйләштерткән, тавышын ишеттерткән икән. (Моны миңа насыйп иткән Раббыма шөкер итәм!)

Мин җәһәт кенә курсташым Хөсәенгә шылтыратып, кайгылы хәбәрне җиткердем һәм, әйдә, иртәгә җеназа намазына барыйк, дидем. Җеназа намазы иртәгә сәгать унбердә Алабугада укылачак икән. Без барлык планнарны үзгәртеп, икенче көнне юлга чыгарга карар кылдык. Чаллыдан без бергә укыган өч төрек дустыбызны да дәштек. Төркиядәгә дусларыма телефон аша хәбәр салдым һәм мәрхүмнең өй телефонын бирдем. Аннан соң Мәскәүдә яшәүче укытучыбыз Әлфинә ханым Сибгатуллинага да хәбәр иттем.

8 март. Пәнҗешәмбе. Хатын-кызлар бәйрәме. Ә без Мөнир абыебызны соңгы юлга озатырга барабыз. Алабу-

гага җиткәч, Сәлахи абыйны да алып, җеназа урынына бардык. Өйалды машиналар һәм кешеләр белән тулган иде. Шунда башка укытучыларыбызны да очраттык. Казаннан ук килгәнебезне белгәч, бик нык тәэсирләнделәр.

Без фатирга кереп киттек. Мөнир абыйның хатыны Рәмзия апа туганнары, дуслары арасында бик авыр хәлдә утыра иде. Күзләре ачык булса да, ул беркемне дә күрми, колагы да бернәрсә дә ишетми шикелле иде. Улы Сәйдәш күренде. 16 яшенә җиткән икән. Ул дөньяга аваз салган көннәрне хәтерлим, Мөнир абыебыз очып йөри иде. Ике кыздан соң малае туу әти кешене аерата шатландыргандыр, билгеле. Улына ни өчен Сәйдәш исемен кушканын ул миңа болай аңлаткан иде: «Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламнең нәселеннән булган кешеләрне «Сәед» дип атыйлар. Менә Сәйдәш шул мәгънәгә ия», — дигән иде.

Шунда мәрхүмнең бертуган абыйсын күрдек: Мөнир абыйга тач охшаган. Әйтерсең, безнең кырыйда Мөнир абый басып тора! «Сез хәзер Сәйдәшкә атасы урынына калган кеше», — дигәч, күзләре яшь белән мөлдерәмә тулды.

Мөнир абый 57 яшьтә иде. Кичә генә кафедрадагы хатын-кыз укытучыларның һәрберсенә атап чыгарган шигырьләрен укып, бәйрәм белән котлаган икән. Әйтерсең бу аның бәхилләшүе булган.

Җеназа намазы алдыннан хәзрәт үлем, ахирәт, җәннәт-җәһәннәм чынбарлыгы турында мәгънәле вәгазь сөйләде. Факультетның деканы, тарихчы Альберт әфәнде мәрхүмне бик җылы сүзләр белән искә алды: «Кафедрабыз ятим калды», — диде. Аннары сүз Мидхәт хаҗига бирелде. Ул болай диде: «94 нче елларда, халык әле ураза тотуның нәрсә икәнен дә белмәгән мәлләрдә, Мөнир мәрхүм Рамазан ае уразаларын тота башлады. Дин буенча булган чараларда актив катнашты. Раббым аның хата вә кимчелекләрен ярлыкасын, аны җәннәтле әйләсен», — диде.

Шуннан соң мәрһүмнең гәүдәсе машинага куелды һәм хушлашырга, дип университет бинасы янына барылды. Шунда Чаллыдан килгән өч милләттәшем дә безгә кушылды һәм без бергә зиратка бардык. Аллага шөкер, җеназа намазын укырга насыйп булды безгә.

Мөнир абый студент чагымда күңелемдә тирән эз калдырган, миңа иң нык йогынты ясаган укытучы булгандыр, мөгаен... Тел фәне миңа әдәбиятка караганда күбрәк якын. Балачагымнан ук аңлатмалы сүзлекләрне актарырга, укырга ярата идем. Мөнир абый безне татар теленең төрле тармакларыннан укытты. Ул үзе дә үз фәнен үлеп ярата иде. Аның дәресләрен йотылып тыңлый идек без. Дәресне шундый дәртле итеп бирә иде ки, ярыш аты шикелле, ару-талуны белмәс иде. Шуңа да инде күңелемдә татар теленә мәхәббәт утын кабызучы Мөнир абый булгандыр.

1994-95 нче уку елы. Мөнир абый диалектология дәресен алып бара. Ягъни татар теленең шивәләре дәресе. Беркөнне Мөнир абый дәрескә әллә

ничә битлек бер карта белән килеп керде һәм безне шаккаттырды. Рәсәйнең кайсы төбәгендә татарлар фәлән сүзне ничек әйтә — бөтенесе күрсәтелгән. Мин, кызыксына төшеп: «Мөнир абый, Төркиядә яшәүче татарлар турында да мондый карта эшләнгәнме?» — дип сорадым. Ул миңа:«Кая инде! 70 ел ишекләр ябык иде бит!» — диде. Миндә шул эш белән шөгыльләнергә бик зур дәрт уянып китте. Мөнир абыйдан эш сорап, җәй көне Төркиягә кайткач, бер дә белмәгән, булмаган җиргә — татарлар яшәгән Искешәһәр каласына барырга булдым.

Июль ае иде. Игезәк сыңарым Туран белән безнең шәһәрдән 11-12 сәгать барышлы Искешәһәргә диктафон, фотоаппарат, дәфтәр-каләмнәр алып, тәвәккәлләп юлга чыктык. Анда танышларның танышлары аркылы «Казан татарларының мәдәни җәмгыяте»нең ул вакыттагы рәисе Әмин әфәнде Сакмар белән таныштык. Ул берничә татар картын да чакырган иде. Без интервьюлар үткәреп, аларны җырлатып бик күп файдалы материаллар алып калдык. Алабугага килгәч, шуларны Мөнир абыйга күрсәттек. Аның ничек шатланганын белсәгез иде! Бу хакта үзе дә бер мәкалә язды хәтта. Шулай итеп, ул гел мине дәртләндереп, иңнәремә канат куеп торды. Шуннан соң 1996 елда да барып, тагын бик күп материаллар (такмаклар, кыска җырлар, хат үрнәкләре һ.б.) алып кайттым. Ахыр чиктә, «Искешәһәрдә яшәүче татарларның тел һәм фольклор үзенчәлекләре» дигән темага диплом эше яздым. Менә боларның барысына дә Мөнир абый сәбәпче булды.

Мөнир абый мәдәният өлкәсендә (җыр-театр) бик актив кеше иде. Безне әдәби-мәдәни кичәләргә әзерли иде. Ул безгә Тукайның «Туган авыл»ын (Алмаз Монасыйпов көе) өйрәткән кеше. Үзенең тавышы да бик матур, моңлы иде. Бездән төрекчә җыр сорап, шуны өйрәнеп, әлеге кичәдә үз кызлары белән бик матур җырлаган да иде хәтта. Аңарчы сәхнәнең нәрсә икәнен дә белмәгән бездән, ел саен шундый кичәләр куйдыра-куйдыра, сәхнә кешеләре дә ясады ул.

Шушы урында туктап, тагын бер хатирәмне язмый булдыра алмыйм. 1998-99 нчы еллар. Курсташым Хөсәен Чобан белән Казанга килгән идек. Килгән уңайдан, Тукай музеен эзләп табып, шунда бардык. Музейны карап-йөреп чыккач, мин Хөсәен дустыма: «Әйдә, Хөсәен, музей хезмәткәрләренә бер кызык ясыйк әле», — дидем. «Ярар», — диде. Мин бер хезмәткәрдән сорыйм:

— Сезнең актлар залыгыз бармы?

— Бар.

— Менә хәзерге вакытта музейда күпме хезмәткәр булса, аларны шунда җыя алмассызмы?

— Ярар, җыярбыз. Шулай да нәрсәгә кирәк булдык әле без?

— Без сезгә номерлар күрсәтмәкче булабыз.

Хезмәткәрләр залга җыелышып бетте. Хәзер, гаҗәпләнеп, нәрсә буласын көтә башладылар. Тамашачыларны: «Без — Алабуга дәүләт педагогия институтының татар филология факультетында укучы төрек студентлары», — дип сәламләп, тамашабызны күрсәтә башладык. Теге вакытта Искешәһәр татарларыннан отып алган такмакларны мин дә, Хөсәен дә моңарчы ятлап бетергән идек инде. Мин бер такмак әйтәм, ул икенче такмак әйтә, шулай озак дәвам иттек. Аннан җырлауга күчтек. Иң соңгы номер итеп «Туган авыл»ны җырладык. Тамашачыларның шатлыктан күзләренә яшьләр тыгылды. Безне алкышка күмделәр, бүләкләр бирделәр. «Әллә кайлардан килеп, телебезне өйрәнеп, Тукаебызны зурлаганыгыз өчен рәхмәтләр яусын сезгә!» — диделәр. Менә әлеге алкышлар һәм рәхмәт сүзләре, чынлыкта Мөнир абыебызга һәм барлык укытучыларыбызга иде. Чөнки без — аларның җимешләре.

Мөнир абый шулай ук безгә 94

нче елларда сүзләре үзенеке, музыкасы Владимир Мироваевныкы булган «Алабугам — ак калам» дигән җырны өйрәтеп ятлаткан иде. Менә хәзер шушы язманы язганда ул җырны тулысы белән яңадан тыңлыйсы килеп китте. Аны тыңлаганда Мөнир абый күз алдыма килеп басты, тавышы колакларымда чыңлады, күзләремнән яшьләр тәгәрәде һәм мин көне буе шул җырны тыңладым. Шул җырны бергә укыган милләттәшләремә дә (күбесе Төркиядә) җибәрдем, алар да үткәннәрне сагынып искә алганнар, күңелләре йомшарып киткән. «Мөнир абыебызны һич онытасыбыз юк, урыны җәннәттә булсын», — диделәр. Мин хәзер ул җырның иң үзәккә тия торган юлларын китерәм:

Изге җирем — Болгар илем,
Алабугам — ак калам.
Синең язмыш — минем язмыш:
Мәңгегә синдә калам...

Әйе... Сүзендә торды Мөнир абый... Шулай эшләде дә... Ул бит, югыйсә, Шыгырдан баласы иде...

И-и, бик кадерле Мөнир абыебыз! Без синнән мәңгегә бәхилбез! Син дә бездән бәхил булсаңчы... Мин Алабугага, укытучыларыбызның хәл-әхвәлен белергә барганда, синең янга да кагылам. Кабереңбашында догалар укып кайтам. Синнән соң, хәләл җефетең, гомер юлдашың — Рәмзия апабызның хәлен белешәм. Сәйдәш турында сорашам.

Мөнир абыем! Синең дә ишетәсең килә торгандыр, син дә шатланырсың, дип бер вакыйганы сөйләмәкче булам.

24 ноябрь — Төркиядә укытучылар көне. 2015 елның 24 ноябре өчен «ТНВ» каналының «Манзара» тапшыруыннан мин фәкыйрегезгә шылтыратып, шушы көн хакында сөйләвемне үтенгәннәр иде. Мин шул тапшыруга институтны тәмамлауга биш ел тулу уңаеннан очрашкан вакытта күмәкләшеп төшкән фоторәсемнең (2004 ел) электрон вариантын да алып барган идем. Тапшыру барышында Алабугадагы студент елларын, сезләрне телгә алганда экранга әлеге фоторәсем чыккан иде. Мин укытучыларымның берсенә дә шундый тапшыруның буласы турында хәбәр салмаган идем.

Ярар. 31 декабрь көнне хатыныгыз Рәмзия апага яңа ел белән котлап шылтыратканда ул миңа нәрсә сөйләде, беләсезме? «Фатих, 24 ноябрь ул — минем туган көнем. Ул көнне иртә белән җиденче яртыларда телевизорны кабызсам, каршымда әтиебез (Мөнир абый) басып тора. Шаклар каттым. «Ирем мине котларга килгән! — дип, шатлыгымнан нәрсә эшләгәнемне белмәдем. Туганнарга шылтыраттым, аларның да, телевизорны кабызгач, исләре-акыллары киткән», — дигәч, минем бала йонналарым бөяләнде, күзләремә яшь килде. «Аллаһы Тәгаләм гомер юлдашыгызны ничек сөендергән икән!» — дип үзем дә хәйран калдым бу хәлгә.

Рәхмәт яусын сезгә барысы өчен дә, Мөнир абый! Без сезне онытмыйбыз, онытмаячакбыз да.

PS. Әлеге фоторәсем 24 ноябрь көнне «Манзара» тапшыруында экранга чыкты. Укытучыларыбыз белән фотога төшкән 2004 ел шулай ук маймыл елы булган икән... Фотода Мөнир абый белән янәшә басып торам. Икебезнең уртада игезәк сыңарым Туран басып тора.

Мөнир Нигъмәтнең котлау сүзе:

«Рәсүл Гамзатов сүзләрен искә төшереп үтик әле:

«И Хатын-кыз! Мин сине өрмәгән урынга да утыртмам. Кулларымда гына күтәреп йөртермен. Шулай күтәргән килеш, Каф тауларының бөркетләр генә оча торган иң биек түбәсенә менәр идем һәм... шунда калдырып та төшәр идем».

Менә шундый капма-каршы фикертойгылар уятырлык, ләкин беркайчан да һәм бер ир-атны да битараф калдырмый торган илаһи көч тупланган бу Ха-

Мөнир Нигъмәт гаиләсе белән. Сулдан уңга: Диана, Мөнир, Сәйдәш, Рәмзия, Диләрә. 2007 ел

тын-кызда. Аны күпме генә күкләргә чөеп мактасаң да аз булыр…

Беренче юлга, тыйнаклык күрсәтеп, без бүген бер генә җөмләдән торган котлау адресы яздык. Бер утыруда укып чыгарга түземлек бирсен Ходай. Котлавыбыз исә мондый:

«Инде мәңгегә килдем, дигәндәй, бар табигатьне салкын, калын кар көртләре астына куып кертеп, барча җан иясен буарга җыенган суыкбай кышның зәмһәрирләрен пыр туздырып, йокыга талган, оеган, җансыз тереклеккә миһербанлы һәм туры караган кояшның беренче җылы нурлары белән җан өргән, яшәү дәрте биргән, киләчәккә өмет уяткан, язның кар сулары ташкыныннан йомычкага йомычка менгән гүзәл бер мизгелдә генә була торган язның тәүге бәйрәме — 8 Март көнендә йөрәктән чыккан иң изге хисләр өермәсен сезгә юллап, бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйбыз да шушы юлларны юллыйбыз (ә аларны юллавыбызның төп сәбәбе түбәндәгеләргә кайтып кала, дип уйлыйбыз): илләрне, патшаларны, олпат ирләрне сугыштырырлык көчкә ия булган, шул ук вакытта кәҗә бәтиенең вафатын ишетеп тә коелып төшкән көчез һәм саклауга мохтаҗ, үзен беркайчан да аңлап бетереп булмаган, булмый торган һәм булачак та түгел бу илаһи зат — фани дөньяда нарасый бала, аннан нәни кызчык, алга таба яшүсмер кыз бала, сылу кыз, кәләш, килен, хатын, ана, әби, каенана, карчык сыйфатында гомер кичергән гүзәл, сөйкемле, сихри, никадәр генә тырышып та азагынача укып бетерә алмаслык серле китап алдында бүген, үтә горурланып, үзен иң көчле арысланга тиңләсә дә, хатын-кызның бер карашыннан коелып төшкән, ул «на-а!» дисә кузгалып, «тр-р!» дисә тукталып, «ә!» дисә, суга сикерерлек, «җә-ә!» дисә утларга керерлек дәрәҗәдә каһарман гамәлләргә рухланган без, ир-ат мәхлуклары, тирән мәхәббәтебезне һәм соклануыбызны белдереп, ихтирам белән баш иябез». ■

Фатих Әмирхан

(1886-1926)

Иң әүвәл Татарстанның атказанган укытучысы Гаяз Байкиев (1888-1959) язып калдырган истәлеккә («Яраткан язучым», «Фатих Әмирхан турында истәлекләр», 1986, 145-147 битләр) игътибар итик әле:

«Мин 1924-1926 елларда Фатих ага Әмирхан белән бер йортта (Жуковский урамы, 12 нче йорт) күрше булып яшәдем, һәм без еш кына очраша идек. Мин үзем укытучы кеше. Фатих ага укытучыларны бик ярата, шуңа да булса кирәк, безнең сүзләр тиз ялганып китә иде... (...)

Фатих аганың дуслары, якыннары күп булуын да әйтеп үтәм. Татарстан сәламәтлек саклау халык комиссары Фатих Мөхәммәдьяров, язучы Кәрим Тинчурин, тел галиме Галимҗан Шәрәф, укытучы-журналист Ибраһим Биккулов, Әбүбәкер Терегулов кебек могтәбәр кешеләр аның янына килеп йөрделәр. Әдип К.Тинчуринны аеруча үз итә: «Мин Кәримгә шундый киңәш бирдем әле», «Кәримне ачуландым әле», — дип еш әйтә иде.

Үлем авыруы белән ятканда да Фатих ага янына гел кереп тордым. Татарстан партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре аңа зур кайгыртучанлык күрсәттеләр. Хәле авыраеп киткән вакытларында яныннан врачлар өзелмәде. Парадный ишегә янына машиналар еш килеп торды. Фатих ага мондый игътибарлы мөнәсәбәтне күреп бик дулкынлана: «Бу нинди хәл инде бу, бөтен хөкүмәт, бөтен Казан аякка басты», — дип әйтә, шул ук вакытта моңа үзенең эчке куанычы да сизелеп тора иде.

Әдип үзендә үпкә авыруы булуын яхшы белде, әмма төшенкелеккә бирелмәскә тырышып: «Җәй генә җитсен, Берсутка, нарат урманына барып, мин бу туберкулезның кирәген бирермен әле», – дип шаяртып алгалаганы да хәтеремдә. Әмма соңгы көннәрендә үләсен сизде. Актык керүемдә: «Хуш, Гаяз, исән бул, без киттек инде», дип, гади генә итеп әйтеп куйды. Дөрестән дә, мин эштән кайтканда, ул өзелгән иде.

Фатих аганы җирләү көннәре әле дә күз алдымда. Аны күрергә килүчеләрдән зур чират тезелде. Күмү көнендә Театр мәйданында зур митинг булды. Мәйдан халык белән тулды. Әдипне озатучы халык төркеме Жуковский урамыннан тотынып Тукай урамына кадәр сузылган иде. Халык арасында «Знаменитый татарский писатель» дигән рус сүзләре дә ишетелеп-ишетелеп китә иде.

Халык үзенең сөекле язучысын соңгы юлга менә шулай зурлап озатты.»

Хәзер исә журналист, педагог, Ф.Әмирханның якын дусты Ибраһим Биккуловның хатирәсен («Мәрхүмнең авыруы», «Фатих Әмирхан турында истәлекләр», 147-149 битләр) яңартыйк:

«Егерме елга якын аягына баса алмыйча, һаман утырып торган бер организмның, әлбәттә, таза организм була алмавы табигый. Фатих әле дә чиксез таза икән. Ул, шул хәлендә гомерендә берничә мәртәбә нык-нык авырып алуларына карамастан, соңгы елларга кадәр яхшы ук таза иде әле. Ул бары үткән 1925 елның язында гына начарлана төшеп, аңарда туберкулез авыруы барлыгы мәгълүм булган иде. Шуннан соң ул, үткән җәйнең ахырларында Кырымга китеп, анда ноябрьләргә кадәр калып дәваланган һәм яхшы ук тазарган иде. Кырымда вакытта үпкәләре тазара башлаган булса да, туберкулез арка сөягендә килеп чыгып, утырып тора алмаслык хәлгә килгән иде. Шулай итеп, мәрхүм Кырымнан үпкәләрен төзәтеп, үзе тазарган хәлдә, утырып тора алмаслык булып кайтты. Шул вакыттан (1925 елның 13 ноябрьләреннән) бирле Фатих һаман түшәктә ятып торды. Әнә шушы ятып тору аны тагын яхшы ук ябыктырды. Кырымда ярала башлаган туберкулезын яңадан кузгатты. Ләкин шулай да Фатихның апрель башларына кадәр Казанда торырлык хәле бар һәм яңадан Кырымга барып дәваланган тәкъдирдә тагын сәламәтләнүенә дә өмид бик зур иде әле.

Фәкать зур бәхетсезлеккә каршы, 1926 елның 15-20 февральләре арасында Фатих үзенә суык тидереп, температурасы күтәрелеп китә. Февральнең егермеләрендә инде 38,2 дәрәҗәләргә кадәр күтәрелә. Ләкин

Фатих Әмирхан. 1915 ел, май

Фатих Әмирханның шәхси таныклыгы. 1925 ел

Р. С. Ф. С. Р.
Т. С. С. Р.
Действительно по 1е 21 июля 1926 г.
Удостоверение личности.
Выдано Казстолмилицией Тат. Сов. Соц. Респуб.
1. Фамилия, имя и отчество Амирханов Фатых Зарифович
2. Год, месяц и число рождения 1886 г.
3. Место постоянного жительства ТР. гор. Казани
4. Род занятий — основная профессия Литератор
5. Отношение к отбыванию воинск. повинности
6. Семейное положение Холост
7. Перечень малолетних до 16 л., вносимых в данное удостовер.
8. Личная подпись владельца
Для фотограф. карточки
М. П.
21 июля 1925 г.
Гор. Казань
Начальник Казанской Столичной Милиции
Заведывающий Паспор. Стол.

Ф.Әмирхан соңгы елларын (1923-1926) яшәгән йорт. Жуковский урамы, 12 нче йорт

Фатих үзе моңар игътибар итмәскә тырыша, гадәти инфлуэнца гына дип карый, шуңар күрә доктор да чакыртмый. Якыннары, доктор чакырыйк, дип кат-кат әйтсәләр дә, мәрхүм: «Ә-ә-ә, андый инфлуэнцаларны гына күп күргән без, аны гына җиңәрлек хәлебез бар әле», дип, үзенең авыруына һаман әһәмият бирмәскә тырыша. Фатихның вакыт-вакыт һаман температурасы күтәрелгәләп торганга күрә, якыннары да һәм янына килеп чыккан кайбер дус-ишләре дә доктор чакырырга Фатихны артык көчләмиләр. Шулай итеп, февральнең 25 е җитә. Бу көн инде Фатих тагын да авыраеп киткәч, доктор китертәләр. Доктор килеп караганда инде Фатихның инфлуэнцасы 20 февральдән бирле үпкә шешүе авыруына әйләнгән булган, һәм 25 ендә инде авыру бик нык көчәйгән, авыруның температурасы 39 га җиткән булган. Доктор иң зарур чараларны күреп һәм Фатих янына шәфкать туташы куеп китә. 26 сында Фатих тәмам авырая, температурасы 39,5 кә җитә. Фатихның авыруыннан хәбәр алгач, якын дусларыннан берничә кеше килеп чыгып, шул көнне үк сәламәтлек халык комиссары Фатих Мөхәммәдьяров иптәшкә мөрәҗәгать итеп, белгеч докторлардан консилиум ясаталар. 27 сендә иртә белән Казанның иң атаклы профессорларыннан тагын бер консилиум ясала. Бу консилиумнар, мәрхүмнең хәленең начарлыгын әйтү белән бергә, өмидсез үк булмаганын әйтәләр һәм медицинаның иң соңгы чараларын күрәләр. Шунда ук татар яшь докторлары, үз араларында нәүбәт куеп, мәрхүм янында төннәрен кала башлыйлар. Көндезләрен һәрвакыт шәфкать туташы яки берәр фельдшер авыру яныннан һич аерылмыйча тора башлый. Табиблар, иртә-кич килеп карап, тиешле инструкцияне биреп китәләр, мәрхүмнең якын дуслары һәм мөхибләре төнен һәм көндез өзлексез кизүлек куеп кизүлиләр. Шунда ук мәрхүмнең дус-ишләре һәм мөхибләре сәламәтлек саклау халык комиссары Фатих иптәш Мөхәммәдьяров кул астында Фатихны коткаруның һәм, бераз хәле яхшыру белән, Кырымга

Ф.Әмирхан гәүдәсе янында. Сулдан уңга: Фатыйма Апакова, Разия Әмирханова, Габдулла Әмирханов, Гомәр Әмирханов, Газизә Яушева, Мәхмүт Әмирханов. Басканы – Габделхәмит Апаков, Газизә алдында утырганы – Зәкәрия Әмирханов

озатуның чараларын күрү эшләре өчен берничә кеше билгелиләр.

Берничә көн үтә, Фатихның хәле яхшырганнан-яхшыра бара. Табиблар үпкә шешенең төзәлә башлавыннан хәбәр бирәләр. Хәтта «Фатих котылды» дигән шатлыклы игътикад һәркемне шатландыра башлый. Шулай тагын бер-ике көн үтә. Фатихны Кырымга җибәрү турында уйлану башлана. Менә 4 мартка каршы төндә көтелмәгәннән Фатихның хәле начарлана. Янадан консилиумнар, табиблар чакырыла. Фатихта үпкә шеше бетеп барганлык, ләкин куркынычлы эчәк һәм карын шешү (воспаление брюшной кишки) авыруы килеп чыкканлыгы беленә. Мәрхүм бу куркыныч авыру белән дә актык хәлгә кадәр көрәшә. Ләкин егерме елларгача аягына баса алмыйча, утырып тора-тора тузып беткән организм бу авыруны җиңә алмый. Фатих 9 нчы мартта иртән 10 сәгать 10 минутта бездән аерыла.

Мәрхүм, үләргә ун-унбиш минут калганчыга кадәр тәмам аңында булып, килгән кешеләрне танып һәм һәркайсы белән берәр сүз генә булса да сөйләшеп ятты. Соңгы өч-дүрт көн эчендә инде үзенең калуына өмиде бетә башлаган, үлемне җиңеллек белән каршы алырга әзерләнгән иде. Хәтта актыккы төнендә үзенең иртә белән сәгать 8-9 араларында үләчәген янындагы кешеләргә әйтеп тә куйган булган. Мәрхүмнең күңел сизүе күп ялгышмады, сәгать ун тирәләрендә: «Әйдә киттек, күңелем рәхәтләнсен» сүзләрен әйткәч, озакламады — җан бирде.

Шулай итеп, Фатих кырык яшь тулганда бездән аерылды.»

Язманы ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

ХОЛЫК

Әхтәм Зарипов

Чорыбызның мәшһүрләреннән Рәсәйнең атказанган, Татарстанның халык артисты Наил Әюпов исемен ишетүгә, аның белән беренче очрашып танышуым мизгелләре җанлана: безнең төркем 1961 елда Мәскәүдән кайтып театрда эшли башлагач, миңа радиода режиссёрлык вазифасын ышанып тапшырдылар. Виктор Астафьев хикәясе буенча радиоспектакль әзерләргә тиеш идем.

Баш рольне башкарыр өчен моңа кадәр ишетелмәгәнрәк тавышлы җырчы артист кирәк иде. Шул мәсьәләдә киңәш-табыш итәргә дип, эфирда күп радиопостановкалар яңгыраткан редактор Ләбиб Айтугановка кердем. Бүлмәдә, Ләбибтән тыш, кулына «хромка» гармуны тоткан бөдрә чәчле мөлаем егет утыра иде. Ул, сүзләрен бүлдереп, минем килеп керүемә кәефсезләнеп: «Монда сезнең проходной двор икән, әле тегесе, әле бусы... Ишегеңне бикләп куймасаң, эш чыкмас», — диде, «кунак булсаң — тыйнак бул» кагыйдәсенә буйсынмыйча.

— Безнең ишек тыштан гына бикләнә шул, — диде Ләбиб, оста сәясәтчеләрчә.

Мин, мөһим сөйләшүләрен бүлдерүемә гафу үтенеп, йомышымны әйтергә ашыктым. Тәҗрибәле Ләбиб, гозеремне бик тиз аңлап:

— Әнә, утыра син эзләгән артист: уйный да, җырлый да. Кәсебе — студент, Сарымсаков шәкерте, Мөслимнән килгән Наил Әюпов», — диде.

Мин, сораучы булмаса да, Астафьев хикәясенең психологик яктан бик катлаулы булуын, андагы рольләрне башкарыр өчен артистларга нинди сыйфатлар кирәк булачагын үземчә бик «грамотный» телдә, төрле цитаталар кулланып, аңлата башлагач, Наил Әюпов, урыныннан торды да:

— Туктале, иптәш, син кем соң? Кемгә һәм нигә дип сөйлисең син бу китап сүзләрен? — диде.

Мин югалып калдым.

Киеренкелектән чыгар өчен, Ләбиб нидер әйтмәк булгач, Мөслим егете кыза башлады:

— Ә син, якташ, мине «сатканчы» кемгә кодалавыңны әйтсәң иде.

— Бу — щепкинчыларның берсе — Әхтәм Зарипов.

— Ә «щепкинчы» дигәнең ни аңлата?

— Шунда укып кайткан дипломлы артист, дигәнне аңлата.

— «Дипломлы» дигәнең «артист» дигәнен акласа, таныштыруыңа шатмын, — диде ул. Шуннан соң сумкасыннан яртылаш бушаган шешә чыгарып:

— Сал, Ләбиб, бергә булыйк, бердәм булыйк, үзебез булыйк! — диде дә, «хромка»сын кулына алды — кемдер керсә, «ширма өчен» саклакнып. Ләбиб, ирексездән, кунак ихтыярына буйсынырга мәҗбүр иде.

Мин, яследән бала аласым бар, дигән сылтау белән сыйдан баш тарттым. Наил шуны гомере буе онытмады. Җае чыккан саен, чыкмаса, чыгарып: «Щепкинчыларның табыны башка», — дип «төрттерергә» тырыша иде. Әмма усаллык белән түгел, мине кимчелегемнән коткарырга теләгән эчкерсез беркатлылык белән, җитешсезлегемә ташлама ясагандай итеп...

Академия театры Горький урамында, хәзерге Тинчурин театры урнашкан бинада эшләгәндә, грим бүлмәбез уртаклыгы безне бераз якынайтты.

Наилнең Казанда гына түгел, республикада дуслары күп иде.

Дусты булмаса — якташлары, еш кына күренекле артист белән танышырга теләүчеләр һәр спектакльдән соң диярлек грим бүлмәсенә күтәрелә.

Әлбәттә, буш кул белән түгел, шундый очракларда Әюпнең мине озатып җибәрүе гыйбрәтле:

— Ашыкмагыз, егетләр, менә бу күп балалы абзагызны озатыйк, юк-бар эш белән ул киткәч «шөгыльләнербез», — дип, «артык кашык»тан котылырга тырыша иде. Дөресен әйткәндә, аның шулай йомшак тотып катыга утыртуы күп чак кәефне бозгач (көчләп яраттырып булмый), без якынаеп, дуслашып китә алмадык.

Ул миңа түзә, мин дә аңа чыдыйм. Тәкәбберлеге өстенә, масаючанлык, эреләнү микроблары да йоктырган иде ул. Сүзе өстен чыксынга кешене кимсетүдән дә тайчанмый. Әмма, җаен табып, аның көен көйли белсәң, синең өчен җанын фида кылып, уткасуга керергә дә риза. Тиз сүрелә, саран түгел. Тик акчага туеп яшәгән чагын хәтерләмим. (Алай дисәң, кайсыбыз акчага туйган соң?)

Чәче генә түгел, күңеленең дә «бөдрәле» булуы аны миңа, мине аңа якынайта алмаганга, ул гына башкарырга тиешле рольләрне дә радио-телевидение спектакльләрендә башка (күндәмрәк) холыклы артистлар уйнады.

Астафьев героеннан башлана алмаган безнең тандем, аны эфирдан читләтсә дә, сәнгатьтән читләтә алмады.

Театр сәхнәсенә Наил Әюпов студент чагыннан ук басты. Чибәрлегенә өстәмә баритон тавышының моңлылыгы, җырга осталыгы, ишетү сәләтенең көчле булуы (слухы абсолютный, диләр иде) аны бездән — дипломлы артистлардан күпкә алга куеп, милләт көтеп алган артист итте.

Наил Әюпов Академия театрының тулы хокуклы әйдәүчесе статусына диплом алганчы ук ия иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр гел җаваплы рольләрдә генә уйнап, милләтнең сөекле, һәрчак тансык артисты титулына лаек булды.

Аның чыгышларын тамашачылар көтеп ала, кайбер чорсызлыкларын күрмәгән-ишетмәгәнгә сабыша, хөрмәтли, кунак итә. Моның исә популяр артист һөнәре өчен кирәкле дә, зыянлы да шартлардан икәнлекне танымыйлар...

Наил Әюпов мәктәп елларыннан ук, үзенең башкалардан өстен, тансык егет икәнен күңеленә сеңдереп, үз холыклы егет булып үсә. Авыл клубындагы кичке уеннар ансыз узмый, гармунда — ул, җыр — аныкы. Яшьләргә сүз әйтүче булса — яклаучы ул. Кирәк икән — сугышырга да әзер сакчы ул.

Кемнедер рәнҗетәләр икән — хөкем Наил кулында, аның каршында җавап бирәсе. Шундый шартларда өлгереп, егет булгач та Наилгә күп чакта «яшел ут» яна: кемгә күзе төшсә — шул кыз белән таныша, кыюлыгы да, әрсезлеге дә мулдан.

Кая барсын иртә өлгергән артист? Әлбәттә, аның юлы — мин-минлекнең иң биек түбәсенә! Әйе, менде Наил ул «түбәгә». («Тауга менүдән төшүе авыррак», диләр альпинистлар.) Түбәдән түбә генә күренә. Югарыга менгән — түбәндә калганнарга карамый. Караса да, күрми. Тауга күтәрелгәнгә астагылар түмгәк кенә булып күренә. «Кеше — тауга түгел, күп чакта түмгәккә

Г.Ибраһимов «Казакъ кызы». 1971 ел

абына», — ди шагыйрь. Әюпнең абынган чаклары күп булды. Ләкин безнең сүзебез аның «абынулары» турында түгел, талантының күтәрелүе турында.

Наил Әюповның башкарган эшләрен, уйнаган рольләрен санап, аларга бәһа куюга керешсәң — үзе бер китаплык «сүз» булыр иде. Минем максатым театрда ул уйнаган спектакльләрдәге рольләренә бәя бирү түгел. Аңа хакым да юк, холкым да рөхсәт итми. Уйнаган икән — димәк, шулай кирәк булган. Кирәк булган икән — димәк, аның уены яраган. Ярагач — яратканнар, яраткач — хуплаганнар, хуплагач — үстергәннәр.

Артист сәнгатенә минем үлчәү «берәмлегем» шул: үзеннән китеп, роле таләп итсә — түбәнәергә, кирәк булса, үзеннән югарырак булырга тиеш артист. Минем өчен үрнәк-өлге булыр артистлар: Аркадий Райкин, Игорь Ильинский. Наил Әюпов шулай ук әйбәт артист иде. Ләкин ул һәр уйнаган ролен йә үз биеклегенә күтәрә, йә төшерә. Ягъни, Наил Әюповның таланты уйнаган һәр ролен үзе биеклегенә куеп, шул персонаж исеменнән яшәүдә. Ышандырып, шик тудырмый яшәүдә. Еш кына мыегын да кырмый, киеме белән гримын да үзгәртми уйнаса да, төрле спектакльләрдә төрле персонажга әверелүенә ышандыра алуы — аның актёрлык диапазоны киңлеген, төсләр палитрасының төрлелеген күрсәткән сыйфатлардыр. Шул үзенчәлекләре белән ул да оригиналь һәм өлге булырлык артист.

Аның катнашында куелган фильм-спектакльләрдәге һәр ролен күреп белсәм дә, «Шамил Усманов»тагы Мәхмүден, «Каргышлы балачак»тан Садыйкны, «Габбас хәзрәт»тән Шәмсине һәм, әлбәттә, «Зәңгәр шәл»дәге Булатны кабатламас осталык белән иҗат ителгән, тулы канлы, үзенә җәлеп иткән хис-тойгыларга бай образлар, дип әйтер идем.

Тамашачы күңелендә һәр артист ниндидер бер роле белән саклана. Шул ук рольдә уйнавын башка бер тамашачыга ошамавы да ихтимал.

Наил Әюповны милләт горурлык белән хәтерләр, дип ышансам да, аның холкындагы кайбер сыйфатлары исеменә кара тап төшерүе сагайт-

ты. Шунда ук үземне-үзем тынычландырырга да ашыгам: кемдә юк соң ул «холык»? (Күпләр аны яшерә беләә.) Әюпнең сере юк иде. Булса да, яшерми иде.

Ул бик иртә өйләнә. Улы туута аерылышалар. Бала ятим үсә. Берчак, сүз ияре сүз чыгып, шул баланың язмышы турында сорагач, ул миңа, ачуланып: «Минем арттан чүп җыеп йөрергә ялландыңмы әллә?» — диде. Нигә соравыма үкенеп, югалып калдым. Соңрак, ике кыз баласы белән икенче хатынын да ташлады талант иясе.

«Каргышлы балачак» телефильмын төшереп, Балтач районы Шода авылында ятабыз. Наил — бер, хатыны икенче фатирда урнашты. Авыл халкы гаҗәпләнә: «Нигә шулай?» — диләр. Яраткан артистларын кушып, бәхетле итү максатында, ике хуҗабикә берләшеп, татулаштыру мәҗлесе үткәрергә була. Сарык суйдырып, мул табын әзерләп, кунак җыялар. Әюповлар түрдә. Табын барышында «кияү» дә, «килен» дә, берни булмагандай «тыныч» утыра. Хуҗа кеше, боларны татулаштырдым дип, ышанып:

— Чәйне мунча чыккач эчәрбез, әүвәл мунча кереп чыгыгыз, — ди.

— Мунча керттегез бит инде, — ди Әюп, тирләгән күлмәген күрсәтеп, һәм: «Сау булыгыз!» — ди дә, чыгарга ашыга.

Мәҗлес, аптыраудан сүзсез, телсез кала.

Соңыннан Шода халкы Наил Әюповның махсус концерт куюына да, сәхнәдән сөйләгән купшы сүзләренә дә гамьсез булып, бер генә сорауга җавап эзләде: «Кушылырлармы?»

Алар өчен иң истә калган «концерт» Наилнең теге мәҗлестән китүе иде, ахры…

Халык яраткан артистларын идеаллаштырып, аларның гөнаһлы «кыңгыр» якларын күрмәскә, күрсә — акларга, якларга тырыша; кечерәкләрен «итәк белән каплап» яшермәкче була. Итәк астына гына яшереп булмас гөнаһлары сизелгәндә дә, алданулары өчен тамашачы яраткан артистын түгел, ә үзен сүгә, үзен гаепли.

Нихәл итмәк кирәк — талант та кеше. Ә кешенең бер иңбашында иблис кунакласа, икенчесендә фәрештә утыра, имеш. Кайсының киңәшен тотуыннан чыгып, кешенең холкы формалаша, янәсе.

Минем уемча, Наил Әюпов ике киңәшчесенең берсенә дә колак салмады. Аңа үз рәхәте рәхәт иде. Ул үзенчә яшәде, үзенчә иҗат итте.

Аның уенын күреп алкышладылар, җырын тыңлап моңландылар.

Наил Әюповның талантлы, әмма дә ләкин каршылыклы шәхес булуын хәтерләп, кемдер аны гаепләр, кемдер кызганыр, кемдер юксыныр.

Мин үзем, мәсәлән, юксынучылар төркемендә. «Бер холыксыз кеше булмас, холык — холыкка охшамас», диләр. Дөрес түгел! Холкын эләктереп булмас «шомалар» басты дөньяны. Холкы нинди булса да, исән булса, Наил Әюпов сәнгате белән күп тамашачыларны үзенә каратыр иде. Әйе, аның үзенә карату, яраттыру таланты дорфалыкларын каплап, шәхесенә серлелек тә өстәгәндер. Дусларының күплеге моңа дәлил. Ни кызганыч, заман чиренә дучар булуы үзенә җәлеп иткән шул серлелектән түгел идеме икән?

Кайчан очратсаң да ул яңа дусты белән булыр, ялгызы йөргәнен күрмәссең. Әмма бу аның битлеге, кабыгы. Чынлыкта ялгыз иде ул, күңеле бикле иде. Шулай булмаганда аннан нинди моң агылсын?

Ничә тапкырлар хастаханәләрдә ятып дәваланса да, авыруларыннан арына алмады. Аның кайбер дуслары белән очрашып, хатирәләр уртаклашканда, гел бер сүзне кабатлап, «үзе гаепле», диләр.

Нәрсәдә гаепле? Талантлы, моңлы булудамы? «Дуслар»ны кире кага алмаудамы?

Әлбәттә, бу сорауларга җавап юк алардан. Иҗатташлары күңелендә

С.Баттал «Сигезенчесе кем?». 1974 ел

Наил кабатланмас шәхес һәм оригиналь талант иясе буларак урын алса, тамашачылар өчен аның Булаты — «Зәңгәр шәл»не кабат карарга килгәндә чагыштыру өлгесе, эталон, үрнәк.

Һәр талантлы артист «йолдыз» түгел, диләр. Ләкин һәр «йолдыз»ны артист, дип тә әйтеп булмый.

Наил Әюпов, «Сүнгән йолдыз»да уйнап та, үзенең сүнмәс йолдыз икәнен күрсәтте.

Халык артистлары Хәлим Җәләлев белән Наил Шәйхетдинов, сабакташларын сагынып, яшьлек истәлекләре белән уртаклашып утырганда, мәрхүмнең холкына хас берничә сыйфатын тәкрарлады: юашлыкны хәйләкәрлеккә тиңли, үзе усал иде, әмма мәкерле түгел; моңлы иде — зарлы, елак түгел; «вожак» иде — юлбашчылык дәгъва итмәде; иманлы иде — имансызлардан качты.

Әйе, «бәндә хатадан хали түгел», диләр. Әмма Наил Әюпов хаталанмады. Ул шундый иде, ул шулай гына яши алырга тиеш иде, шулай яшәде дә. Милләт яшәгәндә ул ничек булса — хәтерләрдә шулай яшәр.

Мәрхүмне соңгы юлга озатырга балалары белән ике хатыны да килгән иде, диделәр.

Минем игътибарым Әюпнеке кебек бөдрә чәчле ир-егеттә булды. Ул, мәрхүмнең табуты куелган өстәлгә чәчәкләр салды да, бер кырыйгарак китте. Мин аны күздән югалтмаска тырыштым... Ул «почётный караул»да торучыларга да карамый, тыңламый да — елый иде.

Миңа Наилнең улыдыр кебек тоелды ул. Электән күргәнем булмагач, өздереп кенә «ул» дип әйтә алмыйм. Шулай да, янына барып, сорарга җөрьәт иттем:

— Туганыгыз идеме? — дидем.

— Монда килгәннәрнең һәммәсенә дә туган тиешледер ул, — диде бөдрә чәчле милләттәш.

— Башкалар еламый ич...

— Башкалар... татар сәхнәсенең соңгы гусарын югалтуларына ышангач, еларлар. Әлегә ышануы авыр...

17 гыйнвар, 2016 ел

«АРЧА ГИМНЫ» – ЙӨРӘК ҖЫРЫМ!

Гөлзада Сафиуллина

Мәшһүр шагыйребез Зөлфәт татар җыры турында заманында:

«Татар җыры,
Бер юлдашның әйткәне искә килә:
Сезнең җырларны
тыңлавы авыр бит,
Җанга тия!» – дип язды.

Әйе, бу чыннан да шулай, халык җырлары безнең җаныбызда, каныбызда, геннарыбызда. Алар тумыштан безнең күңелләребезгә салынган.

Туган якка багышланган, табигатьнең илаһилыгы турындагы җырлар минем өчен барыннан да якынрак, кадерлерәк. Бәлки гомеремнең ун елын туган яктан читтә үткәргәнгәдер?.. Ул елларда китапханәләрдә очраган һәр газета-журналдагы шигырьләрне бөртекләп җыеп бардым. Әле дә аларны ташларга кулым ятмый. Борынгы җыр китапларын табып булмый иде ул елларда. Наданлыгым, ягъни гарәп алфавитын белмәвем аркасында, Коръән дип җыйган китапларымның күбесе агрономия, табигать белеме китаплары булып чыкты. Ә инде укылганнарын йөрәгебез аша үткәреп, күңел иләгеннән иләп, «мәңгелек шкатулка»бызга сала бардык. Менә шул әсәрләр, татар халык иҗаты тәрбияләде дә инде безне. Халык иҗатына олы хөрмәт мине мөнәҗәт, бәетләр дөньясына алып керде. Аның чиксез дәрья булуын, яшәешебезнең, тарихыбызның аерылгысыз төп нигезе икәнен аңларга ярдәм итте.

Соңгы елларда күп кенә заман җырчылары җыр сатып акча эшләгән дәвердә, мин халыкны мөнәҗәт, бәетләр, халык җырлары аша олы сәфәргә алып чыгып тәрбия кылдым, моңга сусаган җаннарга моң өләштем. Үземнең җыр студиямдә дөнья күргән дистәләгән тәрбия һәм укыту әсбаплары, аудио язмалары — моның ачык дәлиле. Шушы язмалар арасында революциягә кадәр яшәгән кырым татар шагыйрьләренең энҗе-мәрҗәннәргә тиң әсәрләрен көйгә салып һәм шулай ук кырым татар халкының каһармани җырларыннан торган җыентыкны дөньяга чыгарып, «Сөембикә» варисларына өләштем. Кырым белән Казан арасын тагын да якынайттым, дип уйлыйм. Шул ук вакытта профессиональ композиторларыбыз, шагыйрьләребез белән дә күп җырлар иҗат ителде. Җырны бит аны язу гына түгел, иң әүвәлге күңелдә тудырырга кирәк. Моның өчен шагыйрь, композитор һәм җырчының бер йолдызлыкка тупланып иҗат итүе мөһим. Әле дүртенче кеше дә бар! Ул, җырга оранжировка ясап, җан өрә. Менә шушы дүрт кешенең хезмәте җырның гомерен билгели. Яшәрме бу җыр, әллә юкмы?

Миңа күп еллар дәвамында танылган композиторыбыз Фасил абый Әхмәтов белән җыр тудыру процессында катнашырга һәм аның белән бергә бик күп авылларга барып, кыр станнарында, фермаларда, клубларда, мәктәпләрдә чыгыш ясарга насыйп булды. Фасил абыйның бер җырын радиога язганнан соң әйткән сүзләре һич онытылмый: «Сеңлем, җырымның скелеты минеке, ә ите синеке булган бит моның. Йә ярый, мин риза, җыр откан гына». Фасил Әхмәтов кебек талантлы, гади, үтә дә ихлас кешеләр сәнгать дөньясында күбрәк булса иде. Фәтхерахман Әхмәдиев, Шакир Мәҗитов, Мансур Мозаффаров, Салих Сәйдәшев, Александр Ключарёв, Сара Садыйкова, Заһит Хәбибуллин әсәрләрен җырлау миңа профессиональ җырчы булып өлгерергә ярдәм итте. Иң гүзәл җырның туган як турында булуын аңларга булышты. Шагыйрьләрдән Фәннур Сафин, Гөлшат Зәйнашева, Мөдәррис Әгъләмов, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллиннардан үзем теләгән темага бик күп кенә җырлар яздырдым. Алар белән һәрдаим иҗади дуслыкта булдык. Бергә иҗат иткән җырлар бүгенге көндә дә актуаль, минем фикеремчә, алар — мәңгелек.

Дистәләгән поэмалар авторы, язмышының иң тирән чоңгылларыннан исән чыгып та сынмаган, сыгылмаган, өлкән яшьтә булуына карамастан, тормышка, кешеләргә карата ышанычын югалтмаган гаять көчле, көрәшче шагыйрә Флёра апа Гыйззәтуллина белән дә безне уртак җырларыбыз, иҗади хезмәттәшлек берләштерде. «Сибелгән татар», «Мәңгелек мәхәббәт», «Зәңгәр төннәр гизеп», «Абага», «Кое әйләнәсе», «Әлмәтем», «Азнакаем», «Арча гимны» һ.б. бик күп җырлар аның сүзләренә язылды.

Сулдан уңга: Равил Фәйзуллин, Гөлзада Сафиуллина һәм Риф Гатауллин – Башкортстанда. 1986 ел

Туган ягым — Арча районының оешуына 70 ел тулу уңаеннан, шул чорда хакимият башлыгы булып торган Илһам Сабиров миннән районыбызга багышлап җыр язуны үтенде. Мине халык җыры «Арча»дан да артык җыр иҗат итеп буламы соң, дигән уй шиккә салды. Әмма язарга кирәк! «Үзең җырларсың», дип тә өстәгәч, әлбәттә, язмый булмас. Арча турында, туган ягым турында җыр, ул инде бик илаһи җыр булырга тиеш, дип Флёра апа Гыйззәтуллинага шылтыраттым. «Арча төбәге бит — Тукай, Мәрҗани, Курсавилар ватаны, шул исемнәрне дә җыр текстына кертсәң иде», — дидем. Флёра апа бер төн эчендә җырның сүзләрен язып та бирде. Миңа бик ошады, әмма ритмы башка, кайбер җирләрен үзгәртергә кирәк. Ни дисәң дә, мин инде җыр рәтен белгән кеше. Флёра апага үземнең фикерләремне әйттем. Ул минем белән килеште. Безгә әле бу җыр текстын берничә мәртәбә үзгәртергә дә туры килде. Ниһаять, җыр «старт»ка басты. Күңелемдә инде ритмы да табылды, көе дә туган кебек. Әлбәттә, Ф.Әхмәтов, С.Садыйковаларның юлын дәвам итүче, танылган композитор Риф Гатауллин гына бу җырга моң өрәчәк. Һәм шулай булды да. Искиткеч матур көй язды аңа Риф. Аның белән иҗади дуслыкта йөзләгән җырыбыз туды. Оранжировкасын Ташкенттан кайткан талантлы музыкантыбыз Шәүкәт Гыйльфанов эшләде. Менә шулай дүрт кешенең хезмәте нәтиҗәсендә җыр камилләште. Районыбыз бәйрәменә Ф.Гыйззәтуллина, Р.Гатауллин һәм мин кайтып, әлеге җырны —«Арча гимны»н бүләк иттек. Халык бик яратты, шатлыгыбыз эчебезгә сыймады. Шулвакыттан бирле күп еллар үтте, әмма «Арча гимны» яңгырамаган бер генә бәйрәм дә, сабан туйлары да үтми. Җыр чыннан да гимнга әверелде. Районым, якташларым, туган авылым, җырларыбыз белән бик горурланам. Үзем исән чакта Арчама «җыр һәйкәле» куя алуыма сөенеп бетә алмыйм. «Арча гимны»н һәр концертымда яратып башкарам. Ул бит минем йөрәк җырым. Һәр төбәкнең, һәр якның үз гимны булырга тиеш, дип уйлыйм. Ә ул «Арча гимны» кебек яшьләрне дә, картларны да рухландыра торган булсын. Аны тыңлаганда, җырлаганда яшисе килсен! Халыкка көч бирсен ул!

АРЧА ГИМНЫ

Флера Гыйззәтуллина сүзләре
Риф Гатауллин көе



АРЧА ГИМНЫ

Илһам нуры җанны чорнап ала,
Ак каеннар шаулап яфрак яра,
Изге манаралар күккә ашып
Азан әйтеп таңны каршы ала.

Кушымта:
Ак каеннар Ватаны син, Арча,
Илһамият Ватаны син, Арча,
Изге моңнар Ватаны син, Арча,
Ватанымның ал таңы син, Арча.

Һәр юлчыга яшел яфрак изәп,
Арча җырын җырлый ак каен.
Мөхәммәттәй затлы туган телем,
Халкым кебек тугры Тукаем.

Кушымта:

Бөек Тукай Ватаны син, Арча,
Мөхәммәтләр Ватаны син, Арча,
Ай-йолдызлар Ватаны син, Арча,
Ватанымның ал таңы син, Арча.

Җидегән чишмәләрдән ургылган моң
Мәңгеләшә безнең җырлар аша.
Мәрҗаниләр, Курсавилар рухы
Гыйлем тавы булып алга баса.

Кушымта:

Мәрҗаниләр Ватаны син, Арча,
Сулмас яшьлек Ватаны син, Арча,
Дан-шөһрәтләр Ватаны син, Арча,
Ватанымның ал таңы син, Арча. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

НУРАЛИ КАПКАСЫ ЯНЫНДАГЫ ЧИШМӘ — Русча чыганакларда — *Тайницкий ключ.* 1552 елда камалышта калган казанлылар, яшерен җир асты юлыннан чыгып, моннан су ала торган булганнар. Казанны штурмлаган вакытта рус гаскәре бу юлны шартлата һәм казанлыларны чиста судан мәхрүм итә.

1730 елгы сызымда ул чишмә ачык күрсәтелгән, ә XIX гасырның беренче яртысында чишмә тирәсенә таш тезеп, бассейн ясаганнар. Аның суы шифалы һәм изге дип саналган. Н.А.Спасскийның 1910 елда нәшер ителгән «Очерки по родиноведению» китабында бу чишмәнең фоторәсеме бар. Чишмә өстендә шатрун түбәле ике чатыр корылган. Рәсемдә берничә мөселман хатыны чишмәдән су алып тора.

1931 елга кадәр бирегә сәҗдә кылырга килеп йөргәннәр әле. 1950 еллар башына инде чишмә юкка чыккан, күмелгән һәм бүген аның урынын төгәл генә күрсәтеп тә булмый. Чишмәне күмеп, аның исемен татар хәтереннән сөреп чыгарырга омтылыш совет чорына хас милли сәясәтнең чын йөзен ачып сала.

Шартлы рәвештә *Нурали чишмәсе* дип атарга мөмкин, ә «Яшерек(ле) капка», «Яшерек(ле) чишмә», «Яшерек(ле) манара» дигәндә мәгънә дә, атаманың эмоциональ көче дә сакланыр иде.

ОЗЫН КУЛ ГЕОРГИЙ — Мәскәүгә нигез салган кенәз Юрий Долгорукий (Ш.Мәрҗани буенча). Аның кушаматын «Озынкул» дип кушып язу кулай. Гомумән, «Озынкул» кушаматы борынгы төркичәдә үк булган һәм русларга ул татардан кергән булырга мөмкин. Ә гарәпчәдә озын кул — *йәд тула.*

Тагын кара: ***Озын ихтыярлы кешеләр.***

ОС — Борынгы төрки телгә барып тоташа торган *ус, уз* («тәҗрибәле, акыллы») тамырыннан, *хәтер* һәм *игътибар* мәгънәсендәге парлы *ис-ос* сүзендә катнаша. Чуаш телендә — *ăс* (акыл, фикер). Татар телендәге *ушлы* сүзе шушы *ос*-тан булса кирәк. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»нә теркәлгән фарсы чыгышлы *уш/һуш* сүзе *ис* (хәтер, зиһен, аң) мәгънәсенә ия. //*Ушлы кеше* (тискәрерәк төсмерле мәгънәдә әйтелә).

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Нурали капкасы янындагы чишмә урыны

ОСУЛ ӘД-ДИН *г.* — Ислам диненең төп нигезләре, тамырлары: 1. Бер аллалык турындагы тәгълимат *(тәүхид)*; 2. Илаһи гаделлеккә, Аллаһының гадел хөкеменә ышану *(гадел)*; 3. Мөхәммәднең һәм аңа кадәрге пәйгамбәрләрнең Рәсүллеген тану *(нәбүвәт)*; монда, Коръәндә телгә алыну-алынмауларына карамастан, Тәүрат белән Инҗилдә телгә алынган барлык пәйгамбәрләр дә күздә тотыла. 4. Кабердән кубарылуга, Кыямәт көненә һәм ахирәткә ышану *(кыямәт яки мәгад)*; 5. Имамәт-хәлифәт турындагы тәгълимат.

Бу нигезләрнең дүртесе сөнниләр өчен дә, шигыйлар өчен дә уртак. Имамәт — югары хакимият турындагы мәсьәләдә алар арасында фикер башкалыгы хөкем сөрә.

ОТРУБ *тар.* — Сөйләм телендә — *утрыб/утрып*. XX гасыр башларында, Русиядә Столыпинның аграр реформасы барышында, җәмәгать җирләреннән крәстиән хуҗалыгы милке итеп бүлеп («кисеп») бирелгән җир мәйданы («хосусый имана җире»). Отрубка аерылып чыккан крәстиәнгә җир бер урыннан бирелгән һәм, хутордан аермалы буларак, йорт утары анда күчерелмәгән. Мәс., Татарстанда 1910-11 елларда Минзәләбаш авылы (хәзерге Сарман районы) крәстиәннәреннән отрубларга аерылып чыгып җир алучылар 61 хуҗалык булган. Отруб җире алучы хуҗалыкларның бер өлеше мул тормышлы хуҗалыклар — муллалар, сәүдәгәрләр һәм таза хәлле крәстиәннәр, бер өлеше урта хәллеләр һәм элек җире аз булган берничә хуҗалык та булган. Болары еш кына үз җирләрен бай кешеләргә сатып җибәргәннәр.

1914 ел башына Казан губернасында 13,3 мең отруб исәпләнгән. 1917-18 елларда отрубларга бүленеп чыгу туктатыла, ләкин НЭП елларында кабат активлаша.

Совет хакимияте елларында коллективизация барышында отрублар да юкка чыккан. ■

СҮЗЛӘР ТАРИХЫННАН: «КАРАНДАШ»

Әбрар Кәримуллин
(1925-2000)



Бу сүзнең каян һәм ничек килеп чыгуы белән шактый күп кызыксынганнар. Урыс теле галимнәре Корш, Ушаков һ.б. аның этимологиясен «кара» һәм «таш» сүзләре кушылудан, дип аңлаталар. Шушы ук аңлату татар теле белгечләре тарафыннан да яклана.

Әмма дә бу аңлатманың дөреслеген Дмитриев беренче мәртәбә шик астына куйды. Беренчедән, карандашны уйлап чыгаруда төрки халыкларның төп роль уйнавына шикләнсә, икенчедән, ул «кара» белән «таш» сүзләре арасындагы «н»ның барлыкка килүенә шик белдерә. Дмитриевның бу карашы хәзергә кадәр тел белгечләренең игътибарыннан читтә кала килде.

> Менә урыс телендәге «бояре» сүзе. Ул татардагы байлар сүзеннән ясалган. Башта урыслар «боляре» дип аны татар телендәге әйтелешенә якын рәвештә кулланганнар.

Бер уйласаң, «кара» һәм «таш» сүзләре кушылудан «карандаш» барлыкка килүен аңлату бик җиңел һәм аңлаешлы күренә. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Гомуми кагыйдә буларак, ике сүз кушылып яңа сүз ясалганда, бервакытта да яңа авазлар, бигрәк тә тартык авазлар өстәлми. Киресенчә, кайбер сузык авазлар — ике сузык бергә туры килгәндә — төшеп кала, ә тартык авазның урын алмашуы гына мөмкин. Соңгысы бик сирәк очрый. Аңа мисал табуы да кыен. Менә урыс телендәге «бояре» сүзе. Ул татардагы байлар сүзеннән ясалган. Башта урыслар «боляре» дип аны татар телендәге әйтелешенә якын рәвештә кулланганнар. Рус кнәзьләре һәм Мәскәү дәүләте белән аралашканда татарлар үзләрен «без байлар», «без татар байлары», «без Казан байлары» дип белдергәннәр. Тора-бара «л» авазы төшеп калып, бу сүз рус теленә «бояре» дип кабул ителгән. Ике сүздән яңа сүз ясалганда, беренче сүзнең азагы, икенче сүзнең башы сузыклардан торса, берсенең төшеп калуы кагыйдә булып киткән. Мәсәлән, «Алма агачы» — алмагач, «кура җиләге» — куражиләк, «кара урман» — карурман һ.б.

Карандаш сүзенең күрсәтелгән ике сүздән барлыкка килүенә Дмитриевның шикләнеп каравы, күреп үткәнчә, хак булып чыга.

Чыннан да, бу сүз ничек барлыкка килгән соң? Шушы сорауга җавап эзләп карыйк. Билгеле булганча, көнчыгышта барлык кулъязма әсәрләр элек нигездә тушь карасы белән язылган. Тушьның ватаны — Кытай. Биредә тушь нечкә таякчык сыман эшләнә. Язар алдыннан ул таякчыкны суга манып, каты предметка ышкып, эретеп, сыекча-кара ясыйлар. Шәрык

халыклары, шул исәптән болгар-татарлар, борынгы заманнарда тушьны таякчык формасындагы каты хәлендә Кытайдан алып кайта һәм аннан сыекча тушь-кара ясап яза торган булганнар, дип уйларга туры килә.

Халкыбызның тормышы, гореф-гадәте белән якыннан таныш булган, XIX йөзнең беренче яртысында Казан университетында эшләгән профессор Карл Фукс татарларның язу өчен һинд әтәче каурыеннан каләм ясап, «язу өчен караны каты тушьны суга манчып, изеп ясау»ларын язып калдырган. Кытайда тушь карасы ничек ясалса, галим күрсәтүенчә, бездә дә нәкъ шулай ясалган.

Кара ясый торган тушьның таш кебек каты булуыннан чыгып, кытайча «туш» сүзенең татарча «таш» сүзенә яңгырашы буенча да бик якын булуыннан, аны бездә «таш» дип атап йөртүләрендә бернинди дә аңлашылмаслык, искитәрлек нәрсә юк.

Карандаш сүзендәге «даш» ничек «таш»тан килеп чыгуы да шөбһә тудырмый. Шуны искә алыйк: татар телендә «н» һәм «ң» авазларыннан соң, кагыйдә буларак, бервакытта диярлек (чит телләрдән кергән сүзләрне искә алмаганда) «т» авазы кулланылмый, ә «д» авазы гына килә. Мәсәлән: «карандаш», «урындык», «Казанда», «куандыру» һ.б. Чагыштырыгыз: «теләктәш», «Тәтештә», «якташ» һ.б. «Т» белән «д» авазларының урын алышулары борынгы төрки телгә дә хас күренеш: таш — даш, тау — даг һ.б.

Хәзер «каран» өлешенең кайдан килеп чыгуын тикшереп карыйк. Башта шуны искә төшерик: элекке заманнарда иң күп күчерелеп языла торган кулъязма китап Коръән һәм аның аятьләре булган. Бу изге эш булып исәпләнгән. Аны күчереп язу өчен әнә шул тушь карасы кулланылган. Функциональ этимологиядән билгеле булганча, теге яки бу эшне башкару өчен нинди предмет киң кулланылса, шуның исемен дә йөртә башлаган. Бу

«Карандаш», безнеңчә, шулай итеп, «Коръән ташы»ннан, ә «таш»ы «тушь»тан татар теле нигезендә барлыкка килгән.

бик табигый хәл. Мәсәлән, агачларның төре күп булган кебек, ташлар да күптөрле. Ташларның барысы да таш булган кебек, агачларның барысы да — агач. Ләкин кулланылышларына карап, аларны без бер-берсеннән аерырга өйрәнгәнбез. Мәсәлән, мичкә ут кабызып җибәрү өчен кулланыла торган агачны чыра агачы — «чырагач» дип йөртәбез. Таба агачы — «табагач» һ.б. Шуның кебек, Коръән язу өчен кулланыла торган ташны гадәти таштан аеру өчен «Коръән ташы» дип йөртә башлаганнар. Безгә балачакта бу сүзне ишетергә генә түгел, аның нәрсә икәнен дә күрергә туры килде. Ул чүпрәккә төрелеп, җыеп-яшереп куела торган кара таш кисәге булып, берәр дога язганда суга манчып кара ясый торган тушь иде. Аны менә шулай «Коръән ташы» дип атыйлар да иде инде.

Күреп үткәнчә, атаклы төрки телләр галиме Дмитриевның карандаш сүзенең «кара» һәм «таш» сүзләреннән кушылып ясалуына шикләнеп каравы хак булып чыга. «Карандаш», безнеңчә, шулай итеп, «Коръән ташы»ннан, ә «таш»ы «тушь»тан татар теле нигезендә барлыкка килгән. Ә инде тартым кушымчасы «ы»ның төшеп калуы бик аңлаешлы күренеш, аңа туктап торуның кирәге дә юк. Карандаш уйлап табылгач, аның формасы һәм кулланылышы да каты тушь таякчыклары «Коръән ташы»на охшаганлыгыннан, аналогия буенча, «карандаш» дип атала башлаган булса кирәк.

1988 ел.

Татарстан радиосының «Тел күрке — сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

ТР МИЛЛИ МУЗЕЕ ФОНДЛАРЫННАН

ТАТАР АВЫЛЫ ХАТЫН-КЫЗЫ КИЕМЕ

Татар хатын-кызы кайда гына яшәмәсен, шәһәрдәме, авылдамы — чисталыкка, пөхтәлеккә, матурлыкка омтылган. Хатын-кыз, шәһәр халкыннан аермалы буларак, авылда һәрвакыт эштә булганлыктан, киемне пычратудан саклау өчен алъяпкыч киеп йөргән. Бүген дә яратып кия аны авыл хатыннары. Югарыга кадәр күтәрелеп, күкрәкне дә каплый торган алъяпкыч — хатын-кызлар эш киеменең бер өлеше. Татар хатын-кызлары аны аеруча матур итеп бизәргә яраткан. Кызыл яки сары киндергә төрле төстәге бизәкләр төшерелгән, соңрак фабрикада тукылган ак тукымага ачык төсләр белән чигү чигелгән кызлар алъяпкычы бөрмәчек, җыерма, сырмалар белән тулыландырылган.

Көндәлек күлмәк арзанлы киң фабрика тукымасыннан тегелгән. Ә камзулны хатын-кыз кияүгә чыкканнан соң кигән. Аны бәрхеттән, чуар үзбәк әдрәсеннән тектәннәр. Авылда камзул урамда киеп йөрү өчен хезмәт иткән.

Буйлап бәйләнгән һәм ияк астына, ә кыр эшләре вакытында баш артына бәйләп куелган ситсы яулык — авыл хатын-кызының төп баш киеме. Ә ефәк шәл бәйрәм киеме булып саналган. Хатыннар аны яулык өстеннән, ә кызлар ак калфак өстенә япкан. Кияү кәләшенә матур шәл бүләк итә торган булган.

Руфия Мөхетдинова *әзерләде.*

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның март ае

Тексты һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мәдрәсәи Мәрҗаниягә вәкыф

Остазыбыз дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре моннан 35 ел элек тәәсис вә бина итдеке мәдрәсә хифзыссыйхәткә[1] муафәкать [туры килгән], тәдәррес [уку] вә мәгыйшәт өчен уңайлык җәһәтеннән ул вакыттагы эчке Русия мәдрәсәләренең иң мөкәммәле вә иң яңа ысулдагысы булса да, башка мәдрәсәләребезнең күбрәге кеби бу мәдрәсә хәзергә кадәр һичбер төрле вәкыф вә ирад[2] берлә тәэмин ителмәгән иде. Хәлбуки, дини мәктәп вә мәдрәсәләребезнең вәкыфлар берлә тәэмин кылынмавы, аларның дәвам вә тәрәккыйләренә булган манигъларның [чикләүләрнең] олугсыдыр. Шунлыктан, соңгы елларда, бу мәсьәләләрнең әһәмиятен аңлаган һиммәт ияләре, дини мәдрәсәләребезне вәкыфлар берлә тәэмин итү чараларына керештеләр. Шул җөмләдән бу көннәрдә мәдрәсәи Мәрҗанияне бер дәрәҗә тәэмин итүгә тәшәббес кылынды [керешелде]. Мәдрәсәне бина кылуда мал вә хезмәте илә иң күп ярдәм иткән мәрхүм Сафа хаҗи Галикәевнең варислары Садыйк карый Галикәй вә Габдрахман хаҗи Галикәй җәнаблары һәм мәрхүмнең башка әүляд [бала] вә әкърибасы [кардәше] Мәскәүский урамдагы утыз мең сумнан артык торырлык таш йортларын мәдрәсәи Мәрҗания файдасына вәкыф иттеләр. Бу йорттан хәзер еллык ике мең сум варидәт [керем] килмәктә булып, киләчәктә тагын артачагы мәэмүлдер [ихтималдыр]. Мелла Кәшшафетдин Тәрҗемани.

Кояш. — 1916. — №927. — 4 март.

Бохара урамы

Евангелистовский урамның Кабан күленә каршы булган җире тәмам карлары арчылмаган, бозлары чабылмаганга чокырланып беткән. Бу чокырлар буй-буй сызылып киткән булганга, бер яктан шакшы кәрваннарның өзлексез йөреп торуы сәбәпле, икенче яктан атлы чаналылар, сирәк-сирәк кенә арбалылар очрашып бәрелешәләр, әләгешәләр. Мондый чакларда аерылышып китә алмыйча бер урында озак бәлаләнеп торулар нәкъ Бохара вә Төркестан шәһәрләре урамнарындагы араба кешеләренең тар урамда буталышуларына охшап китәдер. Иртә белән мәктәп балаларын атта озатучыларга шундый хәлләргә еш-еш очрарга туры киләдер.

Кояш. — 1916. — №932. — 13 март.

Зур һиммәт [тырышлык]

Казанның беренче мәхәлләсенең (Шиһаб хәзрәт Мәрҗани мәхәлләсе) яңа байларыннан Садыйк әфәнде Кәримов тарафыннан шушы мәхәллә

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Хифзыссыйхәт — сәламәтлекне саклау.

[2] Ирад — күчми торган милектән алынган керем.

мәдрәсәсенә (мәдрәсәи Мәрҗанигә) карашлы фокара [фәкыйрь балалар] мәктәбе файдасына вәкыф ителеп, дәүләт банкына егерме мең сум акча салынган. Бу вәкыфтан файдалану юллары хакында киңәшү өчен мәхәллә картларыннан гыйбарәт мәҗлес җыелган. Мәҗлестә вәкыф иясе, үзенең вәкыфының килере белән мәктәптә ятимнәр тәрбия кылуны максат итеп тотканлыгын, акчаны хәзердән банкка салуына, акчаның үз милкеннән чыгып ният иткән урынга билгеләнеп калуын мәслихәт күргәнлеген белдергән. Мәҗлес вәкыфны мәгалмәмнүният [шатланып] кабулга ашырып, шартларын тәртип итәргә биш кешелек комиссия сайлаган.

Шул ук мөнәсәбәт белән мәҗлестә мәдрәсәи Мәрҗаниянең ремонтка мохтаҗ икәнчелеге телгә алынган һәм Садыйк кари Галикәев кузгатуы буенча бу эш өчен дә акча бирергә язылулар булган. Сабит әфәнде Хәбибуллин — 3000, Садыйк кари Галикәев — 2000, зур һиммәт иясе Садыйк әфәнде Кәримов — 1000, Мөхәммәтҗан әфәнде Кәримов — 1000 сум. Җәмгысе 7000 сум язылганнар һәм Садыйк Кәримов акчсын шул ук мәҗлестә биреп калдырган. Мәҗлестә булган Гыйлметдин хаҗи Ибраһимов: «Сез күпме язсагыз, мин шулкадәр бирәчәкмен», — дип вәгъдә кылган. Гыйлметдин хаҗи бу фикерен мәйданга гарыз кылып та, язуга имза итмәгән булса да, сүзендә торыр вә вәгъдәсе белән өстенә йөкләгән 7 мең сумны бирергә кылган гаһеден [бурычын] үтәр, дип өмид итәргә тугры киләдер.

Рус теле мөгаллимәсе

Гимназия бетергән һәм хәзерге көндә Казанда русский-татарский прошколада рус теле мөгаллимәсе булып торучы татар кызы җәй көне читкә китеп укытырга телидер.

Кояш. — 1916. — №940. — 27 март.

Гаскәриләргә пасха бүләкләре

Гаскәргә пасха бүләкләре җибәрү вә шуңа иганә җыю вә махсус көн ясау өчен бюро университетта һәр көн 12 сәгатьтән 3кә кадәр ачыктыр. «Гаскәриләргә пасха бүләге көне» өчен район рәисләре тәгаен кылынган инде. Боларның барысы 20 кадәр булып, мөселман районнары өчен ихтияр ителгәннәре: Гайшә Терегулова — 1 нче ... йортында; Гайшә Юнысова — Екатеринский урамда, үз йортында; Кәшшаф Тәрҗемани — Яңа бистәдә Симбирский урамда, үз йортында.

Кояш. — 1916. — №941. — 29 март.

Караклык

Алат авылы янындагы Булыгиннар ширкәтенең аракы заводы хәзерге көндә хәзинәгә спирт әзерләү белән мәшгуль булып, йөк белән озатып тормакта вә йөкләрнең күбесе мөселманнар тарафыннан Казанга күчерелмәктә. Өченче көн шушындый спирт мичкәләр белән Казанга китерелеп, йөктән төшерелгәндә мичкәләрнең җиңеләйгәне сизелгән вә тәфтиш кылынган. Тикшерелгәннән соң ике мичкәдән 15 чиләкләп спирт агызылып алынганы, бу эшне Салих Мозаффаров җитәкчелегендә йөк күчерүчеләр эшләгәне мәгълүм булган.

Кояш. — 1916. — №942. — 31 март. ■

Көлке куа килә...

ПАТША ИСЕМЛЕ... ЖУКЛАР

(Интермедия)

....

Фоат Садриев

Катнашалар:
Китап алучы
Беренче китапханәче
Икенче китапханәче
Өченче китапханәче
Дүртенче китапханәче
Бишенче китапханәче

Абонемент бүлегендә беренче китапханәче ялгызы.
Китап алырга килүче керә.

Китап алучы *(гыжлап).* Уф, кых, җәһәннәм тишеге шушыдыр.
Беренче китапханәче. Исәнмесез, узыгыз.
Китап алучы. Миңа ни кирәк иде.
Беренче китапханәче. Ни?
Китап алучы *(ике бармагын кара-каршы китереп).* Мондый китап кирәк.
Беренче китапханәче. Авторы бармы?
Китап алучы. Авторы чүпрәк.
Беренче китапханәче. Чүпрәк?!
Китап алучы. Авторы дисең... Китапның төбедер бит ул?
Беренче китапханәче. Язучысы. Исеме, фамилиясе...
Китап алучы. Карале, килгәндә хәтеремдә иде. Тел очында гына эленеп тора *(телен чыгара).*
Беренче китапханәче. Юк, анда күренми.
Китап укучы. Патша исеме иде ул.
Беренче китапханәче. Шәехзадә Бабичмы әллә?
Китап алучы. Үзбәкләрдә кем соң әле, муены аркылы килеп дөмеккере!..
Беренче китапханәче. Әмир түгелме?
Китап алучы. Во, сыер икәнсең — өстенә бастың!
Беренче китапханәче. Мирсәй Әмир, шулмы?
Китап алучы. Юк. Шуны да белмәгәч, ник кенә утырасыз соң сез монда хөкүмәтнең акчасын имеп, ә?!
Беренче китапханәче. Әмир Мәхмүдов, Әмир Камалиев.

Китап алучы. Юк, юк!

Беренче китапханәче. Китапның исеме ничек?

Китап алучы. Оныттым! Склероз! Онычыгма иртәгә имтиханга кирәк.

Беренче китапханәче. Нишләп үзе килмәде соң?

Китап алучы. Бәла аяк астында йөри бит ул. Идәндә яткан ногыт борчагына яланаягы белән ялгыш китереп баскан! Аның үкерүен күрсәң! Шуны, скорый чакырып, вишневский мазь белән бәйләдек. Хәзер бот күтәреп виноград-миноград сулары чөмереп ята.

Беренче китапханәче. Шылтыратып үзеннән сорагыз. Менә телефон.

Китап алучы. Әйе, сезнең теләсә кем теләсә нәрсәсен тоткан кулы беләнябышкан телефоныгыздан шылтыраттым ди менә хәзер. *(Кесә телефоныннан үтә ягымлы тавыш белән.)* Әлү, әлү, улым, улыкаем, теге китап ни исемле иде әле ул?.. Сүкмә инде, кайткач сүгәрсең, склерозым купты бит... Әһә, ярар, ярар. *(Сөйләшеп бетереп, күзләрен челт-челт йомып карап тора.)*

Беренче китапханәче. Ни ди?

Китап алучы. Хәзер әйтәм... *(Паузадан соң.)* Билләһи, оныттым! Куркуымнан оныттым! Жуклар дигәне генә истә калды.

Беренче китапханәче. Жуков түгелме?

Китап алучы. Жуклар, диде.

Беренче китапханәче. Колорадо жуклары, димәдеме?

Китап алучы. Димәде.

Беренче китапханәче. Зөләйха, кер әле.

Икенче китапханәче *(кереп).* Нәрсә бар?

Беренче китапханәче. Син авторы патша исеменә охшаш «Жуклар» дигән китап белмисеңме?

Икенче китапханәче. Юк. Нәсия, кер әле!

Өченче китапханәче *(кереп).* Мин сезне ишетеп тордым, юк андый китап. Рита, чык әле монда.

Дүртенче китапханәче *(кереп).* Нәрсә?

Беренче китапханәче. Авторы патша фамилияле, исеме — «Жуклар», ди. Бармы андый китап?

Дүртенче китапханәче. Юк.

Китап алучы. Исемә төште. Кыздыра торган жуклар!

Китапханәчеләр:

— Кыздыра торган?!

— Жукны тавык та ашамый бит аны...

— Ничек кыздыралар?

Китап алучы. Мин каян белим. Май беләндер инде.

Дүртенче китапханәче. Наилә, кер әле!

Бишенче китапханәче *(кереп).* Ни бар?

Китап алучы. Бәрәч, апаем, нихәл?

Бишенче китапханәче. Исәнмесез.

Китап алучы. Үткән кыш син миңа менә мондый калын бер китап биргән идең. Шул китап тагын кирәк булды бит. Хәтерлисеңме?

Бишенче китапханәче. Ничек хәтерләмәскә. *(Китапны алып килә.)* Менә ул: Нурихан Фәттах, «Сызгыра торган уклар».

Китап алучы. Хан шул, хан! Әйттем бит, патша исеме дип! Бөтенегезгә бер зиһенле кеше бар икән! Әйтер идем инде тутырып... Юкка гына алып ятасыз хөкүмәт акчасын! *(Китапны тартып алып.)* Язып куй минем исемгә! *(Чыгып китә.)*

Китапханәчеләр бер-берләренә карашып тора.

Кәрим Тинчуринга кагылышлы мәзәкиятләр

Заһидә Тинчурина

МАРҖАГА ӨЙЛӘНГӘН КӘРИМ

1914 ел.

Кәрим Тинчуринның марҗага өйләнүе турында хәбәр аның туган авылына барып ирешә. Бу хәбәрне күрше авыл кешесе җиткерә. Беренче Бөтендөнья сугышында яраланып кайтучы бу солдат авылга Казан аша кайта да:

— Кәрим марҗага өйләнгән! — дип сөйли.

Моны ишеткәч, Кәримнең анасы әлеге солдат авылына китә.

— Әйе, әйе, Мәхмүдәттәй, — ди солдат. — Кәримең марҗага өйләнгән!

— Булмас ла! — ди ана кеше. — Бу хак сүз түгел!

— Валлаһи! — дип, яралы солдат ант итә. — Туйларында булдым. Кәрим үзе чакырды. Үз күзләрем белән күрдем. Бик олылап туйладылар. Марҗа белән туйларында кочаклаштылар, үбештеләр. Яхшы булды туйлары. Тик шунысы ошамады, Мәхмүдәттәй, туйга килгән халык үз акчаларына сатып алып ашады ризыкны. Эчемлекләрне дә үзләре сатып алып эчте.

Кәримнең анасы Мәхмүдәттәй, тиз генә җыенып, Казанга чыгып китә. Театрны эзләп таба. Сораштыра торгач, Кәримнең марҗасын да күрә. Ул марҗа Гөлсем Болгарская булып чыга. Сөйләшә-сораша торгач, шул аңлашыла. Яралы солдат урыс драматургының татарчага тәрҗемә ителгән пьесасы нигезендә куелган спектакльне караган икән дә, анда Кәрим Тинчурин уйный торган егет Гөлсем Болгарская уйный торган кызга өйләнә икән. Сәхнәдә туй күренеше дә булып, тәнәфестә тамашачылар буфеттан ашарга-эчәргә алган ризыкларны солдат туй сые, дип аңлаган икән.

8 март, 1986 ел

ЯЛЫНДЫРУ

Фатыйма Ильская бер генә режиссёрны да санламаган, диләр. Бөтен театр аның ихтыярына буйсына икән. Ләкин ни холыксыз булса да, Ильская Кәрим Тинчурин белән беркайчан да телгә килмәгән. Иртәгә премьера уйналасы көнне Фатыйма ханым:

— Уф, башым авырта, иртәгә мин уйный алмам, ахрысы. Спектакльне күчерегез! — дип, артистлар күңеленә шом сала.

Директор, администраторлар, артистлар, режиссёрлар, вахтерлар, каравылчылар Фатыйма ханым янына килеп ялына башлый:

— Харап итмә, билетлар сатылып беткән!

Юк! Фатыйма ханым уйнаудан баш тарта.

Шуннан соң Кәрим Тинчурин Фатыйма ханымның өенә китә.

— Юк-юк, Кәрим абзый, мин уйный алмыйм, кәефем юк! — дип чат каршы тора артистка.

Кәрим дәшми, Фатыйма ханымның чәпчегәнен байтак кына тыңлап утыра да әйтеп куя:

— Ярар, Фатыйма ханым, — ди режиссёр. — Алай хәлегез бик авыр булса, уйнамассыз. Ләкин спектакльне өзәргә ярамый. Шуңа күрә, башка берәр артистканы әзерләрмен. Сезнең репетицияләрне баштанаяк караучылар бар анда. Галия Булатова да рольне тиз ала…

— Ю-ук, юк! — дип кычкыра Фатыйма ханым. — Үзем уйныйм. Аларга бирәмме соң мин үз ролемне! Үзем уйныйм!

Шулай итеп, спектакль өзелмичә кала.

22 апрель, 1986 ел ■

Мирасворд

Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә

Борынгы грекларда исәпләү тактасы

Әдәби әсәр, китап бүлеге

Киевка нигез салган кенәз

Кисәкчә

1923 елда Ташкентта татарча чыккан педагогик журнал

Төрки каганлыкларда каган варисы титулы

Алтын Урда шәһәре

Мәҗнүннең сөйгәне

Хаҗилар киеме

Юраган ... килә

Халык авыз иҗаты әсәре

Салават репертуарындагы җыр

Шәехзадә Бабич туган авыл

Шымчы (иск.)

Урта гасыр сугышчысы баш киеме

Дини бәйрәм

Йорт, бина (иск.)

Борынгы Русьта игенче

... кичтән хәерлерәк

Аккургаш һәм сөрмә эретмәсе

Актриса ... Синәева

Хромлы минераль буяу

Дөрес, хак

Нәҗми, Латыйп

Кобо ... (япон әдибе)

Совет истребителе

XIX йөз рус рәссамы

... Насыйри

Утлы күмер

Чуашларның милли бәйрәме

Композитор ... Мурадели

Камыр башы, ачыткы

Фольклорчы ... Надиров

Грек хәрефе

Кабыктан ясалган түгәрәк савыт

Тарихта тирән ... калдыру

Акча да, уен коралы да

Татар ханлыкларында дәүләт вәзирлеге идарәсе

Борынгы грек шагыйре

... Юзиев



Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

Мәшһүр немец композиторы

Төркия каласы

Идел буе Болгар дәүләтенең икенче хакиме

Рәис Габдулла төзеде.

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: бунчук, диван, ашуг, Зәйни, күн, Карл, Наил, верлибр, ләх, газета, гореф, гарасат, Ика, Мар, угыз, Урайский, хәмзә, егу, еру, «Авыл», Каюм, зыян.

Өстән аска: хек, «Зар», Гамбәр, әрбә, Ра, Муса, Бәдәйли, гаруз, Лаос, Рәхим, Нәваи, Рада, аш, егет, «Уяну», Фавн, ук, Аяз, киле, Агиев, үләт, Кыйгы, Хафиз, улан.

Даруханә бинасы. Казан. 1908-1910 нчы еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы /март

• 315 ел элек (1701)

Казанда беренче даруханә ачыла.

• 235 ел элек (1781)

Мамадыш өяз шәһәре статусына ия була.

• 120 ел элек (1896)

Беренче татар укчы бригадасының Беренче мөселман полкы командиры Әхмәтша Сабит улы Сабитов (1896-1919) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1921)

Мәскәүдәге Шәрык телләре институтында татар әдәбияты түгәрәге эшли башлый.

• 90 ел элек (1926)

9 мартта башкалабыз Казанда татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан (1886-1926) вафат була.

• 85 ел элек (1936)

Бөтенукраина пролетариат язучылары оешмасының Харьковтагы Үзәк бюросы янында татар секциясе төзелә. Ул Донбасстагы татар клублары, партия мәктәпләре каршында, Днепростройдагы татар эшчеләре арасында матур әдәбият түгәрәкләре оештыру белән шөгыльләнә, аларны тиешле программа вә китаплар белән тәэмин итә.

• 80 ел элек (1931)

23 мартта Татар дәүләт академия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» әсәре буенча спектакль премьерасы була.

• 75 ел элек (1941)

18 мартта «Алтынчәч» операсына багышланган иҗади конференция уза. Докладлар белән Нәҗип Җиһанов һәм Җәләл Садриҗиһанов чыгыш ясый.

• 70 ел элек (1946)

Башкортстан язучылар союзы Габдулла Тукайның тууына 60 ел тулуны үткәрү өчен комиссия төзи.

• 65 ел элек (1951)

5 мартта Татарстан дәүләт музеенда каһарман шагыйрь Фатих Кәримнең фронтта һәлак булуына алты ел тулуга багышланган гыйльми җыелыш була.

• 25 ел элек (1991)

13 мартта Уфа каласында Һади Такташның тууына 90 ел тулуга багышланган кичә уздырыла. ■

«Мульталь». Кәгазь, акварель

Зифа Мөхәммәтҗанова

«Зөһрә».
Кәгазь, акварель

Зифа Васыйл кызы Мөхәммәтҗанова 1951 елның 19 июлендә ТАССРның Биектау районына караган Бимери авылында дөньяга килә. 1973 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Озак еллар дәвамында «Азат хатын» («Сөембикә») һәм «Ялкын» журналларында рәссам булып эшли.

Зифа Мөхәммәтҗанова — 1994 елдан Татарстанның, 2002 елдан — Россиянең Рәссамнар берлекләре әгъзасы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001).

Рәссамның әсәрләре Россиянең һәм чит илләрнең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.

Зифа Мөхәммәтҗанова 2016 елның 7 февралендә Лондон шәһәрендә вафат була.

«Падишаһның хатыны һәм Алтынчәч турында әкият». Кәгазь, акварель

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«Безнең мирас» белән бергә булыгыз!

www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

• www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә

• редакциядә

• www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172